ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№12 (324) – ДЕКАБРЬ 2018

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан нәшер ителә

Тавыш бирү аша яңару

Кеше китә, җыры кала

Шәһәрдән рәхәтрәк яшәү

ЭЛВИН ГРЕЙ: – БӨТЕН ДӨНЬЯ ТАТАР МУЗЫКАСЫН ТЫҢЛЫЙ

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Ксения Сёмина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: җырчы Элвин Грей
Фото җырчының архивыннан алынды

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Татар телендә тираж: 1000 данә,
рус телендә: 2500 данә

Гомуми тираж: 3500 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № Е-3516
Басарга кул куелды: 24.12.18

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Коммерция директоры урынбасары:
Җәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru

Сату бүлеге белгече: Гүзәл Подольская

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

БӘХЕТ АРТЫК БУЛМЫЙ: ЯҢАСЫ ДА, ИСКЕСЕ ДӘ...

Икенче меңьеллык та үзенең балигълык чорына керде. Бик тиздән, берничә көннән, аңа инде 20 яшь тула. Меңьеллык үзенең 19 яшьлек гомерен ничегрәк уздырды соң, – монысын анык кына берәү дә хәтерләми. Хәтта тарихчылар да. Аның каравы, без узган гасырның 19 нчы елын бик яхшы хәтерлибез, чөнки ул – Гражданнар сугышы вакыты. Салкын, ач, хәвефле... Кешеләрдә – шом, курку. Туган – туганына, ата улына каршы корал тотып барган заманнар... Кабат шундыйны күрсәтмәсен берүк!

Нәкъ менә чагыштырулар хакыйкатьне тоярга мөмкинлек бирә дә. Салкын урынына – җылылык, уңайлылык. Ачлык урынына – туклык, хәтта ки муллык. Ә курку урынына – тынычлык һәм йөзләрдәге якты елмаюлар.

Кем дә кем, әлеге поляр чагыштыруларны ваемламыйча, һаман да хәсрәтләнеп, сызланып утырырга тели икән, әнә шул 1919 нчы елга китсен һәм рәхәтләнсен! Ә без сезне 2019 нчы елга чакырабыз һәм Яңа ел, яңа бәхет, яңа шатлык белән тәбриклибез! Иске бәхеттән дә баш тартырга ашыкмагыз, дип өстибез килә тагын редакция исеменнән. Икесе дә булсын – бәхет артыкмыни?!

СЕЗНЕҢ БӘХЕТЛЕ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзүм Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **924 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7076** – татар телендә
Индекс **П7077** – рус телендә

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ



Галина Антонова. «Бөгелмә янында беренче кар». 2016 ел.

ДЕКАБРЬ

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Якыннан аралашу.
Россия Президентына
нинди сораулар бирделәр

7. Кытайдан Лондонга кадәр.
Татарстан Президентының
эш сәфәрләре

19. Фермерларга ярдәм.
Авыл хуҗалыгы грантларын ничек
алып була

22. Тавыш биреп төзекләндерү.
Үзара салым авылларыбызны
ничек матурлый

26. Татар халкы үсеше стратегиясе.
Фикерләр туплыйбыз

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

28. Өйләр якты булсын!
Катлаулыны ничек
гадиләштерергә

30. Кышкы мавыгулар.
Балыкчылардан –
кызык хәлләр

Тулырак
мәгълүмат түбәндәге
сайтта:
www.protatarstan.ru

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

42. «Татарстан» журналыннан шашлык рецепты.
Бөгелмә мәрында кунакта

56. Тарихи сәхифәләр.
Казан ханлыгы тәхете
өчен көрәш ничек барган

64. Безнең киштәдә.
Кино дөньясыниләр
белән шаккатыра

80. Авылларыбыз.
Кайда шәһәрдән
рәхәтрәк яшиләр

84. Элвин Грей:
«Бөтен дөнья татар
музыкасын тыңлый»

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

11.12

Валентина Матвиенко, Федерация Советы рәисе, – Мәскәүдә, РФ Федераль Җыенының Федерация Советында Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше мәсьәләләрен тикшергәндә:

– Татарстан тотрыклы рәвештә инвестицияләр өчен аеруча кызыклы төбәкләр исәбенә керүен дәвам итә. Күптән түгел Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан дөньяда иң яхшылардан дип танылды.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

14.12

Карина Саликова, чемпионатларны федераль һәм халыкара дәрәҗәдә WSI стандартларына туры китереп оештыру буенча «Яшь профессионаллар» («Ворлдскиллс Россия») Союзы генераль директоры урынбасары:

– Татарстан – WorldSkills хәрәкәтендә катнашучылар арасында бик көчле уенчы, чөнки монда көчле IT-кластер. Республика, тармакның үсешенә көч керткәнгә күрә, күп яктан башка төбәкләрдән алда бара. Без Татарстан Хөкүмәте һәм республика Президенты тарафыннан зур кызыксыну күрәбез.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

17.12

Илсур Метшин, Казан мэры, – мэриядәге эшлекле дүшәмбедә:

– Быел без шәһәрне бизәүгә күп көч һәм акчалар кертергә тырыштык – бигрәк тә аның үзәгенә, чөнки, традиция буларак, бәйрәмнәрдә монда Казан кешеләре җыела, анда Яңа ел чаралары уздырыла һәм төп туристик маршрутлар үтә торган театрлар һәм күпсанлы концерт мәйданнары урнашкан. Республика Президенты ярдәме белән без бәйрәмчә бизәлешкә шактый игътибар бирә алдык. Инде бу атна ахырында ук сез шәһәр үзәгенең һәм башкаладагы төп мәйданнарның ничек яңача балкуын күрә алырсыз, дип өметләнәм.

Фото ТР Президенты сайтыннан алынды

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан Президенты **КАЙЛАРГА** юл тота

Фермер хуҗалыклары өчен **НИНДИ** грантлар каралган

Үзара салым авылга **НИЧЕК** ярдәм итә

Татар халкы үсеше стратегиясе **НИНДИ** булырга тиеш

ФОРСАТТАН ФАЙДАЛАНЫП, **ПУТИНГА СОРАУ БИРЕГЕЗ**

Россия Президенты 20 декабрь көнне Мәскәүдә, илнең һәм дөньяның төрле почмакларыннан Халыкара сәүдә үзәгенә җыелган ике меңгә якын журналист булән очрашып, дүрт сәгатькә якын аларның сорауларына җавап бирде.

Автор: Татьяна Вафина

ҮТКЕНЛЕКТӘ ЯРЫШЫП...

Сораулар җитди иде, ә менә Путинның игътибарын үз персоналарына традицион плакат-табличкалар белән җәлеп итәргә тырышучылар – күп түгел. Журналистлар тапкырлыкта-үткенлектә ярышты: «Мне больно!», «Я из будущего!», «Татары здесь!», «Нас ждёт Париж», «Россияне в опасности!», «КГБ и дети», «Путин+лыжи=Карачаево-Черкессия», «Путин – щука»... Әлбәттә, сорау бирүчеләр 1702 кеше булып, җавап бирүче берүзе генә булганда, нәкъ менә сине күреп алсыннар өчен тырышырга туры килә. Һәм халык аерылып торырга, оригиналь күренергә, шаккатырырга омтылды... Милли киемнәр, шөлдерле барабаннар, Кар кызы костюмы яисә хоккейчы шлемы белән генә булса да.

ИГЪТИБАР – ТЫЙНАКЛАРГА

Президентның бу маскарадка исе китмәде кебек, кычкыручыларга бик сабыр карады, зур канәгатьлек белән сүзне артык оригиналь булмаганнарга – Россия флагын тыйнак кына чайкап, видеооператорларга залны төшерергә комачаулаган журналисткага бирде.

– Россия флагы беркемгә дә комачаулый алмый! – дип битәрләп тә алды операторларны.

Күзенә тарткан җете зәңгәр сөрмәсе «Мин СССРдан» дип «кычкырып» торган ханыма да чират җитте, ул Президентның Әрмәнстан белән мөнәсәбәтләрне ничек җайларга җыенуы белән кызыксынды. Бөтенесеннән дә катырак кычкырган Владивосток та сүз алды. Йөз чалымнары славян тибын хәтерләтмәгән, алсу төстәге костюм кигән кызлар – һәркайсыбызга билгеле телеканалларның сөйкемле алып баручыларына да бер-ике минут вакыт табылды.

«КЕШЕЛӘР ЕРАКТАН КИЛГӘН...»

Нәтиҗәдә 53 кеше 86 сорау бирергә өлгерде – бу мәгълүмат махсус өйрәтелгән кешеләр тарафыннан саналып, барлык ММЧнда инде яңгырады. Президентның матбугат секретаре Песковның, бер-берегезне хөрмәт итеп, берәр генә сорау бирегез дигән үтенечен ишетмәделәр кебек. Ә бәлки ишеткәннәрдер дә, чөнки яңгыраган һәр фикерне сорау дип атап булмый иде. Барыннан да бигрәк, аларны рәхмәт сүзләре, ярдәм турындагы үтенеч һәм кунакка чакырулар дип атап буладыр – «Чечняга килегез берочтан...».

– Чечняга берочтан килергә ярамый, – диде Путин, нәсыйхәт биргәндәй. – Чечняга махсус килергә кирәк. Һичшиксез барачакмын.

Чечня бик шатланды һәм ташып чыккан куанычыннан, күрәсең, ничек кенә тырышмасын соравын бирә алмый азапланган Латин Америкасына игътибар итүләрен сорады:

– Кешеләр ерактан килгән бит...

БЕЗ – БЕР КАННАН!

Куркынычсызлык органнары хезмәткәрләре көне (ә ул ничектер нәкъ менә матбугат конференциясе оештырылган көнгә туры килде) белән котлаулар кабул итеп, Президент каләм һәм микрофон ияләрен калкан һәм кылыч хезмәткәрләре белән чагыштырды.

– Күпмедер дәрәҗәдә без сезнең белән – коллегалар. Сез мәгълүмат җыясыз, без дә мәгълүмат туплыйбыз...

Журналистлар әлеге чагыштыруга каршы килмәде.

ШӘХСИ ТОРМЫШ ТУРЫНДА

«Life» интернет-басмасы журналистының «Сез кайчан өйләнәсез? Һәм кемгә?» дигән соравы үзләренә чират килеп җитә алмавыннан моңсуланган рәтләр арасында җанлану уятты. Президент башта журналистның гаилә хәлен сорашты һәм, инде уңай җавап алгач, күрсенеп кенә:

– ...Тәрбияле кеше буларак мин дә, мөгаен, кайчан да булса моны эшләргә тиеш буламдыр.

Озын сүзнең кыскасы, өйләнергә вәгъдә итте дияргә була.

– Сәламәтлегегез ничек? – дигән сорауга да шаяртып җавап бирде:

– Өметләнмәгез!

ИНТЕРНЕТТА ДА БУЛСЫН ҖАВАПЛЫЛЫК!

Яшьләр турында сөйләшүдә исә мәзәкләр кискенрәк булды.

Интернетта хакимият вәкилләрен мыскыл иткән өчен җаваплылык турындагы законны кертеп, яшьләрнең ышанычын югалтудан курыкмыйсызмы дигәнгә:

– Интернеттан тыш җаваплылык бар икән, ул интернетта да булсын, – дип җавап бирде Президент. Ул җыр текстларында наркотикларны, суицидларны пропагандалауга юл куелмаска тиеш дип саный.

– Нәрсә без хәзер асылынырга да тиешме? Бигайбә, мин беренче түгел! Андыйга китсә, сез беренче буласыз.

БЮРОКРАТИЯ – МӘҢГЕЛЕК

Сорауларның берсенә бирелгән җавап бюрократияне җиңүгә бераз гына булса да өмет барлыгын расларга тиеш иде кебек. Әмма Президент өмет калдырмады. Җиңел генә, нәтиҗәләрен озаклап уйлап тормыйча да, кистереп белдерде:

– Бюрократия – мәңгелек. Аны җиңү мөмкин түгел. Һәм аңардан башка яшәп тә булмый.

Конференциядән соң, командировка кәгазьләрен ябарга чират торганда, без Президентның, хәер, башка фразалары кебек үк канатлыга әйләнеп өлгергән әлеге фразасын искә төшердек. Һәм ризалаштык. Инде Президент та бюрократияне җиңәргә җыенмагач, чигенергә генә кала. Самолетка гына соңга калмаска иде... Т

Автор фотолары

FlashNord
TELLING THE UNTOLD
ТАТАРЫ КАЗАНЬ
ЛИДЕРЫ КУЗБАССА

КРЫМСКИЕ ТАТАРЫ

РОССИЯ

ВЕРНИТЕ НАШЕГО МЭРА

КОГАЛЫМ

ПУТИН–ЩУКА

ТАТАРСТАННЫҢ ИҢ ЯХШЫ БЛОГЕРЫ ӨЧЕН ТАВЫШ БИР!

protatarstan.ru

vk.com/protatarstann

instagram.com/protatarstan

Реклама 16+



ПРЕЗИДЕНТ МАРШРУТЫ БУЕНЧА

Татарстан Президентының эш графигы никадәр тыгыз булуын аңлар өчен, бернинди махсус хронометраж үткәрү таләп ителми. Аның сәфәрләре маршрутына күз салу да җитә. Республика, ил, дөнья буйлап туктаусыз йөри ул. Еш кына Рөстәм Миңнеханов иртән нинди дә булса Европа илендә потенциаль инвесторлар белән сөйләшүләр үткәрергә, көндез Россия башкаласындагы мөһим киңәшмәдә катнашырга өлгерә, берничә сәгатьтән соң исә Әлмәттә нефть тармагы үсеше перспективаларын тикшерә... Һәм көн саен диярлек шундый хәл күзәтелә.

Юлда үткән сәгатьләр һәм чакрымнар, мөһим очрашулар, җитди чыгышлар һәм җаваплы карарлар. 2018 елның ахыры вакыйгаларга бай булды. ТР Президентының соңгы арадагы эш сәфәрләреннән «Татарстан» аеруча әһәмиятлеләрен сайлап алырга тырышты.

КЫТАЙ.
ЮГАРЫ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРНЕҢ ТАРТУ КӨЧЕ

НӘРСӘ:

Республика Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкчелегендәге ТР делегациясенең Гуандун (Кытай) провинциясенә эш сәфәре белән барышында Татарстан белән Huawei компаниясе арасында хезмәттәшлек турында кайбер документлар имзаланды.

Татарстан Президенты Гуандун провинциясе хөкүмәтенең генераль секретаре урынбасары Линь Цзи әфәнде белән очрашты, Гуандун провинциясе вице-губернаторы Оуян Вэймин белән төбәкара хезмәттәшлек перспективаларын тикшерде, Татарстан Республикасы һәм Гуандун провинциясенең эшлекле даирәләре катнашындагы бизнес-форумда чыгыш ясады, CHTF Кытай югары технологияләре күргәзмәсендә һәм берничә билгеле компаниядә булды.

КАЙДА:

Гуанчжоу, Шэньчжэнь

КАЙЧАН:

15–16 ноябрь

– Кытай милли химия-инженерлык корпорациясе катнашында Татарстанда «Аммоний» минераль ашламалар җитештерү заводы төзелде. Тяньцзинь икътисадый һәм техник үсеш зонасы белән «Алабуга» МИЗның өченче чиратын үстерү өчен уртак предприятие ачу мөмкинлеге карала. «КАМАЗ» һәм Кытайның «Вейчай» компаниясе арасында автомобиль двигательләре җитештерү өлкәсендә эшчәнлек алып барыла. «Хуавэй» компаниясе белән без инфокоммуникацион технологияләр өлкәсендә хезмәттәшлек итәбез.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты.

Фото: ТР Президентының рәсми сайты, Марсель Бадыкшин

ТУЛЫРАК:

Татарстан һәм Гуандун провинциясенең эшлекле даирәсе катнашындагы бизнес-форумда Рөстәм Миңнеханов шуны искә төшереп үтте: Татарстан белән Кытай арасындагы товар әйләнеше динамик үсешен дәвам итә. Хезмәттәшлекне киңәйтү өчен потенциаль резервлар арасыннан берсе – югары технологияләр өлкәсе.

Рөстәм Миңнеханов Кытайга сәфәре кысаларында PAX Technology ИТ-компаниясе генераль директоры Джек Лю белән очрашты. Компания – банк түләү терминаллары дөнья базарындагы лидерларның берсе.

PAX Technology белән Татарстанның SwitchSales системасын үстерүче DLS ИТ-компаниясе хезмәттәшлек итә. PAX Technology һәм DLS компаниясе арасындагы хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. PAX Technology компаниясе SwitchSales системасын халыкара базарга этәрүгә ярдәм итәчәк.

Шэньчжэньда Татарстан Президенты Huawei компаниясенең куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге соңгы эшкәртмәләре белән танышты. Huawei штаб-квартирасында компания һәм ТР Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы арасында хезмәттәшлек турында меморандумга кул кую тантанасы узды. Huawei республика территориясендә үзенең фәнни-тикшеренү үзәген ачарга ниятли. Шулай ук Huawei һәм «Татнефть» хезмәттәшлек турында меморандум имзаладылар.

БЕЛЕШМӘ:

Гуандун – Кытайның көньяк-көнчыгышындагы провинция. Бу КХРның әйдәп баручы икътисадый һәм экспорт базасы. Провинция ил күләмендә электрон, текстиль, азык-төлек, фармацевтика продукциясе һәм көнкүреш техникасын җитештерү буенча лидер санала. Гуандунда Кытайдагы дүрт махсус икътисадый зонаның өчесе урнашкан: Шэньчжэнь, Шаньтоу һәм Чжухай. Узган елда провинциянең импорт һәм экспорт буенча гомуми күләмнәре $1 трлннан артып китте. Провинциядә биш дәүләт аэропорты, һәм шулай ук берничә эре диңгез порты урнашкан. Зур тизлекле тимер юлларның гомуми озынлыгы – 1500 километр.

– Без уртак сәүдә-икътисадый эшчәнлегебезне яңа дәрәҗәгә күтәрербез, үзара инвестицияләрнең тагын да югарырак күрсәткечләренә ирешербез, дип ниятлибез. Уртак тырышлык нәтиҗәсендә Гуандун провинциясе һәм Татарстан Республикасы яшәгән төбәкләребез һәм илләребез халыклары иминлеге-муллыгы хакына алып барылган хезмәттәшлек тарихының өр-яңа сәхифәләрен язачак, дип ышанабыз.

Линь Цзи,
Гуандун провинциясе хөкүмәтенең генераль секретаре урынбасары.

ТОМАНЛЫ АЛЬБИОН. БИЗНЕСНЫҢ МАКСАТЛАРЫ АЧЫК



– Безне үзара мөнәсәбәтләр урнаштыру кызыксындыра. Төбәкара дәрәҗәдә тагын да уңышлырак эшли алырбыз, дип уйлыйм. Татарстан Хөкүмәте һәм Уэльс Хөкүмәте арасында нинди дә каршылыклар юк. Без сәүдә-икътисад, мәгариф, фәнни-тикшеренү һәм туристлык мөнәсәбәтләре кысаларындагы теге яисә бу программалар буенча тизрәк уртак тел таба һәм аларны гамәлгә ашыра алачакбыз.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты.

НӘРСӘ:

IV Россия-Британия бизнес-форумында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың инвестицион потенциалы белән таныштырды.

КАЙДА:

Лондон

КАЙЧАН:

26 ноябрь

Фото: ТР Президентының рәсми сайтыннан алынды, Эдуард Хәйруллин

ТУЛЫРАК:

Рөстәм Миңнеханов форумның пленар утырышында чыгыш ясады. Татарстан Президенты шуны билгеләп үтте: уңай инвестицион климатны үстерү – республикада төп бурычларның берсе, һәм ул уңышлы хәл ителә. Татарстан предприятиеләре һәм банклар инглиз партнерлары белән турыдан-туры элемтәләргә ия, вузлар Британия университетлары белән хезмәттәшлек итә. Бөекбритания ягыннан тупланган инвестицияләрнең күләме $1 млрдка якын. Хезмәттәшлекне киңәйтү өчен сфералар – энергетика һәм нефть химиясе, автомобиль төзелеше һәм автокомпонентлар җитештерү, авиатөзелеш, ИТ-өлкә, агросәнәгать комплексы, инжиниринг, медицина һәм башкалар. Форум кысаларында Татарстанда төзелеп килә торган яңа «Фармаполис» үсеш территориясе проектын тәкъдир иттеләр. Аннан соң ТР Президенты катнашында Татарстанның «АГРОСИЛА» компаниясе белән Британиянең үсемлекләрне химик яклау өчен заманча җиһазлар чыгаручы Househam компаниясе арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды.

Шул ук көнне Татарстан Президенты кайбер компанияләр җитәкчелеге белән сөйләшүләр уздырды. ТРның туристлык куәтен алга этәрү буенча хезмәттәшлекнең мөмкин булган юнәлешләрен ул National Geographic Partnersның Европа һәм Африка буенча өлкән вице-президенты Аннабел Канвелл белән фикер алышты. Precision Decisions Ltd (Hands Free Hectare – роботлаштырылган ферма проектын эшләүчеләрнең берсе) җитәкчелеге белән очрашуда Рөстәм Миңнеханов ТРнда уртак проектларны тормышка ашыру мөмкинлекләрен тикшерергә тәкъдим итте. Эшчәнлекнең төрле вариантларын тикшереп карау өчен эшче төркем төзү турында United Green Group җитәкчелеге белән дә килешүгә ирешелде. Әлеге компания энергетикада, автосәнәгатьтә, туклану продуктларын җитештерү һәм башка юнәлешләрдәге уңышлы проектлары белән билгеле.

Мөмкин булган хезмәттәшлек мәсьәләләре шулай ук Рөстәм Миңнехановның Британия парламентарийлары һәм Уэльсның беренче министры Каруин Джонс белән очрашулары барышында тикшерелде. Һәр ике як та хезмәттәшлекнең перспективалы юнәлешләрен билгеләү өчен эшче төркем төзергә килештеләр.

Сәфәр ахырында Рөстәм Миңнеханов бүгенге көндә 500дән артык кешене туплаган Бөекбритания татар җәмгыяте вәкилләре белән очрашты.

БЕЛЕШМӘ:

Татарстан Британиягә нефть һәм нефть продуктлары, пластмасса, каучук, резина эшләнмәләре һәм башка товарлар чыгара. Үз чиратында республика төрле җиһазлар, технологияләр, кайбер сәнәгать товарлары сатып ала. 2017 ел йомгаклары буенча товар әйләнеше 55% ка үсте, $340 млнны тәшкил итте. Быелның 9 аенда гына да үзара сәүдә күләмнәре $800 млннан артып китте. Ел ахырына кадәр әлеге күрсәткеч $1 млрдка җитәр, дип ниятләнелә.

IV Россия – Британия бизнес-форумы бизнесны, дәүләт оешмаларын һәм ике илнең үсеш институтларын күрсәтүче 800дән артык катнашучыны һәм 50 югары дәрәҗәдәге спикерны берләштерә. Экспертлар фаразлары буенча, Россия һәм Бөекбритания арасындагы товар әйләнеше 2018 ел йомгаклары буенча үсешен дәвам итә һәм $14 млрдка якынны тәшкил итәчәк.

«МИРАС». ЧЕМПИОННАР БИШЕГЕ

– Барлык әлмәтлеләрне дә әлеге менә дигән спорт комплексының ачылуы белән котлыйсым килә. Нефтьчеләребез ярдәме белән республикада шушындый матур объектлар пәйда була. Проектлаучыларга, төзүчеләргә һәм әлеге проектны тормышка ашыруда катнашучы барлык кешегә рәхмәтемне белдерәсем килә.

Рөстәм Миңнеханов,
Татарстан Президенты.

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Әлмәттә тантаналы рәвештә су спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен яңа «Мирас» спорт-савыктыру комплексын ачты.

КАЙДА:

Әлмәт

КАЙЧАН:

19 ноябрь

Фото: ТР Президентының рәсми сайты, Марсель Бадыкшин

ТУЛЫРАК:

Су спорт төрләре үзәге – нефть башкаласы картасында пәйда булган тагын бер заманча күпфункцияле савыктыру комплексы. Мәйданы 12 мең квадрат метрны тәшкил иткән бинада 10 йөзү юлы булган 50 метрлы зур бассейн һәм балалар өчен 10 метрлы бассейн урнаштырылган. Суның чисталыгын махсус су әзерләү һәм фильтрлау системасы тәэмин итә.

БЕЛЕШМӘ:

«Мирас» үзәгендә шулай ук тренажер залы, медицина блогы һәм Актив озак яшәү үзәге бар. Физик мкинлекләре чикле кешеләр өчен бөтен шартлар тудырылган. Инде якын киләчәктә йөзү белән шөгыльләнүче әлмәтлеләрнең саны өч-дүрт мәртәбәгә артыр, дип көтелә.

– Мин яшь йөзүчеләргә, спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләргә Олимпия уңышлары телим, чөнки әлеге объектны ачу белән спорт әзерлеген бөтенләй яңа дәрәҗәгә күтәрү мөмкинлеге барлыкка килә. Ләкин иң мөһиме – «Мирас» бассейны, нинди генә яшьтә булуларына карамастан, бар кеше өчен дә ачык булачак.

Айрат Хәйруллин,
Әлмәт муниципаль районы башлыгы

ЛАЕШ РАЙОНЫ.
АНГАРАНЫҢ КАМА ЯРЫ

Фото: ТР Президентының рәсми сайты, Рөстәм Кадыйров

НӘРСӘ:

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Зөләйха күзләрен ача» фильмын төшерү мәйданчыгында булды.

КАЙДА:

Лаеш районы

КАЙЧАН:

21 ноябрь

ТУЛЫРАК:

Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романы буенча шул ук исемдәге фильмны төшерү өчен декорацияләр Кама елгасы ярында, Лаеш районының Иске Пристаненнан ерак түгел генә төзелгән иде. «Семрук» махсус поселениесен» – бараклар, клуб, лазарет, махсус комендатура һ.б.ларны – стахановчылар темпында кордылар, көзен фильмны төшерә дә башладылар. Фильмның продюсеры Илья Папернов Рөстәм Миңнехановка хәбәр иткәнчә, съемкалар гыйнвар-февраль айларында дәвам итәчәк, башта – Пермьдә, аннан – Казанда, соңрак тагын Лаеш «Семругында». «Төп урын – бистәдә казылган землянка булачак. Бу авыр елларда авыл кешеләренең ничек исән кала алулары турындагы кышкы күренешләрне төшерәчәкбез», – диде Папернов.

Фильм авторлары Кама ярында салынган «Семрук»ны кайчандыр тайгадагы, Ангара яры буендагы махсус поселение көнкүрешен күрсәтү өчен идеаль урын дип саный: барысы да кино төшерүчеләр күзаллаганча эшләнгән. Татарстан өчен фильм төшерүчеләр белән хезмәттәшлек – шулай ук зур уңыш. Эш монда «үзеңне кинода күрү» мөмкинлегендә генә түгел. Зур күләмле декорацияләр фильм төшерелгәннән соң арт-объектка әйләнә ала. Алай гына да түгел, алардан башка фильмнарны, шул исәптән үзебезнекен, Татарстанныкын төшергәндә файдаланып булачак.

БЕЛЕШМӘ:

«Зөләйха күзләрен ача» романыннан өзек 2014 елда «Сибирские огни» журналының май санында басылган иде. Роман тулысынча бер елдан соң дөнья күрде, шул ук елда аның авторы Гүзәл Яхина «Большая книга» Милли әдәби премиясенең лауреаты дип табылды. 2017 елга роман инде 18 телгә тәрҗемә ителде.

«Зөләйха күзләрен ача» фильмын төшерү белән «Русское» кинокомпаниясе шөгыльләнә. Төп рольдә – Чулпан Хамматова. Сериалда шулай Юлия Пересильд, Сергей Маковецкий, Роман Мадянов, Евгений Морозов, Елена Шевченко, Александр Баширов, Рамил Сабитов, Роза Хәйруллина һәм башка артистлар катнаша. Фильмның режиссеры – Егор Анашкин.

Айдар Мадьяров, директор

ШӘП СЫЙФАТ!

«Татспиртпром» АҖ филиалы «Усад спирт заводы» – Татарстан Республикасының 1898 елда ук нигез салынган иң зур һәм тарихи предприятиеләреннән берсе. Революциягә кадәр гөрләп эшләгән завод яки фирманың, җитештерүне саклап калып, безнең көннәргә кадәр имин килеп җитүенә сирәк очрый торган мисалларның берсе бу.

Биредә чыгарыла торган продукциянең күләме елдан-ел ишәя бара, аның сыйфаты һәм көндәшлеккә сәләтлелеге арта. Әмма заманчалаштыруга акча кертмәсәң, бик алдынгы, уңышлы предприятие дә базарда лидерлык позицияләрен саклап кала алмый. 2015 елда Усадта зур җитештерү куәтенә ия булган, заманча итальян һәм немец җиһазлары белән җиһазландырылган яңа завод файдалануга тапшырылды. Ул иң яңа технологияләр буенча Татарстанда һәм Россия Федерациясендә зур ихтыяҗ тудырган югары сыйфатлы продукт җитештерү мөмкинлеге бирә.

Заводта җиһазлар, файдаланыла торган методикалар өзлексез тикшерелә, продукциянең сыйфаты катгый контрольдә тотыла, персоналның квалификациясе даими күтәрелә. Хәзерге предприятие әйләнә-тирәгә зыян салуны мөмкин булганча киметә торган чистарту корылмалары системасы белән җиһазландырылган. Туган якның экологиясе табыштан мөһимрәк!

Продуктның сыйфатын һәм ГОСТ таләпләренә ярашлы булуын объектив бәяләү өчен ябык дегустацияләр үткәрелә, аларда Россиянең башка шундый предприятиеләрендә җитештерелгән продукция дә катнаша. Мондый тикшерүләрнең нәтиҗәсе һәрвакыт диярлек бертөрле – Усад спирт заводы даими рәвештә иң күп тавыш җыя, бу исә иске партнерлар белән хезмәттәшлекнең дәвам итүен һәм яңалары белән килешүләр төзелүен аңлата.

2011 елда «ПРОДЭКСПО» халыкара ярминкәсендә үткән XIII конкурсында УСЗ «Люкс» продукты сыйфаты өчен алтын медаль белән бүләкләнгән. 2017 елда Мәскәү халыкара конкурсында «Люкс» продукты сыйфаты өчен предприятие I дәрәҗәле диплом һәм алтын медаль яулаган. 2018 елда предприятие «Россиянең иң яхшы йөз товары» конкурсында «Азык-төлек товарлары» номинациясендә лауреат булган.

2018 елда филиал беренче тапкыр «Сыйфат өлкәсендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте премиясе» конкурсында катнашкан. Бәйге нәтиҗәләре буенча «Эшлекле камиллек» номинациясендә грамота белән бүләкләнгән.

Бүген УСЗ халыкара дәрәҗәгә чыга, төрле оешмалар белән партнерлык мөнәсәбәтләре урнаштыра, һәм үз продуктын көнбатыш базарларына тәкъдим итә.

Җитештерүдән соң калган барданы авыл хуҗалыгы хайваннарына һәм кошларына ашаталар. Азык бардасын Россия базарына да, экспортка – Балтыйк буе илләренә дә чыгаралар.

Бердәм һәм тату командадан башка яхшы нәтиҗәгә ирешү мөмкин түгел. Завод хезмәткәрләре эшли дә, ял да итә белә. Эшчеләр кышкы һәм җәйге спартакиадаларда, төрле шахмат һәм теннис турнирларында даими катнаша.

Заводта эшләүчеләр «Биектау» спорт комплексында волейбол, футбол, хоккей уйный, гаиләләре белән тимераякта шуарга килә. ГТО нор-

Фотолар Усад спирт заводыннан алынды
Реклама

маларын тапшыралар. УСЗ командалары еш кына районда беренче урыннарны ала. 2017 елда завод физкультура-спорт эше куелышы буенча Бөтенроссия смотр-конкурсында җиңгән.

Завод хезмәткәрләре эшче яшьләрнең «Безнең заман – Наше время» республика конкурсында ел саен алдынгы урыннарны ала. Ветераннарга һәм тыл хезмәтчәннәренә аеруча хөрмәт күрсәтелә. Предприятиедә буыннар бәйләнеше өзелмәсен, яшьләр үз геройларын, завод, район һәм бөтен ил тарихын белсен өчен тырышалар.

УСЗ картларга, балалар йортларына, мөмкинлекләре чикләнгән балаларга ярдәм күрсәтә. Йөрәк кушуы буенча хәйрия эшләрендә һәм Татарстан Республикасындагы тормыш шартларын яхшырту чараларында катнаша.

«ТАТАВТОМАТИЗАЦИЯ». ОЗАККА ИСӘПЛӘНГӘН УҢЫШ

«ТатАвтоматизация» ҖЧҖнең тарихы 1957 елдан – «Бөгелмәнефть» нефть эшкәртү идарәсе каршында автоматика һәм Контроль-үлчәү пункты цехы барлыкка килгәч башлана. Нефть чыгару процесслары катлаулану «Татнефть» берләшмәсе нефть һәм газ чыгару идарәләренең Җитештерүне автоматлаштыру цехларын булдыру кебек перспективалы юнәлеш буенча эшчәнлегенең үсешенә китерә.

2009 елда «Татинтек» Компанияләр Төркеме оеша, ул җитештерүне автоматлаштыру цехы нигезендә барлыкка килгән «ТатАвтоматизация» ҖЧҖ дә үз эченә ала. Хәзерге вакытта предприятиедә 650 кеше эшли, шуларның өчтән бере – инженер-техник хезмәткәрл.

2018 елгы «Россиянең иң яхшы 100 товары» бәйгесе «Сыйфат + куркынычсызлык = көндәшлеккә сәләтлелек!» шигаре астында үтте.

Әлеге формула «ТатАвтоматизация» ҖЧҖ предприятиесенең миссиясенә авазлаш. Ул заказ бирүче куйган бурычларны моңа кадәр тупланган инженерлык-техник һәм иҗади тәҗрибәсенә таянып хәл итә.

Быел «ТатАвтоматизация» компаниясе «Россиянең иң яхшы 100 товары» программасының «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары һәм хезмәт күрсәтүләре» төбәк этабында «Проектлау, янгын-саклау системаларына хезмәт күрсәтү, үтеп йөрү, видеокүзәтү контроле» номинациясендә лауреат булды.

Куркынычсызлык системалары буенча хезмәтләр комплексы: проектлау, монтажлау һәм эшләтеп җибәрү, көйләү эшләре, янгын-саклау автоматикасына техник яктан хезмәт күрсәтү, үтеп йөрү, видеокүзәтү контроле системалары – үз эшенең осталарыннан җыелган команда алып барган эшчәнлекнең бер юнәлеше бу.

Предприятие күрсәтә торган хезмәтләр өлкәсенә түбәндәгеләр дә керә:

- нефть чыгару һәм куу скважиналарын, төркемләп үлчәү җайланмаларын, нефть һәм газ коммерциясен хисаплау төеннәрен, сыгучы насос станцияләрен, тармаклы насос станцияләрен, нефтьне алдан әзерләү һәм сатар өчен әзерләү җайланмаларын, махсус техниканы, нефть, су җыю һәм аларны транспортлауның торбаүткәргеч системаларын автоматлаштыру һәм телемеханикалаштыру һ.б.
- нефть чыгару предприятиеләрен автоматлаштыру чараларына техник яктан хезмәт күрсәтү һәм аларны метрологик яктан тәэмин итү;
- проектлау-эзләнү эшләре;
- теләсә кайсы җитештерүченең, шул исәптән үзендә җитештерелгәннәрнең дә, тирәннән үлчи торган комплексларын монтажлау, сүтү һәм ремонтлау-төзекләндерү эшләре алып бару;
- куркынычсызлык системаларын (СВН, ПОС, СКД) төзү, монтажлау һәм эшләтеп җибәрү.

Шамил Бикколов, «ТатАвтоматизация» ҖЧҖнең башкарма директоры:

– Предприятие үсешен дәвам итә. Без яңа продуктлар эшләдек: скважина чыгарган продукцияне исәпләүнең күчерелмә төене (ПУУ ДСП), контрольдә тотыла торган «Акира» пунктын, ТА-РЭП-01R-22 интеллектуаль идарә итү станциясен.

Базар икътисады шартларында югары икътисадый нәтиҗәләргә ирешергә теләгән һәрбер предприятие алдында бер-бер артлы хәл ителергә тиешле ике бурыч тора: базарда үз урыныңны булдыру һәм анда озак вакытлар уңышлы эшли торган ролендә калу. Без нефть әзерләү буенча 19 эре объектка хезмәт күрсәтәбез. «Татнефть» ГАҖ, «Роснефть» НК, «Лукойл» ГАҖ, Россия территориясендә Волгоград өлкәсеннән алып Сахалинга һәм Комсомольск-на-Амуре якларына кадәр кече нефть компанияләре объектларында эшлибез.

2017 елда Бузулукта «Оренбургнефть» ГАҖ объектларында янгын сигналлары һәм кисәтү системаларының автоматлаштырылган җайланмаларына техник яктан хезмәт күрсәтү өчен куркынычсызлык системаларын тәэмин итү участогы булдырылды.

Безнең предприятие белгечләре комплекслы куркынычсызлык системалары җиһазлары җитештерүчеләрдә даими рәвештә белемнәрен күтәреп тора. Безнең компетенцияләр монтаж белән көйләү эшләрен башкарып чыгарга гына түгел, шулай ук куркынычсызлыкның интеллектуаль системаларын да эшләп, кулланылышка кертергә мөмкинлек бирә. Техник яктан хезмәт күрсәтү буенча тупланган тәҗрибә заказ бирүченең объектларында куркынычсызлык мәсьәләләрен комплексы рәвештә хәл итүне гарантияли.

Без даими рәвештә үзебезнең югары һөнәр осталары булуыбызны раслап торабыз, мәсәлән, «ТатАвтоматизация» ҖЧҖнең сәнәгать автоматлаштыру белгече узган «Яшь һөнәр осталары» (WorldSkillsRussia) төбәк чемпионатында өченче урынны алды. Теләсә кайсы бурычны хәл итүгә иҗади якын килү, яңача фикерләү, проблемага принципиаль рәвештә башка күзлектән карау «ТатАвтоматизация» ҖЧҖ белгечләренә һәрвакытта да ярдәм итте.

Реклама Фото «ТатАвтоматизация» ҖЧҖнән алынды

ГРАНТ: ҺӘР НӘРСӘНЕҢ ҖАЕ БАР...

Узган санда Питрәч районының Күн авылы фермеры Илгизәр Рәфыйков турында язган идек. Ул ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына үпкә белдерде: «Грант алырга дип җыйган документларны соңгы көнгә кадәр тоттылар да кире кайтардылар», – диде. Бактың исә, Күн фермеры 2004 елның апреленнән 2017 елның декабренә кадәр шәхси эшмәкәр булып теркәлгән. Ә андый очракта өч ел узгач кына фермерлык эшен башлау өчен грантка өмет итеп була. Бу шартлар «Лизинг грант» программасына туры килә, ә ул Икътисад министрлыгына карый. Без ТР Икътисад министрлыгы белән элемтәгә кердек. Алар Күн фермерына ярдәм итәрбез, дип вәгъдә бирделәр.

Бу санда ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы фермерларга бирә торган грант, субсидияләрнең иң киң таралганнары турында язарга булдык.

Сарман районы Иске Имән авылының иң эре фермеры – Галиевлар ихатасы. Гаилә 2016 елда 2 миллион сум грант откан.

Автор:
Руфия Фазылова

«ЭШ БАШЛАУЧЫ ФЕРМЕР» ПРОГРАММАСЫ

Программа 2012 елдан бирле эшли.

«Эш башлаучы фермер» программасында катнашу өчен арендага алынган яки үз җирең, күпмедер техникаң, махсус белемең булу шарт. Һәм салым инспекциясендә теркәлү дә зарур. Шулай ук шәхси эшмәкәр булгансың икән, эшеңне япканнан соң, өч ел вакыт узарга тиеш.

Сөтчелек һәм итчелек тармагында грантның күләме 1-3 млн сумны тәшкил итә. Фермер булып теркәлгәннән соң ике ел (24 ай) эчендә грантка дәгъва кыларга мөмкин. Әгәр ике елдан артыграк вакыт үткән икән, программа «эш башлаучы» түгел, ә «үсештәге фермер» буларак теркәлүне күздә тота. Аның шартлары бүтән.

Шуны да искәртәсе килә: кайсы гына грантка дәгъва кылсагыз да, иң беренче эш итеп, бизнес-план төзелә. Ә аның өчен фермер башлангыч капиталы булуын күрсәтергә тиеш. Мисал өчен, җирне эшкәртергә – техникасы, җайланмалары һ.б. Теләк кенә җитми, бизнес-планны тикшергәндә комиссия, иң беренче чиратта, фермерның мөмкинлекләрен дә исәпкә ала.

«ГАИЛӘ ФЕРМАСЫ»

«Гаилә фермасы» программасының суммасы зуррак. Бер фермерның 7 млн сумга кадәр грант оту мөмкинлеге бар. Таләпләре нигездә «Эш башлаучы фермер»ныкы кебек үк. Тик кайбер аермалар да бар. Мисал өчен, проект 8 елга дип төзелә. Фермер яки аның гаилә әгъзалары «Эш башлаучы фермер» грантын моңарчы алмаган булырга тиешләр. Тагын бер мөһим шарт: бу төр грант үсемлекчелек тармагына бирелми.

«Гаилә фермасы» программасында, аны откан очракта, терлекнең баш саны түбәндәгечә булырга тиеш:

– 50дән күбрәк сыер;
– 100 баш мөгезле эре терлек;
– 200 баш ат;
– 300 сарык;
– 100 баш савым кәҗәсе;
– 10 мең баш йомырка сала торган тавык;
– 8 мең баш каз;
– 10 мең баш үрдәк.

Әлеге программада катнашучы фермерның бу өлкәдә ике ел эшчәнлеге, ягъни мал үстерү тәҗрибәсе булуы да шарт. Мисал өчен, моңа кадәр ит, сөт белән бәйле продукция җитештереп саткан булырга мөмкин ул.

Фермер грантны ферма төзергә ала икән, бинаның проекты тәкъдим ителгән булырга тиеш. Алай гына да түгел, аңа экспертиза үткәрелгән, төзелеш буенча рөхсәт кәгазе алынган булу да шарт.

«АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ КООПЕРАТИВЫ»

Авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә юнәлдерелгән иң күләмле грант. Аның суммасы – 70 млн сумга кадәр. Тәҗрибә буларак 2018 елда гына эшли башлады. Һәм әйтергә кирәк, әлеге программага зур өметләр баглыйлар. Берничә хуҗалык берләшеп эшләүгә корылган ул. Шулай ук берничә тармакны да берләштерә.

«Авыл хуҗалыгы кооперативы» программасында катнашуның шартлары түбәндәгеләр:

– фермер булып теркәлгәнгә, кимендә, 12 ай вакыт узган булу;

– ким дигәндә, 10 юнәлештә эш алып барылырга тиеш. Мисал өчен, ит һәм сөт җыю, саклау, эшкәртү, үсемлекчелек, тире, йон эшкәртү, дару үләннәре җыю, сату һ.б.

– нигезләнгән бизнес-планның булуы.

Кооператив әгъзалары эшкә 9-15 процент үз өлешен кертергә тиешләр. Калганы субсидия белән түләнә.

Грант алганнан соң, кооператив ел саен үзенең эш нәтиҗәләрен комиссия әгъзаларына тәкъдим итәргә бурычлы. Шулай ук һәр отылган өч миллион сумга бер эшче алырга да тиешләр.

Грант акчасын төзелешкә, реконструкциягә, продукция җитештерүгә, саклау, эшкәртү объектларын булдыруга тотарга мөмкин. Шулай ук махсус транспорт сатып алу да рөхсәт ителә.

Республика буенча 2018 елда шундый 100 гә якын кооператив төзелде, моның өчен 300 млн сум акча бүленеп бирелде.

СЫЕР, КӘҖӘ ИСӘБЕННӘН – СУБСИДИЯ

2016 елдан бирле савым сыерлары һәм кәҗәләре булган хуҗалыкларга дәүләт субсидия түли башлады. Агымдагы елда аның күләме – бер сыерга 2 мең сум, ике сыер тотучыларга – 3 мең сум, аннан да күбрәк очракта 4 мең сум. Кәҗәләргә 1 мең сум исәбеннән бирелә.

Субсидияләр алу өчен башта җирле авыл җирлеге идарәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ни өчен дигәндә, башта авылның һәр хайваны электрон хуҗалык китабына кертелә. Сыер теркәлгән булса гына, авыл җирлеге администрациясе халыктан субсидия түләүгә гариза ала. Гражданнар, үз чиратында, сыерларның баш санын шул санда саклап калуга гариза яза. Димәк, терлекләрне суярга ярамый һәм аларның сөте сатылырга тиеш. Субсидия терлекләрнең баш санын саклап калу һәм арттыру өчен бирелә.

Шуннан соң инде авыл җирлеге администрациясе реестр төзи. Ул районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә тапшырыла. Алга таба район буенча җыелма белешмәлек төзелә. Барлык мәгълүматлар да ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына тапшырыла. Нигездә ул ике көн эчендә карала. Тикшерү тәмамланганнан соң, түләү түләнә. Субсидияне кулга алыргамы яисә счетка күчерергәме – моны мөрәҗәгать итүче үзе хәл итә. Бу гаризада алдан ук күрсәтелергә тиеш.

ГРАНТ ШАРТЛАРЫ:

- салым органына әҗәтең булмау;
- фермер булып теркәлгәнче, шәхси эшмәкәр булгансың икән, аны япканнан соң өч ел вакыт узарга тиеш;
- грантка дәгъва кылучы затның ирегеннән мәхрүм ителмәгән булуы зарур;
- авыл җирендә яшәргә тиеш;
- авыл хуҗалыгы тармагында эшләү тәҗрибәсе булу;
- теге яки бу гражданның хуҗалыгы аның соңгы биш ел эчендә бердәнбер эш урыны булып исәпләнүе шарт;
- биш ел эчендә алынган һәр миллион сумга бер эшче тотарга, аңа минималь хезмәт хакыннан ким булмаган (7,5 мең сум) суммада акча түләнергә тиеш.

ФЕРМЕР КОЛАГЫНА:

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы оештырган конкурсларда катнашу өчен, башта районның авыл хуҗалыгы идарәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк. (Турыдан-туры ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгына да барырга була, әлбәттә. Тик беренче вариант фермер өчен уңайлырак).

Төп документлар:

- фермерлар конкурсында катнашу өчен анкета, гариза;
- бизнес-план;
- чыгымнар планы;
- резюме;
- катнашучының бурычлары.

САННАР:

- 2019 елда ТР агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү максатларына 10,7 миллиард сум акча бүленәчәк. Шуларның 5 миллиард сумы – РФ бюджетыннан, 5,7 миллиард сумы – ТР бюджетыннан.
- Авыл хуҗалыгы тармагын үстерүгә юнәлдерелгән федераль дәрәҗәдәге – 16, республика күләмендә 27 төрле программа эшли, ә бу грантлар, субсидияләр саны дигән сүз.
- Республикада рәсми рәвештә 5 меңнән артык фермер теркәлгән.

ТАВЫШ **БИРЕП ЯҢАРУ**

Татарстан гражданнарның үзара салымы буенча үткәрелгән референдумнар нәтиҗәсендә җыелган акча күләмнәре буенча илнең башка төбәкләреннән алда бара. Югары Ослан муниципаль районының берничә авыл җирлеге мисалында «Татарстан» әлеге механизм буенча бюджетка бирелгән һәрбер сумга гражданнарның нәрсә алуына төшенергә тырышты.



Автор:
Ксения Сёмина

Теманы ныклабрак ачыклау өчен без башта Печищи авыл җирлегенә юл тоттык, аңа әлеге авылдан тыш кечкенә генә Захваткино авылы да керә. Монда тавыш бирү, нинди генә тема көн үзәгендә тормасын, һәрвакыт диярлек район буенча иң түбәне. Әчтән генә сорауларыма тискәре җаваплар алачагыма әзерләнеп барам. Тик юкка борчылганмын икән.

ЯКТЫРАК БУЛСЫН!

Печищи авыл җирлегенең яшь, энергиясе ташып торган башлыгы

Леонтий Яковлев безне җирлекнең истәлекле урыны – «Гремячка» чишмәсе янында каршы ала. Ике ел элек меценатлар чишмәнең иске «өен» һәм купельне алыштыра. Быел Качману көнендә бәкегә чумарга теләүчеләрнең саны Введенская Слобода тирәсендәге Идел ярындагыга караганда да күбрәк булгандыр.Леонтий Владимирович суны татып карарга тәкъдим итә. Ул таудан агып төшә, шуңа күрә артезиан суына караганда җылырак һәм чыннан да бик тәмле икән.

– Үзара салым буенча референдумга моның нинди мөнәсәбәте бар соң? – дип сорыйм җирлек башлыгыннан.

– Турыдан-туры, – ди, бер дә аптырап калмыйча, Леонтий. – Алдагы ике елда үзара салым акчалары ярдәмендә без су белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл иттек, шул исәптән Гремячкада су алу урынын тәртипкә китердек.

Күп еллар дәвамында Печищида су белән җитди кыенлыклар булган икән. Ярты гасырлык юбилеен билгеләп үткән җирле суүткәргечкә капремонт ясалмаган диярлек. Кешеләр Гремячкага суга йөрергә ияләшкәннәр... Әмма хәтта Печищи краннарына суны кайтару кебек максат куелган 2015 елдагы беренче референдум да җиңел генә үтми. Кешеләрдә механизмның үзе шик уята, һәм җыелган акчалар чыннан да суүткәргеч челтәрен ремонтлауга тотылырмы-юкмы дип уйлыйлар.

– Акчаларны бик озак җыйдык, ләкин бу акчалар суүткәргечнең иң проблемалы берничә йөз метрын тәртипкә китерергә генә җитте. 2017 елда халык дәртләнебрәк тавыш бирде, бөтен сумманы диярлек бик тиз тупладык. Бу акчаларга резервуарны алыштырырга ниятлибез, – дип сүзен дәвам итте җирлек башлыгы.

Без Леонтий Владимирович офисына юл тотабыз. Анда башлыкны үз йомышлары белән килгән Александр Кличёв һәм Печищи ФАП мөдире Нина Галимҗанова көтеп тора иде.

Аларның референдумда катнашу-катнашмаулары белән кызыксынам. Быел яктырту системасын яңарту өчен һәр кешедән 150 сум акча җыярга булганнар. Пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән һәм көндезге бүлектә укыган студентлардан (аларның күбесе Казанда укый) 75 сумнан җыярга сөйләшкәннәр.

Фото: Александр Ефремов

– Үзең өчен, туган авылыңны матурлау өчен 150 сум бирмәскә соң! – дип үз фикерен белдерә **Александр Иванович**. – Урамнарда караңгы бит!

– Бөтенләй караңгымыни?

– Әйе, урам башында фонарь һәм урам ахырында, минем өй янында – дөм караңгы… Ә тирә-якта – чокыр-чакыр, тыкрыклар, егылып, аягыңны сындырырга була…

– Алай булгач, авылыгызда референдумга халык аз килә икән соң? – дип, саклык белән генә сүз катам. Тавыш бирергә хокукы булган җиде йөзгә якын кешенең яртысыннан аз гына күбрәге референдумга килгән. Шул яртының яртысы гына урамнарны яктырту системасын яңартуны яклап чыккан.

– Кайберәүләр болай дип фикер йөртә: минем өй янында ут бар бит, миңа кирәкми. Ник мин башкалар өчен түләргә тиеш әле? Кемдер ял көнне өенннән чыгарга иренә. Күпләр авылда теркәлгән, үзләре шәһәрдә яши. Яисә шунда көн саен эшкә йөри, – дип аңлата **Нина Галимҗанова**. – Әле тагын шәһәрдә теркәлеп, монда яшәгән «дачниклар» бар, алар тавыш бирә алмый. Ләкин алар үз теләкләре белән акча бирәләр – аларның акчаларына дәүләт субсидиясен өстәп булмавы гына кызганыч.

Кире кайтканда Леонтий Владимирович безне Печищи мәктәбе белән таныштыра. Кар көртләрен ерып барып, спорт мәйданчыгы янында тукталабыз. Леонтий Владимирович, сорау биргәнемне көтмичә, сөйли башлый:

– Минем сезгә авылданиләр эшләнгәнлеген күрсәтәсем килә. Яхшы яктан, әлбәттә, – дип шаяртып ала ул, минем аптырабрак калганымны күреп. – Спорт мәйданчыгын без дәүләт программасы буенча ясадык, район бюджеты акчаларына 800 метрга якын юлга вак таш түшәдек – аның буенча тауга йөк машиналары ашлык амбарына күтәрелә, мәктәп янындагы мәйданчыкны һәм керү юлын асфальтладык. Әгәр бөтенесен дә исәплибез икән, 2018 ел эчендә 11 миллион сумнан артык субсидия алган булып чыгабыз. Бу барлык спонсорлык акчаларын кертеп исәпләгәндә – үз авылларына актив ярдәм итүче берничә эшкуар яши биредә. Үз көчебез белән генә моның кадәр эшне эшләп бетерә алмаган булыр идек – Печищи авыл җирлегенең бюджеты – 2,3 миллион сум… Димәк, үзара салым – инфраструктураны яхшырту инструменты гына түгел. Бу гражданнарны авыл эшләренә җәлеп итү ысулы да.



БЕРДӘМ ТАВЫШ ҺӘМ ХӘТЕР

Югары Ослан районы башлыгы урынбасары **Сергей Осянин** белән бергә Борнаш авыл җирлегенә барабыз. Республика буенча алганда үзара салым темаларының күпчелеге якынча бертөрле – юлларга вак таш түшәү, зиратларны коймалау һәм тәртипкә китерү, урам яктырткычлары урнаштыру. Шулай да Борнаш халкы үз юлы белән бара.

– Көзен һәм язын безне су баса дияргә була. Юлны аркылы чыгып булмый, урап узарга ерак. Ә аръяктагы мәктәпкә балалар йөри, – ди авыл җирлеге башлыгы Сергей Бурукин.

Без тирән булмаган, әмма киң чокыр аркылы салынган тимер күпер уртасында торабыз. Күперне агымдагы елда җыелган үзара салым акчасына төзегәннәр. Акчалар – бюджеттан алынган субсидияләр белән бергә 430 мең сумга якын – чокырның текә ярларына алып менүче ике киң сукмакка таш җәяргә дә җиткән.

Аннан алданрак үткән референдумнарда Борнаш авыл җирлегендә яшәүче халык юлларны рәтләргә сөйләшкәннәр. Әлеге акчалар хисабына (һәр кешедән 500әр йөз сум) Татар Борнашы, Каинки, Юматово авылларындагы юлларга вак таш түшәгәннәр.

Сергей Бурукин безне авыл үзәгенә таба алып бара. Каршыбызда – Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә куелган ачык яшел төстәге истәлек һәйкәле. Аның артында агач чиркәү күренә. Чиркәү төзелешенә акчаларны хәйриячеләр – борнашлылар Мария һәм Илгиз биргән. Яңа чиркәү фонында ярты гасыр элек төзелгән һәйкәл бик тыйнак күренә.

– Нәкъ менә быелгы референдумда барысы да диярлек 300әр сум акча җыярга һәм һәйкәлне яңартырга дип тавыш бирделәр. 2020 елга – Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгына һәйкәлне матурлыйбыз. Без әлеге көнне лаеклы каршыларга телибез. Җирлектән киткән 600дән артык кеше яу кырларында ятып калган. Кешеләр туганнарының сугышта катнашуы турындагы документларны китерәләр һәм мемориаль такталарга аларның да исемнәрен кертүне үтенәләр. Шуңа күрә һәйкәл безнең барлык авылдашларга – сугыштан кайта алмаганнарга да, яу кырларыннан җиңү белән кайтып керә алучыларга да, тыл хезмәтчәннәренә һәм сугыш чоры балаларына да багышлана, – ди Сергей Бурукин.

ИРТӘГӘГЕ КӨН ЮЛЛАРЫ

Татар Борнашыннан соң Рус Макылына – Макыл авыл җирлегенең административ үзәгенә дә сугылырга уйладык. Монда үзара салым турындагы карар референдумнар аркылы түгел – чагыштырмача яңа ысул – гражданнарның җыеннарын оештыру ярдәмендә кабул ителгән. Юлда Сергей Осяниннан район халкының үзара салымга мөнәсәбәте турында сораштырам.

– Безнең асылда шәһәр яны территориясенә керүебезне исәпкә алырга кирәк. Шуңа күрә дә район буенча уртача тавыш бирүнең республиканыкыннан түбәнрәк – 60–62 процент (2018 елгы референдумнарда Татарстан буенча тавыш бирү уртача 69 процентка якын – ***ред. иск.***) булуын аңларга кирәк. Быел бюллетеньнәрдә күрсәтелгән максатларга 82 процент катнашучы тавыш бирде. Димәк, беренчедән, авыл җирлекләре башлыклары темаларны формалаш-

тырганда халык ихтыяҗларыннан чыгып эш иткәннәр, икенчедән, гражданнар референдумнарга уңай карыйлар, – ди Сергей Викторович. 2019 елда Югары Ослан районында үзара салым программасы 19 авыл җирлегенең 17сендә тормышка ашырылачак, дип тә өсти. Референдумнар Югары Ослан һәм Коргуҗа авыл җирлекләрендә үткәрелмәгән, чөнки беренчесендә узган елгы референдумда кабул ителгән сумманы җыеп бетерергә һәм ике зыяратны тәртипкә китерергә уйлыйлар, икенчесендә шулай ук башланган проектны төгәлләргә һәм үзара салым акчаларына янгын депосы төзергә ниятлиләр икән. Барлык проектларның арзан тормавына бәйле рәвештә бөтен сумманы җыярга кирәк. Эш шунда ки: 1 апрель – республика Финанслар министрлыгы субсидияләрне исәпли (һәр җыелган сумга 4 сум исәбеннән) һәм күчерә торган көнгә әлеге җирлекләр буенча җыемнар 50–60 процентны тәшкил иткән. Ә 1 апрельдән соң җыелган акчаларга субсидияләр бары тик киләсе елның февралендә генә килә.

– Җыеп кына әйткәндә, 1 апрельгә кадәр никадәр күбрәк акча җыйсаң, төзелеш сезоны ахырына шулкадәр күләмдәге эшләрне башкарып чыгарга була. Үзара салым акчаларын тоту процедурасы катлаулы. Акчалар тотылачак эшнең теләсә кайсы төре өчен авыл җирлеге проект һәм смета документациясен эшләргә тиеш, ә аны тиешле инстанцияләрдә раслаганнан соң – проектны гамәлгә ашыруга тендер игълан итәргә кирәк, – дип аңлата Сергей Викторович.

Рус Макылы авыл советы янында безне җирлек башлыгы Алинә Матвеева каршы алды. Озакка сузмыйча, 2019 елгы үзара салым акчалары тотылырга тиешле урыннарны карарга юнәлдек. Юлда референдум урынына ни өчен халык җыеннары уздыруларын сораштырам.

– Референдум, беренчедән, җирлеккә кергән барлык торак пунктларның уртак максатлары өчен, икенчедән, җыемнарның күләме – суммасы өчен тавыш бирүне күздә тота. Ә халык җыеннары процедурасы тавыш бирү вакытында турыдан-туры максатны да, сумманы да сайларга мөмкинчелек бирә. Кечкенә авыллар өчен бу бик кулай механизм. Сәеттә, мәсәлән, 76 гражданның 40ы тавыш бирүдә катнашты, – дип сөйли Алинә Илшатовна. – Алар авылдагы юлларны ремонтларга дип, 1000әр сум акча җыярга карар иттеләр. Анда нигездә пенсионерлар яши, әмма алар бик актив. Дачниклар да үзләреннән өлеш кертергә вәгъдә иттеләр. Клянчино авылында тавыш бирергә хокукы булган кешенең 78е, балалар мәйданчыгы төзергә дип, 500әр сум акча тапшырырга карар кылды. Татар Макылында тавыш бирергә хокуклы 121 кешенең җыенда 95е тавыш бирде. Зыяратка коймa тоту максатына 300әр сум акча җыярга булдылар. Дачниклар шулай ук үз өлешен кертәләр, дөрес, аларның акчаларына субсидияләр өстәлми, гәрчә без моны гадел дип санамыйбыз – алар да безнең территориядә хуҗалык тоталар һәм авылдагы уңайлылыклардан файдаланалар.

Халык арасында «Сельхозтехника» дип йөртелгән «микрорайон»га җитәбез. **Алинә Илшатовна** машинасын туктата,вак таш түшәлгән юлга басабыз.

– 2016 елда үткәрелгән беренче референдум нәтиҗәсендә җыелган үзара салым акчаларына су алу урынын төзекләндердек, резерв насослар сатып алдык, скважиналар төбенә бетон җәйдек – су белән тәэмин итү проблемасын тамырдан хәл иттек. 2017 елда юлларны тәртипкә китерергә ниятләдек. «Сельхозтехника» районы 80 нче елларда барлыкка килгән, шул ук исемдәге предприятие белән бергә. Монда берничә йөз кеше яшәде, ә юллар беркайчан да булмады. Һәм менә үзара салым акчаларына без юлларны рәткә салдык, – дип аңлата Алинә Илшатовна.

Рус Макылы авылының «тарихи» чигенә якынлашабыз. Алда, кар каплаган кыр аркылы – яңа микрорайон.

– Балалар бакчасы һәм мәктәп бу якта, ә теге якта бик күп яшь гаилә яши. Киләсе елның февралендә үзара салым акчаларының калганын алып, юл салачакбыз, – ди Алинә Матвеева.

Кар салган кырга күз атып, яңа юлның ничегрәк узачагын күзалларга тырышкан арада яныбызга күрше йортта гына яшәүче апа килеп баса. Яңа танышым Анна Алексеевнадан үзара салым программасына мөнәсәбәтен сорыйм.

– Уңай, башкарылган эш күзгә күренә. Алинә Илшатовна молодец ул! Узган ел авыл юлларына таш җәябез дигән максатны куйдык – эшләнде. Бик уңай хәзер, туфлидән йөрсәң дә була… Нинди вакытлар бар иде бит… – ди **Анна Алексеевна**. – Ә хәзер төзекләндерү тулы көченә алып барыла. Файдалы эшләргә тотылган акча җәл түгел. Мин хуплыйм!

Әгъзам Гобәйдуллин,
«Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе:

– Дәүләт тарафыннан күрсәтелгән ярдәм шактый киң күләмдә булса да, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен муниципаль берәмлекләрнең җирле бюджетларында акча һәрвакытта да җитеп бетми. Федераль законнарга ярашлы рәвештә, мондый очракларда хакимиятләр үзара салым процедурасын куллана алалар. Татарстанда әлеге программа республика Президенты Рөстәм Миңнеханов хуплавында 2013 елда старт алды. Программаның асылы гади: авыл кешесеннән җыелган һәр бер сумга республика тагын дүрт сумны өсти. Ләкин бу акчаларны референдум нәтиҗәсендә генә бүлеп бирергә мөмкин. Референдумда һәр гражданин ирекле рәвештә авыл җирлеген үстерү сораулары буенча үз фикерен белдерә һәм аны акча белән ныгыта. Үзара салымга караган төп сорауларны һәм җыелачак акча суммасын билгеләү өчен авыл җирлеге башлыклары һәм депутатлар халык белән очрашулар үткәрә. Акчаларны тоту үтә күренмәле булырга тиеш: чыгымнар турында хисап массакүләм мәгълүмат чараларында басыла һәм халыкка төбәк бюджетыннан акча алынган елдан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмый тәкъдим ителә. Бүген авыл кешеләренең зур күпчелеге үзара салымда актив катнаша, ә Татарстан тәҗрибәсе федераль дәрәҗәдә өйрәнелә, башка төбәкләргә үрнәк итеп куела. Исегезгә төшерәм: үзара салым процессы ирекле һәм ачык. Әгәр халык референдумга каршы чыга икән – бу аларның ихтыярында.

СТРАТЕГИЯ – МИНЕМ ФИКЕР

Журналыбызның соңгы саннарының берсендә ТР Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев белән язма бастырган идек. Төп темасы – Татар халкы үсеше стратегиясен әзерләү. Әлеге әңгәмә вакытында ул: «Массакүләм мәгълүмат чаралары, Интернет челтәре аша һәркем әлеге документка кагылышлы теләк-тәкъдимнәрен язып җибәрә ала», – дигән иде.

Татар халкы үсеше стратегиясе турында фикер йөртүчеләр шактый. Шул исәптән – чит өлкәләрдә дә. «Татарстан» журналы аларны «чүпләп» биреп барырга булды.

«МЕСКЕНЛЕК – ЯРЛЫЛЫКТА!»



Иниятулла Кутуев,
Ленинград өлкәсе,
Тосно шәһәренең «Изге юл» татар җәмгыяте җитәкчесе

– Без теләк-тәкъдимнәребезне язып, Бөтендөнья татар конгрессына җибәрдек. Татарстаннан читтә яшәүче татар буларак, беренче әйтәсе килгән сүзем шул: матди база булмый торып, милләтебезне саклау, яклау турында сүз алып барып булмый. Тосно шәһәрендә егерме елдан артык татар җәмгыятен җитәклим. Болар барысы да үз теләгебез белән эшләнә, җәмәгать эше ул. Үз акчаларыбызга җирле татарларны җыеп, Мәүлид кичәләре, Корбан ашлары, Сабантуйлар үткәрәбез. Соңгысына Казаннан да кунаклар килә. Тик, яшеренбатырын түгел, акчасыз булмый, чөнки килгән кешене кунак итәргә кирәк. Татарның төп сыйфатларыннан берсе – кунакчыллык бит.

Иң төп проблема – бинабыз юк. Нинди генә чара үткәрә башласак та, шуннан интегәбез. Бина эзлибез. Музей, мәктәп, мәдәният йорты – һәрберсенә башны иеп кереп, буш вакыт сорыйбыз. Чараның зурлыгына карап инде... Мәсәлән, Тукай кичәсенә кеше күп җыела, сәхнә кирәк. Музей белән генә булмый. Шуңа мәдәният йортын сорыйбыз. Бик мөһим тагын бер чара – егерме елдан артык Муса Җәлилне искә алу кичәсе үткәрәбез. Тосно шәһәре – Муса Җәлил сугышкан, кулга алынган район. Февраль аен «Җәлил айлыгы» дип атыйбыз. Ул көннәрдә татарлар гына түгел, башка милләт вәкилләре дә җәлилчеләрнең батырлыгын тагын бер кат искә төшерә.

Әйе, зарланмыйм, шәһәрдә безгә каршы килгән кеше юк. Алдан килешеп, чаралар үткәрергә буш урыннар табабыз. Тик... болар безнең халыкның дәрәҗәсен төшерә. Соранып йөрү татарга хас сыйфат түгел. Шуның өчен чит төбәкләр өчен иң мөһим әйбер – татар стилистикасын кертеп, йортлар төзү. Мисал өчен, егерме ел эчендә бик күп китаплар җыелды. Менә аларны кая куярга? Ул китаплар минем аш бүлмәсендә, башкаларның фатирларында шулай тора. Ә бит аларның урыны – китапханәдә, алар милләттәшләребезгә хезмәт итәргә тиеш.

Аңлыйм, һәр төбәктә Татарстан йорт сала алмый, чөнки аның да үз җире, үз халкы бар. Ленинград өлкәсе җитәкчелеге дә моны күтәрмәс дип уйлыйм. Ни өчен дигәндә, биредә, татардан кала, тагын финнар, немецлар, мукшылар – башка милләтләр бар. «Ни өчен татарларга гына шундый мөнәсәбәт?» – дип, алар тавыш чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә татарның эшмәкәрләрен, бай улларын тартырга кирәк, дип уйлыйм. Татнефть, башка эре оешмалар бар. Менә шулар зәкәт акчасыннан аерып булса да, аерым бер сумма күчерсәләр, Россиянең төрле шәһәрләрендә шундый йортлар салып чыгарга мөмкин булачак. Моны күреп, башка эшмәкәрләр дә әлеге изге эшкә кушылыр, бәлки.

Татар йорты башка милләтләр алдында безне берничә баскычка күтәрер иде. Күз алдына китерәсезме: рус милләтеннән булган ике кеше сөйләшә: «Бүген Татар йортында күргәзмә (яки концерт), барып кайтыйк. Соңыннан шундагы татар кафесына кереп, милли ризыклар белән сыйланырбыз...» Менә шул рәвешле башка милләтләр белән дә араны якынайтыр идек. Безнең мәдәният, көнкүреш белән танышкан кешеләр инде ул чакта мөселманнарны төрле экстремист төркемнәр белән дә бутамас иде.

Җыелыр урын булмау бер Ленинград өлкәсендә генә проблема түгел, башка чит төбәкләрдә дә шул ук хәл. Россия шәһәрләрендә, чит илләрдә татар йортлары төзесәк, бик күп проблемалар хәл ителер иде, дип уйлыйм. Аны берничә катлы итеп ясап, балаларга ана телен өйрәтү өчен кечкенә мәктәп, музей, хәтта кунакханә – барысын да эшләргә була.

Әгәр син ярлы икәнсең, димәк син мескен дә. Шул мескенлегең белән гомер итәсең. Ә мескен кешене яратмыйлар. Димәк, татар үзен бай итеп күрсәтергә тиеш. Моны күреп, яшьләребез дә уяныр иде. Аларның бит гаярь, көчле буласылары килә. Ә без нәкъ шундый халык...

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Катлаулыны **НИЧЕК** гадиләштерергә

Татарстан балыкчылары
Идел һәм Чулманда **КҮПМЕ** балык тотканнар

ӨЙЛӘР **ЯКТЫ** БУЛСЫН!

Төзелеш – мәшәкатьле эш, документларны рәсмиләштерү һәм коммуникацияләргә кушылу процедураларын гадиләштерү бу яктан кешеләр өчен бик зур ярдәм. «Челтәр компаниясе» ААҖ клиентка йортны һәм җир кишәрлегендәге башка объектны электр челтәренә тоташтыруга минимум вакыт сарыф иттерү юнәлешендә актив эшли.

Татарстанда индивидуаль һәм шәхси йорт төзелеше үз әйләнешләрен арттыра бара. Федераль законнарга ярашлы рәвештә, объектны электр челтәрләренә технологик тоташтыру процедурасын һәр төзүче (милек иясе) узарга тиеш. Клиентлар өчен килешүләрне төзү процедурасын тиз һәм уңайлы итү максатыннан «Челтәр компаниясе» ААҖндә җиде хезмәт күрсәтү үзәге ачылды: Казанда, Түбән Камада, Яр Чаллыда, Әлмәттә, Бөгелмәдә, Алабугада һәм Чистайда.

ГАРИЗА БИРҮ – ТИЗ...

Компаниянең Җиңү проспекты, 47 адресы буенча урнашкан Казан офисында кеше күп – монда килүче гариза бирүчеләрнең саны аена 2 меңнән артып китә. Әмма монда чират күренми. Күчемсез милекнең иясе алышу, югалган документларны торгызу, электр челтәрләренә техник тоташу кебек мөрәҗәгатьләр тиз карала. Кабул итү вакыты – 15–20 минут. Сүз уңаеннан, хәзерге вакытта үзәктә клиент турында мәгълүматны автомат рәвештә кертеп, хезмәт күрсәтү вакытын 5–10 минутка кадәр кыскартырга мөмкинлек бирүче сервисны гамәлгә кертү өстендә эшлиләр.

– Мин Биектау районында участок алган идем, ләкин үзем монда, Казанда яшим. Мин монда участокны электрга тоташтыру турында гариза бирә аламмы? – дип сорый белгечтән берәү.

– Әлбәттә. Без хәзер үк гаризаны тутыра башлый алабыз. Әгәр таләп ителә торган егәрлек 15 киловаттан артык булмаса, җиргә милек хокукы ясисә бер елдан артыкка арендага

Реклама

ТЕХНОЛОГИК ТОТАШТЫРУ ПРОЦЕССЫ:

- Гариза кулланучыларга хезмәт күрсәтү офисларында яисә компания сайтындагы шәхси кабинет аша тапшырыла.
- 15 календарь көн эчендә электромонтёрлар бригадасы йорт хуҗалыгына килә, энергия кабул итү җайланмасын карый. Бу вакыт аралыгында технологик тоташу килешүе проекты әзерләнә. Ташламаларга ия гариза тапшыручы физик затлар өчен (15 киловаттан артык булмаган егәрлек соралганда, челтәргә кадәр ара шәһәрдә – 300 метрдан, авылда 500 метрдан артмаганда), бу хезмәт күрсәтү нигездә 550 сумга төшә (кулланучының гамәлдәге электр челтәренә кушылуына яисә компаниянең яңа инженер коммуникацияләре үткәрүенә бәйсез рәвештә). Ташламадан бер муниципаль берәмлек кысаларында өч елга бер мәртәбәдән дә артыграк файдаланырга рөхсәт ителми.
- Электромонтажчылар бригадасы һава яисә кабель линиясе суза, трансформатор подстанциясе урнаштыра. Гариза бирүче шулай ук килешүдә каралган техник шартларны үти: исәпкә алу приборын сатып ала һәм аны килешүдә тәкъдим ителгән вариантларга ярашлы итеп урнаштыра.
- Барлык чараларны башкарганнан соң, гариза бирүче компаниягә техник шартларның үтәлеше турында хәбәр юлларга тиеш. Һәр ике як та йөкләмәләрен үтәгәннән соң, челтәр компаниясе электр челтәрләренә кушылу буенча оештыру һәм техник чараларны башкара.
- Тоташтыру процедурасын компаниянең махсус өйрәтелгән персоналы үти, алар үз эшләрен көчәнеш астында эшләү технологиясе буенча башкара.
- Мөһим! «Челтәр компаниясе» ААҖ күп очракта технологик тоташтыру эшләрен көчәнеш астында эшли, башка абонентларны (кулланучыларны) челтәрдән аермый эшләү методын куллана.
- Эшләр тәмамланганнан соң, гариза бирүчегә технологик тоташтыру процедурасының тәгәлләнүе дә язылган документларның тулы пакеты тапшырыла.
- Гариза бирүчеләрнең күпчелеге өчен процесс 4 айдан да күп вакытны алмый (энергообъектның реконструкциясе таләп ителгәндә – 6 ай) (срок РФ Хөкүмәтенең 2004 елның 27 декабрендәге 861нче Карары белән расланган Технологик тоташу кагыйдәләрендә билгеләнгән).

алу турында килешү кәгазе булса, ә участоктагы ноктадан безнең челтәргә кадәр ара 500 метрдан артмаса, сез тоташу өчен ташлама каралган категориягә керәсез. Сезгә әлеге хезмәт өчен 550 сум түләргә кирәк булачак. Түләүне офиста урнашкан терминал аша үткәрергә мөмкин, – дип аңлата белгеч. Берничә минуттан гариза әзер дә була.

– Гаризаны, йортыгыз яисә участогыгыз территориаль яктан кайда урнашкан булуына карамастан, үзегез өчен уңай теләсә кайсы офиста тапшырырга ярый, – ди «Челтәр компаниясе» ААҖ филиалы – Кулланучыларга хезмәт күрсәтү дирекциясе директоры урынбасары Лилия Төхбәтуллина. – Үзәкләрдән тыш, республикада тагын 49 хезмәт күрсәтү пункты эшли. Якындагы хезмәт күрсәтү үзәгенең яисә пунктының төгәл адресын компаниянең сайтында (www.gridcom-rt.ru) яисә тәүлек әйләнәсе эшли торган контакт-үзәкнең күп каналлы телефоны (8-800-2000-878) аша белергә мөмкин.

«Челтәр компаниясе» сайтындагы шәхси кабинет аша мөрәҗәгать итеп, эшне тизләтеп тә була.

...ҺӘМ ЫШАНЫЧЛЫ

Гариза шәхси кабинет аша тапшырылганнан соң, технологик кушылу килешүе һәм энергия белән тәэмин итү килешүе электрон формада башкарыла. Челтәр компаниясе объектны электр челтәренә тоташтыра алсын өчен, милек иясе кайбер техник шартларны үтәргә тиеш: счетчигы һәм автомат йөкләнеш аергычы (УЗО) булган күчереп йөртелешле «шкаф» урнаштырырга. Моның өчен ул тиешле лицензиягә ия электр-монтаж оешмасы хезмәтләреннән файдалана ала. Счетчиклы һәм аергычлы тартма гадәттә участокка иң якын утыртылган электр баганасына беркетелә.

– Тартманың болай урнаштырылуы гамәлдәге законнарга таянып башкарыла. Һәм асылда клиент өчен дә уңайлы. Беренчедән, елына ике тапкыр счетчикларны тикшерергә тиешле электр челтәре хезмәткәрләре бу эшне йорт хуҗалыгы иясеннән башка, хуҗалык территориясен карап чыгып кына башкара ала. Икенчедән, янгын куркынычсызлыгы арта. Статистика буенча шәхси йортларда чыккан янгыннарның төп сәбәбе – кыска ялганыш, – ди Казан электр челтәрләренең хезмәтләр күрсәтүне гамәлгә ашыру буенча директор урынбасары Дмитрий Казайкин. – Моннан тыш, яңа буын счетчиклар энергия куллану турындагы мәгълүматлар автомат рәвештә тапшыра алалар. Бу мәгълүматлар безнең серверга килә, ә аннан энергия белән тәэмин итү компаниясенә тапшырыла.

«БЕР ТӘРӘЗӘ» ПРИНЦИБЫ БУЕНЧА

Милек иясе, килешүне кулына алганнан соң, соралган техник шартларны никадәр тизрәк үтәсә, тоташтыру шулкадәр тизрәк эшләнәчәк.

– Клиент безгә техник шартларның үтәлүе турында хәбәр җибәрүгә, без кучмә бригада өчен заявка тутырабыз. Хәбәр алынганнан соң 10 көн эчендә бригада, урынга барып, техник шартларның үтәлешен карый, счетчиклы «шкаф»ка пломба сала, көчәнеш бирә, счетчиктагы күрсәткечне тикшерә, – дип сөйли Идел буе электр челтәрләренең технологик тоташулар бүлеге башлыгы Александр Сабиров. – Милек иясе технологик тоташуның башкарылуы турындагы актны имзалый, безнең белгечләр электр белән тәэмин итү килешүен аның кулына бирәләр. Шул мизгелдән кулланучы – «челтәрдә» санала.

Сүз уңаеннан, әгәр берничә ел элек электр белән тәэмин итү килешүенә бер айлап вакыт соралса, Технологик тоташу кагыйдәләренә кертелгән соңгы үзгәртмәләр челтәр оешмаларының тәэмин итүчеләр белән мөстәкыйль эш итүен күздә тота.

– Хәзер ике килешү дә параллель эшләнә. Гариза алганнан соң, без бу турыда гарантия бирүче тәэминатчы – «Татэнергосбыт» АҖ мәгълүмат тапшырабыз һәм аңа гариза бирүченең документларын юллыйбыз. Ул, үз чиратында, безгә имзаланган энергия белән тәэмин итү килешүе проектын тапшыра. Гариза бирүче безгә кабат килгән вакытта әлеге килешүгә кул куйдырабыз яисә килешүне аның шәхси кабинетына юллыйбыз, – дип сөйли «Челтәр компаниясе» ААҖнең килешү эшләре бүлеге башлыгы Олег Табакин. – Тоташтырганнан соң, без гариза бирүче имзалаган килешүне тәэмин итүче оешмага кайтарабыз. «Татэнергосбыт» АҖ белән безнең үзара документ әйләнеше сыйфатлы оештырылган, хәзер без шулай ук Татарстан территориясендә электр белән тәэмин итү хезмәтләрен күрсәтергә хокукы булган башка тәэмин итүче оешмалар белән шундый ук хезмәттәшлекне җайга салабыз.

ТЕХНОЛОГИК ТОТАШТЫРУ САННАРДА:

2018 елның 9 аенда «Челтәр компаниясе» ААҖндә физик һәм юридик затлардан технологик тоташтыруны сораган **17 193 гариза керде**.

Технологик тоташтырулар турында документларны торгызуга (яңадан рәсмиләштерүгә) **9177 гариза кабул ителде.**

Гомуми максималь егәре 448,7 МВт булган технологик тоташтыру буенча **12 771 килешү башкарылды**.

МОНЫ БЕЛҮ ФАЙДАЛЫ:

- Технологик тоташтыруны сораган гариза челтәр оешмасы тарафыннан гариза бирүче имзалаган килешү проекты алынган көннән 30 эш көненнән дә иртәрәк юкка чыгарылмый. Әлеге вакыт аралыгында сез килешүгә кагылышлы барлык сорауларны (алар туган очракта) хәл итә аласыз.
- Электр белән тәэмин итүнең даими схемасы буенча килешү төзелгән булып, төзелеп килүче объектны вакытлыча электр белән тәэмин итәргә кирәк булганда, вакытлыча технологик тоташтыруны сорап гариза бирергә кирәк. Бу вакытта гариза бирүче гамәлдәге тоташу ноктасыннан электр челтәре хуҗалыгының кирәкле объектларын төзүне мөстәкыйль башкара. Егәрлек буенча чикләүләр бу очракта юк. Электр белән тәэмин итүнең даими схемасы буенча техник шартлар үтәлгәннән соң, вакытлыча кулланылган схема сүтелә.
- Объектның билгеләнеше үзгәргәндә (мәсәлән, гараж кибет итеп үзгәртелә) электр белән тәэмин итү турында яңа килешү имзаларга кирәк, чөнки шәхси торак төзелеше тарифлары кибетнекеннән аерыла.
- Әзерләнә торган федераль закон проектларының берсенә ярашлы, тоташу вакытында соралган егәрлектән әзрәк егәрлек тотучыларга карата файдаланылмаган егәрлекләрдән чыгып исәпләнгән тарифлар кулланылачак. Кулланылган электр энергиясенә зуррак тариф буенча түләмәс өчен, тиешле килешү төзеп, максималь егәрлекне йә челтәр оешмасы файдасына яңадан бүлергә, йә челтәр компаниясе катнашында икенче кулланучы белән егәрлекләрне яңадан бүлү турында килешү төзергә кирәк булачак.

Тәүлек әйләнәсе эшли торган күп каналлы контакт-үзәк 8 800 2000 878

Фотолар «Челтәр компаниясе» ААҖ нән алынды.

ТАТАРСТАН БАЛЫКЧЫЛАРЫ

«Татарстан» республикадагы барлык балык тоту урыннарын белә. Чөнки сезон ачылганнан бирле Татарстанның иң билгеле балыкчылары белән балыкка йөрде. Һәркайсы белән салкында бәке төбендә туңып утыра торгач, без балыкчылардан шактый гына кызыклы хәлләр турында сораштык. Шулай ук «Татарстан» журналының балык тоту турындагы өч соравына җавап та алдык:

1 Сез тоткан иң зур балыкның авырлыгы нинди булды?

2 Балыкчы булган гомерегездә якынча күпме балык тоттыгыз?

3 Кыш көне балык тотканда сезнең белән булган иң кызык хәл.



Фото ТР Президенты Инстаграмыннан

БАШЫҢА КИ!

Сергей Иванов,

Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитеты рәисе:

1 Мин тоткан иң зур балык, бәлки, рекорд та түгелдер, – шулай да ул 2 килограммлы судак иде.

2 Кышын балык тотарга бик яратам, чөнки кыш көннәрендә Идел киңлекләре өстендә кояш чыккандагы матурлыкны сүз белән генә сөйләп-аңлатырлык түгел: бөтен җир ап-ак, кояш – кып-кызыл. Шуңа да үз гомеремдә күпме балык тотканымны санаганым юк, минем өчен процесс һәм матурлык кадерлерәк.

3 Балыкка баргач, кызыклы һәм көлкеле хәлләр еш була. Иң кызыклары соңыннан анекдот булып китә. Мәсәлән, мондые: ирләр балык тотып утыра, зәмһәрир суык. Берсе – яланбаш. Аңа: «Нигә башыңа кимисең? Салкын бит, чирләрсең. Ки башыңа!» – диләр. Ә ул: «Ыһы! Кигән ди! Кичә кигән идем, барысын да эчәргә чакырганнар, ә мин ишетмичә калганмын – ап-аек идем!»

Фото: Ната Смирнова

ИДЕЛНЕ ЯУЛАП АЛДЫЛАР, БАЛЫК ТОТАР УРЫН ДА ЮК!

Павел Лоханов,

Кама Тамагы районы башлыгы, 30 еллык балыкчылык стажы бар:

1 3 кило 700 грамм авырлыктагы судак – миңа эләккән иң эре балык шул!

2 Утыз еллык балыкчылык стажым булуын исәпкә алганда, тоннага якын балык тотканмындыр.

3 Ике ел элек балыкка чыгып киттем, 2 гыйнвар иде ул. Иртәнге караңгыдан ук. Килдем, Куйбышев сусаклагычында бер урынга утырдым. Әйләнә-тирәдә дистәләрчә чакрым боз, бер җан әсәре дә юк. Карасам, таң белән үк Затон ягыннан миңа таба унлап балыкчы төягән тагылма белән «Буран» килеп ята. (Биредә яшәүче кешеләр балыкчыларны балык тоту урынына илтеп куеп, акча эшли). «Буран» миннән ун метрлап арада гына туктады да, балыкчылар аннан төшеп, минем тирәли чәчелеп утыра башладылар... Гадәттә, балыкчыларның язылмаган кануны буенча алай ук янәшә килеп утырмыйлар... Тыйнак кына боларны кисәтәм: ким дигәндә, миннән биш чакрым аралыкта бер генә җан иясе дә юк, балык тотар өчен урын күп. Сүгенү сүзләрен безнең телгә тәрҗемә иткәндә, җаваплары болайрак булды: «Бөтен Иделне яулап алдылар, балык тотар урын да юк!»

Фото Павел Лохановның шәхси архивыннан алынды

БАЛЫКЧЫЛАР НИЧЕК ИТЕП КОТКАРУЧЫЛАРНЫ КОТКАРДЫ

Андрей Кузьмин,

«Татмедиа» АҖнең генераль директоры, 15 еллык балыкчылык стажы бар:

1

Мин тоткан иң зур балык – 30 килолы җәен. Иделдә тоттым.

2

Үз гомеремдә күпме балык тотканымны әйтә алмыйм. Санап карагыз: унбиш ел тотам инде. Барган саен бишәр кило балык алып кайтам.

3

Шулай бервакыт, кыш азагына якынлашканда, Идел өстендә кар автомобилебез ватылды – Кама Тамагы ягына бара идек. Коткаручыларны чакырдык. Алар алты тәгәрмәчле зур машинада килде – балыкчыларны экстремаль хәлдән коткару өчен махсус машиналары ул аларның. Боз өстендә кар боткасы изрәп тора иде инде… Безнең янга килеп җитәрәк болар шул «ботка»да батып калдылар. Алга да барырлык түгел, артка да. Шундый зур машинаны урыныннан кузгатыр хәл юк. Әлеге машинаның җиһазлары арасында чыгыр да бар, алдык та машинадан 15 метр читтәрәк бәкеләр тиштек. 15 ләп бәке, һәркайсына терәк тыктык һәм шулай чыгардык. Башта без коткаручыларны коткардык, аннан соң алар – безне.

Фото Андрей Кузьминның гаилә архивыннан алынды

Фото: Ольга Тупоногова-Волкова

НИЧЕК МИНЕ БАЛЫКТА ОНЫТЫП КАЛДЫРДЫЛАР...

Фото: Лаеш районының матбугат хезмәте

Борис Кузнецов,

Бөек Ватан сугышы ветераны, Советлар Союзы Герое:

1 Мин гадәттә Лаеш районында балык тотам. Анда Идел белән Кама елгалары кушыла, киңлеге 46 чакрымлык зур «диңгез» хасил була! Анда төрле балык бар: судактан алып – шыртлакага кадәр. Һәм шул «диңгездә» без еш кына кило ярымлы, ике килолы корбан балыклары тотабыз. Ә берсендә мин 6,5 килолы чуртан тоттым! Кайда дисезме? Казансуда! Кышын!

2 Шуны гына әйтә алам: балыкка барган саен 5–6 кило балык алып кайтам. Ә балыкка без атна саен йөрибез. Гомер буена бер ярым, бәлки ике тонна балык тотканмындыр мәгәр!

3 Балыкта кызыклы хәлләр еш булып тора. Шулай бер-ике көн элек балыкка килдек. Миңа балык әйбәт «керә», ә минем дустыма – подполковникка – юк. Ул башка урынга барып карыйм әле, диде дә, мине калдырып, китеп барды. Бер сәгать утырам, ике... Юк та юк. Балык та капмый башлады. Иң мөһиме: телефонны өйдә онытканмын. Кич җитте инде. Ә аның анда әйбәт каба, күрәсең, аерыла алмый, дөньясын оныткандыр, дим... Һәм шунда каяндыр яныма таныш бер балыкчы килеп чыкты. «Борис Кириллович, нишләп берүзең генә утырасың?» – ди бу. Мин аңлатып бирдем. Ул телефонын чыгарды да дустыма шалтыратты. «Нишләп калдырып киттең аны? Тиз бул, килеп җит!» – ди. Унбиш минуттан теге очып килеп җитте! Чынлап та – рюкзагы тулы балык! Машинасына утырдык та кайтып киттек шулай итеп...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Бөгелмә мэры **НӘРСӘГӘ** күнегә алмый

Казан ханлыгы тәхете өчен көрәш **НИЧЕК** барган

Кино дөньясы **НИЛӘР** белән шаккатыра

КАЙДА шәһәрдән рәхәтрәк яшәп була

Элвин Грей татар музыкасын **КЕМНӘРГӘ** таныта

БӨГЕЛМӘ РАЙОНЫ



БӨГЕЛМӘ МЭРЫННАН – *шашлык*

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫ ӨЧЕН МАХСУС

Декабрь җиле «татарстан»лыларны кунакчыл Бөгелмәгә илтеп ташлады. Безгә Бөгелмә районы башлыгы Линар Закиров пешергән тәмле шашлык белән сыйланырга насыйп булды.

ИҢ МӨҺИМЕ – ЭШ, ГАСТРОНОМИЯ – СОҢЫННАН

– Мин теләсә нәрсә әзерли алам! – дип ышандыра безне бусагадан ук Бөгелмә мэры. – Чөнки Интернет бар, ә аннан җаның теләгән рецептны табып алып, әзерләү серләрен белеп була. Тәмле килеп чыгамы, юкмы – анысы инде башка мәсьәлә. Ошаталармы? Моңарчы бер дә зарланганнары юк иде әле. Мин үзем талымлы кеше түгел, нәрсә бирсәләр шуны ашыйм. Мөгаен, һөнәрем шулай өйрәткәндер

– Татарстан район башлыкларының күпчелеге шундый ахры...

– Безнең бөтен гомер диярлек эштә үтә бит, сырланып, сайланып утырырга вакыт калмый. Шунлыктан мин ит тә, балык та, яшелчә дә ярам... Иң гади ризыкларны үз итәм. Бәрәңге, сельдь балыгы, әнием пешергән кәбестәле аш, токмач, пилмән... Кәефкә карап инде. Бүген

Фото: Александр Ефремов

Кирәк булачак:

- Сыерның сум ите (сөяксез ите).
- Яшь бәрәннең кабырга өлеше – бөтен кешегә җитәрлек күләмдә.
- Суган – күп кирәк.
- Тоз, борыч, тәмләткечләр – теләнчә.
- 1 данә лимон.

Журнал
ТАТАРСТАН
Редакционная Кухня
Обращение
к народам всего мира
Татарстан
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
и история

Автор:
Татьяна Вафина

минә сезгә бәрән һәм сыер итеннән шашлык әзерлисем килә.

БАЛЫК ПЕРКОСЫ

– Яңа ел табынына ниләр әзерләячәксез? Кем салат турый? Кем кайнар ашны пешерә? Кем җитәкчелек итә – сезме, хатыныгызмы?

– Хәләл җефетемнең мине аш-су әзерләүгә катнаштырасы бик килми, ул моны хатын-кыз эше дип саный. Әмма кайбер елларда өйдә булырга, зур тату гаиләбез белән табын тирәли бергә җыелырга мөмкинлек чыкса, ит яки балык пешерәм. Менә кичә генә газ мичендә сибас пешердем, бик тәмле булды.

– Ә сезнең районда нинди дә булса җирле балык бармы?

– Нигездә елга керкәсе (пеструшка). Ул хәтта безнең Бөгелмәнең гербында да мәңгеләштерелгән. Бу шул ук форель, керкә балыгы. Күптән түгел мине елга карпын бик тәмле итеп әзерләргә өйрәттеләр. Моңа кадәр карп шундый тәмле була, дип уйламый идем. Рецепт үзе бик гади: үсемлек мае, күп итеп сарымсак, төелгән кара борыч һәм тоз кирәк. Башта майны кыздыралар, аннары сарымсак салалар, ул алтынсу-көрән төскә кергәнче кыза һәм бөтен тәмен майга бирә. Сарымсакны алып, тоз һәм борыч сибелгән, онда әвәләнгән балыкны кызарга салалар... Өлгерергә биш минут чамасы калгач, сарымсакны балык өстенә сибәләр. Искиткеч тәмле ризык! Бик гади булуына карамастан, телеңне йотарлык була!

ШАШЛЫК ӘЗЕРЛӘҮ СЕРЛӘРЕ

– Нигәдер без һаман балык турында сөйләшәбез әле... Бүген без кыздыра торган шашлык та сезнең сыналган рецепт буенчамы?

– Шашлык әзерләү рецептлары бихисап, аны һәркем үзенчә кыздыра. Минемчә, шашлык тәмле булсын өчен тоз, борыч, тиешле күләмдә тәмләткечләр генә кирәк.

– Ягъни бернинди серкә-кефир-минераль су кирәкми?

– Шашлыкны тиз арада маринадларга кирәк булса, серкә өстәргә дә була. Тик мин лимон белән яхшырак маринадлана, дип саныйм.

– Ә сез ашарга пешерергә кайда өйрәндегез?

– Тулай торакта. Казанда, Товарищеская урамындагы 35 нче

йортта торганда. Алты ел буе тулай торакта яшәү теләсә кемне дә әллә нәрсәләргә өйрәтә ул.

ШАКТЫЙ КАҢГЫРАРГА ТУРЫ КИЛДЕ

– Ә кайда укыдыгыз?

– Башта Казан авиация институтында бер курс укыдым. Күңелемә ятмавын аңлагач, аны ташладым. Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институтына кердем. Әмма тулай торакта яшәвемне дәвам иттем, чөнки башка торыр урыным юк иде. Гомумән алганда, мин үз гомеремнең 6 елын тулай торакта, 5 елын кеше фатирында торып үткәрдем. Барлыгы 11 ел каңгырап йөрдем. Тулай торакта яшәгәндә, әллә нинди бер-берсенә ярашмаган ашамлыкларны кушып та ризык әзерләргә туры килгәләде. Нишлисең, башка ашамлык юк яки аны сатып алырга акча җитми иде. Бөтен студентлар да шулай яшәде ул чакта. Шунлыктан әллә нинди ризыклар пешерә идек... Күңелле чаклар!

– Шулай да, сезнеңчә, ризыкны кем тәмлерәк пешерә – ир-атмы яки хатын-кызмы?

– Төрлечә була инде. Кемдер бик тәмле итеп аш пешерә, ә кемнеңдер барып чыкмый. Башка эшләр дә шулай ук бит. Мин, мәсәлән, ирләр яхшырак үтүкли, дип саныйм. Үземнең чалбар һәм костюмнарымны гел үзем үтүклим. Монысына да тулай торакта өйрәндем.

ТУЫП-ҮСКӘН ҖИР ЯКЫН

– Әгәр башлык шул ук шәһәрдән (районнан) икән, аңа эшләве дә җиңелрәк, нәтиҗәләре дә әйбәтрәк, дип санала, чөнки туып-үскән җирдә сулавы да иркенрәк, кешеләре дә якынрак кебек тоела...

– Нигәдер, мин гел үз туган шәһәремә әйләнеп кайтасымны тоеп яшәдем. Ә болай... биредә – 17, Казанда исә 20 ел яшәдем. Минем өчен Казан да бик кадерле. Әмма Бөгелмәгә әйләнеп кайткач, туган шәһәремдә бөтен нәрсәнең җанга якынрак булуын аңладым. Миңа аның бөтен почмагы да таныш. Дөрес, 20 ел эчендә кайбер урамнарның исеме онытылган, яңалары пәйда булган... Шәһәр үсә, зурая, тормыш алга бара. Монда бернинди гаҗәпләнерлек нәрсә дә юк.

– Бөгелмәдә иң яраткан урыгыз нинди?

– Үземнең йортым һәм әниемнең йорты. Бизмәнгә салып үлчәү мөмкин түгел, Бөгелмәнең бөтен

урыннарын яратам. Биредә һәр җир минем өчен бик якын, үз. Күрәмсең, шундый бер вакыт җитәдер... Еллар үткән саен яшәрә бармыйбыз бит, сагыну, җирсү дә артарак төшә. Инде «мин яшь чакта...» дигән сүзләрне үземнең дә һаман ешрак кабатлавымны сизәм.

ХАЛЫК КАРШЫНДА НИЧЕК ТӘ СЫНАТМАСКА ИДЕ

– Һәр шәһәрдә, һәр авылда һәм җирлектә башка беркемгә дә охшамаган халык яши. Сез бөгелмәлеләрне ничек тасвирлар идегез?

– Бик үзенчәлекле, тырыш, хезмәт сөючән халык яши биредә. Тулаем алганда, белемле халык. Тарихи яктан шулай килеп чыккан: Бөгелмәдә фәнни-тикшеренү институты бар, шунлыктан бездә фән докторлары, доцентлар, академиклар, профессорлар күп булган... Билгеле, бөгелмәлеләрнең холкы төрле, әмма аларның барысы өчен дә уртак булган, аларны республикабызның башка төбәкләре халкыннан аерып торган сыйфатлар да бар. Мәсәлән, Арча кешесе, халык җыелган җирдә аралашканда, үз якташын шунда ук танып ала. Эчке сиземләү белән. Бөгелмәлеләр белән дә шулай...

– Сезне дә танайлармы?

– Мине башкача танайлар. Бөтен җирдә тануларына әле һаман да күнегә алмыйм. Бу – зур сынау. Бигрәк тә хәзерге социаль челтәрләр заманында... Аларга зур саклык белән карыйм. Бөгелмәлеләрнең челтәргә язган тәнкыйте кайдадыр чынлап та ярдәм итә, кирәкле булып чыга – без андый очракларда оператив рәвештә барысын да үз карамагыбызга алабыз. Әмма кайвакыт тәнкыйть җимергеч төс ала. Кайберәүләр хакимияттәгеләрне Интернет аша мәсхәрәләүне, түбәнсетүне зур казаныш дип саныймы, белмим. Миңа калса, мондый нәрсә булырга тиеш түгел.

– Шашлыкка күз салыйк әле. Маринадландымы икән инде?

Остабыз, иснәп карап, итнең әзерме-юкмы икәнлеген тикшерә һәм ит кисәкләрен пөхтәләп шампурга тезә башлый.Без исә аңардан «сорау алуыбызны» дәвам итәбез.

ШВЕЙК МАҖАРАЛАРЫ НИЧЕК ТӘМАМЛАНГАН?

– Сез нәрсәне шәһәрегезнең визит карточкасы дип саныйсыз? Нинди дә булса истәлекле урыннымы, үзегездә җитештерелгән берәр продукциянеме?

– Бездә мондый урыннар күп, чөнки, ни әйтсәң дә, шәһәргә 238 ел бит! Бөгелмәдә башка беркайда да булмаган гаҗәеп урыннар байтак. Ярослав Гашек музее шәһәрнең иң танылган «визитка»ларыннан берсе булып тора.

– Аның Швейк атлы сөйкемле солдатын без тимер юл вокзалында ук очраттык... Поездларны каршылый икән.

– Ансыз булмый. Чөнки Швейк атлы батыр солдатның маҗаралары турындагы хикәяләрен Гашек нәкъ менә Бөгелмәдә яза башлаган. Маҗараның ничек тәмамлануын сораганнар иде бер – искә төшерә алмадым. Мөгаен, яхшыдыр. Кабат укып чыгарга кирәк!

ПРОВИНЦИЯ КЕШЕЛӘРЕ

– Эш сәфәре белән чит илләрдә еш буласызмы? Бездәге һәм андагы провинция шәһәрләре ни белән аерыла? Безгә аларга охшарга тырышу кирәкме?

– Мөгаен, баштанаяк омтылмаскадыр. Хаҗәте бармы моның? Безнең үз үсеш юлыбыз. Бары безгә генә хас булган. Ә менә яхшы, алдынгы нәрсәләрне үзебездә кертү – мәҗбүри. Бу хәтта зарур.

Мин Сколковода укыганда Америка Кушма Штатларына барган идем. Әлеге гаҗәеп сәфәр бер айга сузылды. Укудан буш көннәрдә без, үзебез кебек студентлар белән, прокатка машина алып торып, төрле шәһәрләрне карап йөрдек. Миңа Монтерей бик ошады. Анда нибары 3500 кеше яши. Бер катлы Америка. Һәм шул 3500 кешегә – 48 кунакханә! Төрле классны. Без бу шәһәргә шимбә көнне бардык һәм бер генә буш урын да таба алмадык! Якын-тирәдә яшәүче бөтен фермерлар ял көннәрендә күңел ачарга килә икән Монтерейга. Барлар, караоке-клублар туп-тулы. Бу мине таң калдырды.

– Зур шәһәрдә дә, кечкенәсендә дә яшәгән кеше буларак, әйтегез әле, кайсында рәхәтрәк?

– Өйдә рәхәтрәк. Биредә һавасы да үзгә, якын. Ә менә минем хатынымның, Казан кызы булса да, моннан беркая китәсе килми. Аңа Бөгелмәдә бик ошый. Чөнки бөтен нәрсә – бер адым ераклыкта гына. Көн саен яр буенда йөрергә мөмкин: һава чиста, саф . Бөкеләр юк. Казанга килеп, бөкегә эләккән чакларда кечкенә шәһәрдә яшәүнең кыйммәтен аеруча яхшы аңлыйсың. Сабыебыз гадәти балалар

1. Кисәбез!

2. Чистартабыз!

3. Турыйбыз!

4. Тозлыйбыз!

5. Борычлыйбыз!

6. Кисәбез!

7. Сыгабыз!

8. Болгатабыз!

9. Кыздырабыз!

10. Тезәбез!

БӨГЕЛМӘ МӘРЫННАН ФАЙДАЛЫ КИҢӘШ: Шашлык маринадларга вакытыгыз бик аз булса, иткә лимон сыгып, әйбәтләп болгатыгыз да, берничә минуттан инде кыздырырга ярый.

бакчасына йөри. Без дә гап-гади кешеләр бит.

КӨЧ НӘРСӘДӘ?

– Элегрәк «провинция» сүзе хәтта бераз гарьләндерә иде...

– Әйе, мин ул вакытларны хәтерлим. Хәтта бераз мәсхәрәлерәк тә яңгырый иде.

– Сезнеңчә, провинциаль шәһәрләрнең көче нәрсәдә?

– Нәкъ менә «провинция шәһәрләре» тота да инде дөньяны. Хезмәт сөючән, тырыш халык шуларда яши чөнки. Теләсә кайсы шәһәрнең үсешенә сәнәгать булыша. Металлургия булса, Уралдан башлап... Безнең биредә бораулаучылар, геодезистлар, нефть чыгаручылар никадәр... Бу күзгә күренмәс каһарманнар ил икътисадын күтәрә дә бит инде.

– Ә нефть чыгарылмаган очракта вазгыять ниндирәк булыр иде икән? Бөгелмәдәге иң зур этәргеч көч нинди?

– Нефтьтән башка ничек булуын белмим, күз алдына да китерә алмыйм, чөнки аннан башка ничек икәнен күргәнем юк. Әмма Бөгелмә районының куәте нефтьтә генә түгел, бездә авыл хуҗалыгы да алга киткән. Өлкәнрәкләр әле барлык күрсәткечләр буенча Бөгелмәнең Казаннан соң икенче булган чагын да хәтерли. Узган гасырның 60 нчы елларында, мәсәлән. Бары бу ике каланың гына Хезмәт Кызыл Байрагы – «Дан Билгесе» орденнары бар. Һәм без моның белән бик тә горурланабыз! Ул елларда АСК секторында үсеш күзәтелгән. Һәм, гомумән, Советлар Союзында бөтен нәрсә дә дөрес оештырылган булган. Куәтле ил, куәтле держава, ә без аннан чак кына колак какмадык. Аннары – торгынлык. Без ул авыр 90 нчы елларны хәтерлибез. Туктаусыз инфляцияләр, сумның бәясе төшү...

Бүген АСК на эре инвесторларны җәлеп итәргә телибез. Беренче адымнар ясалды инде. 2014 елда районга «Племрепродукт» кебек эре инвестор керде, нәтиҗәдә тавык йомыркасы җитештерү районда 20 мәртәбәгә диярлек артты, бу 27 млн данә дигән сүз. 100% куәтенә эшли башлаганда, елына 120 млн данә йомырка җитештерелəчәк. Татарстанның Көньяк-Көнчыгышындагы иң зур предприятие бу. Шул ук инвестор азык җитештерү заводын эшләтеп җибәрде, анда теләсә кайсы хайван өчен азык ясарга мөмкинлек бирүче зур лаборатория бар.

Боларга өстәп, тагын ит комбинаты да төзи. Совет чорында биредә танылган Бөгелмә ит комбинаты булган. 90 нчы елларда ул банкротка чыккан, мөлкәтен сатканнар. Һәм менә хәзер яңа ит комбинаты төзелә, иң яңа, заманча җиһазлар белән. Тәүлегенә 30 тоннага кадәр ит продукциясе җитештереләчәк. Совет чорындагы комбинатта тәүлегенә 15 тонна ит чыгарылган. Ягъни яңа завод аннан ике тапкыр куәтлерәк булыр дип көтелә.

СӨТ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ

– Шәһәр гөрләп үсә, бу берничә айга бер тапкыр килеп киткәндә дә сизелә. Ә авылларда вазгыять ни чама? Хәзер күп авыллар бетеп бара бит – эш тә юк, мәктәп тә, клуб та...

– Күп кеше авылдан килеп Бөгелмәдәге предприятиедә эшли, анда шактый эш урыны пәйда булды. Ит комбинаты файдалануга тапшырылгач, тагын эш урыннары булачак. Катнаш азык заводында бик күп кеше эшли. Хәзер безгә тагын бер эре инвестор кушыла – әлеге агрохолдингның хуҗасы чыгышы буенча немец булган Штефан Дюрр әфәнде. Ул инде 1989 елдан бирле Россиядә яши, илебезне бик ярата. Бүген аның предприятиесендә 100 мең баш сөт терлеге исәпләнә.

Озак вакытлар буе Бөгелмә районы сөт саву буенча күрсәткечләре өчен гел тәнкыйтьләнде, чөнки Бөгелмәнең спецификасы башкачарак. Бездәге бюджетны оештыручы төп предприятие – «ТНГ-Групп», аның эше Ерак Төньякка бару белән бәйле. Бу – геологоразведка. Анда уртача хезмәт хакы шактый югары, шуңа күрә ирләргә, терлек асраганчы, еракка китеп акча эшләп кайту файдалырак. Шунлыктан без нәкъ менә сөт саву, терлек саны буенча озак вакытлар буе тәнкыйть утына тотыла килдек. Хәзер исә без Штефан әфәнде белән Бөгелмә районы территориясендә өч сөтчелек комплексы төзү турында килештек. Бу 3550 шәр баш терлек өчен ике ферма һәм 6000 баш терлеккә



исәпләнгән бер мегаферма. Барлыгы 13000 баш сөт терлеге дигән сүз! Тәүлегенә уртача 360 тонна сөт, күз алдына китерәсезме? Әгәр эшебез уңса – без сөтчелек буенча районнар арасында беренче урынга чыгачакбыз! Бу бик җитди инвестицияләр: 10 миллиард сумнан артыграк акчаны компания 2,5 ел эчендә кертергә җыена. Минем өчен аеруча мөһим фактор: авыл халкы өчен тагын эш урыннары булачак.

БАШЛЫКНЫҢ БАШЫН НИ АВЫРТТЫРА?

–Башлык булу авырмы? Башыгызны нинди уйлар, мәсьәләләр бимазалый?

– Башны түгел, йөрәкне бимазалый ул уйлар... Бөтен нәрсә һәм бөтен кеше өчен йөрәк сызлый. Үз эшеңне чыннан да яратсаң, ә мин аны яратам, барысын да йөрәк аша кичерәсең. Сколковода укыганда психологлар моның бик үк дөрес булмавын аңлатырга тырышты да бит. Имеш, бу хисләр деформациясенә, эмоциональ зәгыйфьлеккә китерә, әйләнә-тирә чынбарлыкны кабул итүдән туктыйсың... Күпмедер дәрәҗәдә килешсәм дә, йөрәк аша кичермичә эшли алмыйм, барып чыкмый. Иң зур проблемам – кистереп «юк» дип әйтә белмәү. Әгәр үзгәрәм икән, инде эшли алмаячакмын. Чөнки мин кешеләрне ишетми башлаячакмын...

– Әмма кешеләр кайвакыт мөмкин булмаганны таптыра бит... Сез исә тылсымчы да, Кыш Бабай да түгел.

– Әйе, төрлесе бар, әмма алар белән эшләү, аларны тыңлау, аңлау, булышу – минем вазыйфам. Социаль статуслары да, дөньяга карашлары да төрле, әмма ничек бар шулай кабул итү зарур һәр кешене. Башкаларга алыштырып булмый бит. Проблемаларны булдыра алганча хәл итәргә тырышам.

– Ә сезнең, шәһәр мэры һәм район башлыгы буларак, берничек тә хәл итә алмаслык проблемагыз бармы?

– Әлбәттә, коллегаларымныкы да бардыр, дип уйлыйм. Проблема гына түгел, бу – әрнү. Бездә онкологиядән интегүчеләр байтак. Булышасым бик килә, әмма мин генә ярдәм итеп бетерә алмыйм. Яшәү һәм үлем проблемаларын бер генә башлык та, берниндиакча да, элемтәләр һәм танышлыклар да хәл итә алмый. Аллаһы Тәгаләнең генә кодрәтеннән килә бу. Ярдәм итеп тә, булышмаса, авыру чигенмәсә, бик авыр.

НИНДИ ИДЕМ, ШУНДЫЙ БУЛЫП КАЛДЫМ

– Дусларыгыз, сыйныфташларыгыз туган җирегезгә мэр сыйфатында әйләнеп кайтуыгызны ничек кабул итте?

– Күптән түгел безнең мәктәпне һәм сыйныфны тәмамлаучылар белән очрашу булды. 24 ел күрешмәгән идек. Күп кеше үзгәргән, кайберләре исә бер дә картаймаган... Баштарак миңа бераз читсенеп карадылар, аннары һаман да шундый ук икәнемне аңладылар һәм уңайсызлык юкка чыкты.

– Ә сез мәктәптә нинди идегез?

– Укуын яхшы укыдым, ә менә тәртип шәптән түгел иде... Мөгаен, бөтен малайларныкы да бер чамадыр инде ул. Ташып торган, куәтле энергиямне дөрес юлга юнәлтер өчен, директор мине мәктәптә үткән бөтен чараларда да катнаштыра иде. Барлык Чыршы бәйрәмнәрен алып бардым, хәтта Кыш Бабай да булдым...

Хулиганлык тормышта булыштымы соң?

– Әлбәттә! Башлык кем ул? Үзенең эчке сәясәтенә ярашлы рәвештә, командасын һәм халыкны артыннан иярттүче лидер. Тик лидер булып тумыйлар, лидерга әйләнәләр. Малай чакта мәктәп артында сугышулар, аннары Казанда чыныгу, тулай торакта мөстәкыйль яшәү – болар эзсез үтми. Чыныктыра. Буыннашларым кебек, мин дә урамда үстем. Шәһәребездә гопниклар да булды, сугыштык та, асфальт та бүлештек, әмма рәхимсезлек булмады...



Шушы нотада Бөгелмә районы башлыгы шашлыкның әзер икәнлеген хәбәр итә. Аны матур итеп тәлинкәгә бушата – башта сыер итен тезеп, өстенә шалаш кебек итеп бәрән кабыргасын өя. Суган бөҗралары, тәмләткеч үләннәр сипкәч, ресторандагыдай матур ризык килеп чыга. Нәкъ менә Бөгелмәдә генә була торган матурлык бу!

Ә шашлык астына – юк, сез уйлаган әйбер түгел – бик тәмле Бөгелмә лимонады килә. Бөгелмә районы башлыгы аны бик ярата икән, барыбызга да өстәп кенә тора. **т**

Бүген Бөгелмә районында вакансияләр саны эшсез гражданнар санынннан 4 тапкырга артыграк (882 вакансия, 220 эшсез), әмма ихтыяҗ һәм тәкъдим арасында җенес буенча, һөнәри әзерлек, квалификация буенча, хезмәткә түләү шартлары һ. б. буенча тәңгәлсезлек саклана.

Аеруча эшче һөнәрләр таләп ителә: машина йөртүчеләр, кондукторлар, контролерлар, машинистлар, юл монтерлары, станок көйләүчеләр, станок операторлары, чәчтарашлар, ашчылар, слесарьлар, токарьлар, электромонтерлар; хезмәткәрләрдән – иминият һәм сәүдә агентлары, бухгалтерлар, табибләр, инженерлар, инспекторлар, шәфкать туташлары, менеджерлар, педагоглар,белгечләр.

2018 елда 2774 кешегә, шул исәптән уку йортларындагы 2102 укучыга профориентация хезмәте күрсәтелгән.

Редакция «Юбилейный» рестораны администрациясенә рәхмәт белдерә.

НЕФТЬ ТӨБӘГЕ **АВАНГАРДЫНДА**

Хәзер нефть фонтан булып җир астыннан атылган чорларны күз алдына китерүе дә кыен, ул вакытта катлаулы техникасыз һәм җиһазларсыз гына, гади кешеләр хезмәте белән зур предприятиеләр төзелгән һәм Татарстанның алга таба уңышлы үсеше өчен нигез һәм горурлык булган тиңдәшсез технологияләр тормышка ашырылган.

1956 елда республикабыз нефть чыгару күләме буенча илдә беренче урынга чыкты һәм аның тизләтелгән үсешен тәэмин итү өчен зур фәнни база булдыру таләп ителде. Шул рәвешле Бөгелмәдә, төп ятмаларга якын урында, Татарстан Нефть фәнни-тикшеренү институты (ТатНИИ) төзелде, соңрак ул «ТатНИПИнефть» дип үзгәртелде, әлеге институт нефть ятмаларын эзләү, үзләштерү һәм эксплуатацияләүнең барлык актуаль мәсьәләләрен дә хәл итәргә тиеш булды.

Институт галимнәре һәм нефть промыселлары хезмәтчәннәренең иҗади эзләнүләре нәтиҗәсендә, Татарстан нефтьчеләренә фәнни-техник прогрессның алгы рәтләренә чыгарга мөмкинлек биргән күләмле техник һәм җитештерү ысул-алымнары эшләнде һәм беренче тапкыр гамәлгә ашырылды. Бу ысул-алымнарның күбесе тулаем нефть тармагының гомуми байлыгына әверелде.

ДАНЛЫ ТРАДИЦИЯЛӘР ИНСТИТУТЫ

Бүген «ТатНИПИнефть» – нефть тармагының алдынгы фән һәм проект үзәкләренең берсе. «ТатНИПИнефть» институтында эшләнгән проектлар буенча 2,5 миллиард тоннадан артык нефть чыгарылган,160 тан артык нефть ятмалары үзләштерелгән. Нефть сәнәгатен үстерүгә керткән өлешләре өчен институт күп мәртәбә Ватаныбыз һәм чит ил бүләкләре белән билгеләп үтелде. Алар арасында Ленин премиясе, СССРның ике Дәүләт премиясе, фән һәм техника өлкәсендә РФ Хөкүмәтенең өч премиясе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының 19 Дәүләт премиясе һәм башка бик күпләр бар. Институт арсеналында 2700 дән артык уйлап табу теркәлгән, шуларның 15 енә 76 чит ил патенты алынган.

Нигез салынганнан алып бу көнгә кадәр «ТатНИПИнефть»тә катлаулы проектлар булдырыла, югары нәтиҗәле технологияләр һәм җиһазларның яңа төрләре эшләнә. Бу еллар эчендә галимнәр һәм белгечләр институтның исемен Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә танытты.

Югары фәнни-техник потенциал, галимнәрнең һәм белгечләрнең күпьеллык тәҗрибәсе төрле таулыклы-геологик шартларда нефть ятмаларын комплексы үзләштерүнең катлаулы фәнни һәм проект-техник мәсьәләләрен уңышлы чишү гаранты булып тора.

ҮТӘ ҮЗЛЕ НЕФТЬ ӨЧЕН ПАР МУНЧАСЫ

Татарстанда «ТатНИПИнефть» соңгы унъеллыкның иң амбициоз проекты – үтә үзле нефть чыгару проектын әзерләүчеләрнең берсе булып тора. Нәкъ менә институт белгечләре беренчеләрдән булып әлеге юнәлештә тикшеренүләр үткәрде; авыр нефть һәм табигый битум ятмаларын актив рәвештә үзләштерергә, ә нефть чыгаруны скважина ысулы белән нәтиҗәле алып барырга мөмкин икәнлеген тәҗрибә юлы белән исбатлады. Узган гасырның 80 нче елларында әлеге юнәлешкә зур өмет баглыйлар, әмма СССР таркалу мондый тикшеренүләрне туктата, ә гамәлдәге нефть чыгару ысуллары икътисадый яктан нәтиҗәсез була. 2000 нче еллар башында гына үтә үзле нефть ятмаларын үзләштерү буенча проектлар эшләү яңадан торгызыла. 2006 елда Татарстанда Ашальчә ятмасында беренче скважиналар бораулана. «ТатНИПИнефть» технологияне эзлекле рәвештә камилләштерә килә, нефть чыгару күләме артканнан-арта бара. Хәзер татарстанлылар таулегенә 5 мең тонна үтә үзле нефть, ягъни елына 2 млн тоннага якын чимал ала. Әмма камиллеккә омтылышның чиге юк.

– Без SAGD – парлы гравитация дренажы технологиясе буенча эшлибез. Җир өслегендә бер үк вакытта ике скважина бораулана, берсе биш метрга түбәнрәк төшә. Нефть өске скважинага җибәрелгән кайнар пар белән сыекландырыла һәм аскы скважинага агып төшә, аны шуннан суырып алалар, – дип аңлата институт директоры Рифхәт Сәхабетди-

Фото: Александр Ефремов; «ТатНИПИнефть» тән алынды

Реклама

– Институтның республика һәм «ТатНИПИнефть» өчен туган төбәк – Бөгелмә районы үсешенә керткән өлеше бәяләп бетергесез, – ди институт директоры Рифхәт Сәхабетдинов.

нов. – Технологияне Канадада уйлап тапканнар, әмма без аны күп тапкыр камилләштердек. Аның буенча безнең патентлар саны да ике йөздән артып китә. Shell һәм «Татнефть» – SAGD технологиясен куллану буенча дөнья лидерлары. Әмма мәсьәлә шунда: безнең шартлар үтә үзле нефть чыгару белән актив шөгыльләнә торган башка илләрнекеннән нык аерыла. Шуңа күрә без йә дөнья технологияләрен үз шартларыбызга җайлаштырабыз, йә үзебезнекен булдырабыз. Әйтик, һәр ятмада диярлек очрый торган су линзаларын химик ысул белән ябып кую һәм ачып җибәрү технологиясен эшләдек, башка бик күп яңалыклар керттек. Хәзер нефть чыгару коэффициентын арттыру өстендә эшлибез. Татарстанда да, Россиядә дә запаслары искиткеч зур булган сланецларның төрдәше – доманикоидлар белән бәйле тикшеренүләрне актив өйрәнәбез

СУ... МЕТАЛЛГА ӘВЕРЕЛӘ

«Татнефть» алдында торган бурычлар аз түгел, димәк, компаниянең структур бүлекчәсе булган «ТатНИПИнефть» институты өчен дә эш җитәрлек. Компаниянең яңа стратегиясенә ярашлы рәвештә нефть чыгару күләмен 2030 елга 38 млн тоннага кадәр үстерү һәм экологик куркынычсызлык буенча эчке таләпләрне катгыйландыру – әнә шундыйлардан. Сүз уңаеннан, экология өлкәсендә институт инде бүген үк күп кенә проектларны тормышка ашыра. Шуларның берсе – скважинага җибәрелә торган суны чистарту һәм кабат куллану. Институт күптән түгел махсус энергокомплексны проектлау эшен тәгәлләде. Бу комплекс кулланышта булган судан пар энергиясен җитештерәчәк һәм аны электр челтәренә җибәрәчәк. Тагын бер экологик проект – нефть ятмаларында зур күләмдә барлыкка килә торган күкертле водород һәм углекислый газны эшкәртү.

– Берничә ел элек без Самара өлкәсендәге җиңел нефть ятмасында «майлы» газны (аның составында пропан, бутан, пентан микъдары зур) эшкәртү проекты белән шөгыльләндек. Исәпләүләр күрсәткәнчә, аларны яндыру – җир астыннан чыгарылган чималның 40 процентын юкка чыгару дигән сүз. Шунда без бу газларны бүлү, чистарту һәм сатуга әзерләү заводы проектын тормышка ашырдык. Хәзер ул уңышлы эшли, – дип сөйли Рифхәт Сәхабетдинов. – Ә быел исә «Казан экология комплексы» чүп полигонында чүплек газларын утильләштерү буенча тикшеренүләр башлап җибәрдек.

Сүз уңаеннан, институт «нуль калдык» принцибын зур уйлап табучанлык белән тормышка ашыра. «Татнефть» ГАҖнең Сколково шәһәрендәге Фәнни-техник үзәге белән бергә эшләүче белгечләр шөгыльләнә торган проектларның берсе – судан металларны чыгару. Иң әүвәл литий карбонаты турында сүз бара, хәзер бу матдә чит илдән бик күп кертелә. Аннары инде чиратта – башка кыйммәтле компонентлар.

ИРТӘГӘСЕ КӨННЕ ПРОЕКТЛАП...

Хәл ителә торган мәсьәләләрнең колачлыгына карамастан, институт эшчәнлеге профильле юнәлеш белән генә чикләнми. «ТатНИПИнефть» инде берничә дистә ел Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы торак йортларның күпчелеген проектлаучы оешма булып тора.

– Без скважиналар төзү һәм аларны үзгәртеп кору, ятмалар инфраструктурасы төзелеше проектларын эшлибез. Бу тәҗрибә безгә башка өлкәләрдә дә проектларны югары дәрәҗәдә әзерләргә мөмкинлек бирә. Әлбәттә, һәр юнәлешнең үз үзенчәлеге бар һәм аны өйрәнү өстәмә тырышлык таләп итә. Шуңа да карамастан, без проектлый торган гражданлык объектлары юнәлешләр шактый киң, – ди Рифхәт Сәхабетдинов.

Институт проектлары буенча 4 млн квадрат метрдан артык торак, барлыгы 200 мең урынга исәпләнгән мәктәпләр, техникумнар, институтлар, 10 мең урынга исәпләнгән хастаханә, санаторий, профилакторийләр төзелгән. Шулай ук күп кенә эре инфраструктура проектлары, шул исәптән «Алабуга» МИЗ территориясендә пыяла сүсе җитештерү заводы, Әлмәттә буалар каскадын торгызу, «ТАНЕКО» комплексы территориясендә су белән тәэмин итү системалары гамәлгә ашырылды. Күптән түгел эшләнгән проектларның берсе – «Татнефть» ГАҖнең югарыда искә алынган Сколково шәһәрендәге Фәнни-техник үзәге. Биредә «Татнефть» ГАҖнең нефть чыгару өлкәсендә инновацияле проектлар белән шөгыльләнә торган махсус лабораторияләре урнашачак.

Институтның республика һәм «ТатНИПИнефть» өчен туган төбәк – Бөгелмә районы үсешенә керткән өлеше бәяләп бетергесез. Монда бюджетка салым түләү, гражданлык объектларын проектлау һәм «Татнефть» аша актив хәйрия эшчәнлеге генә түгел, ә интеллектуаль капиталга инвестицияләр дә күз уңында тотыла. Институт патронажындагы мәктәптә районның имтиханнарда иң күп йөз балл җыючылары һәм медаль иярәре белем ала, шул рәвешле бу уку йортында иртәгә Татарстан нефть тармагын үстерергә киләчәк кешеләр әзерләнә.

ФАЙДАСЫ ДА БУЛСЫН, **ЛӘЗЗӘТЕ ДӘ...**

Бөгелмә сөт заводы павильонын традицион көзге Татарстан авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә табуы бик җиңел: аның янында сатып алучылар гадәттә мыжлап тора. Бу күренешнең сере бик гади дә, гаять катлаулы да.

Гади, чөнки бөтен эш – сыйфатта. Катлаулы, чөнки сыйфаты буенча кайтышрак, әмма бәягә дә арзанрак, шуңа күрә ихтыяҗ зуррак продукция арасында чагыштырмача кечкенә предприятиегә эре конкурентлар булган базарда марка тотарга да кирәк бит. Бөгелмә комбинатында моның ысулларын камил дәрәҗәдә үзләштереп өлгергәннәр.

30 нчы елларда башланып китә аларның тарихы. Ул чакта Бөгелмәдә сөт китерү пункты эшли башлый. Анда җирле колхозларда җитештерелгән сөтне китерәләр. Шул рәвешле зур булмаган сөт, май, каймак җитештерү производствосы оеша. 50 нче елларда Бөгелмәдә республиканың нефть эзләү һәм чыгару үзәге урнаша, шәһәр искиткеч кызу темплар белән үсәргә керешә. Сөт продукциясенә булган ихтыяҗ да күзгә күренеп арта. Шуның белән бергә, аңлашыла ки, эшкәртелергә тиешле сөт күләме үзе дә. Бу шартларны исәптә тотып, Бөгелмәдә май заводы төзелә: ул май, эремчек, кефир, каймак җитештерә. Акрынлап җитештерү киңәя, завод үзе дә модернизацияләнә, яңадан җиһазландырыла. 80 нче еллар башында биредә сыр чыгара башлыйлар. Шактый катлаулы 90 нчы елларда да завод тотрыклы рәвештә эшләвен дәвам итә, 2000 нче елларда да – шулай ук. Якын һәм ерак чит илләрдәге җитештерүчеләр белән көндәшлек көчәйсә дә, ул тотрыклылыкны саклый килә.

Илһам Минһаҗев, генераль директор

Бүген Бөгелмә май заводы – заманча җиһазландырылган алдынгы предприятие. Аның уңышы җитештергән продукциянең сыйфатын даими контрольдә тотуга, тармакның иң яхшы традицияләренә тугры калуга һәм, шуның белән бергә, җитештерү технологияләрен өзлексез камилләштерүгә нигезләнгән.

Ассортиментта 40 тан артык төр продукция исәпләнә. Биредә чимал буларак бары тик табигый сөт кенә кулланыла, ул, элеккеге традицияләрне исәптә тотып, бары тик җирле җитештерүчеләрдән генә сатып алына. Комбинатның үз лабораториясе бар, һәм килгән чималның һәр партиясе әйбәтләп тикшерелә. Шул исәптән – кибет киштәләренә китәргә тиешле әзер продукция дә. Җитештерүче шул рәвешле сатып алучыга тәкъдим ителгән товарның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын гарантияли.

Карап торганда әллә ни зур булмаган предприятиенең җитештерү күләмнәре шаккатыргыч. Көн саен предприятие складына 10 мең тонна табигый сөтле һәм әчетелгән сөтле продукция озатыла. Әчә торган сөт (2,5 һәм 3,2 процент майлылыкка ия), кефир, катык, ряженка, каймак, эремчек, табигый кушылмалар белән баетылган җиләк-җимеш йогыртлары, ацидофилин әчемлеге, эремчек продукциясенең өч төре, эретелгән сырлар – болар барысы да кулланучыга брендлы затлы тышча белән төрелеп тәкъдим ителә. Төрү материаллары – ул матур каплар, тартмалар, фольга һәм пластик контейнерлар. Көн эчендә

Реклама Фото: Александр Ефремов

җитештереп чыгарыла торган май күләме (биредә бары тик ГОСТ 32261-2013 кануннары буенча гына җитештерәләр («Крестьян» ак мае)) 2 тоннадан артып китә. Сатып алынган сөтнең өчтән ике өлеше каты сортлы сырлар әзерләүгә тотыла. Бөгелмә сырлары линейкасының «хиты» – ул «Делиз» төре (французчадан delice – «ләззәт»). Бу төр атаклы импорт пармезанга әйбәт мәгънәдә көндәшлеккә ия продукт булып әверелде. «Делиз» сырының, шулай ук биредә җитештерелгән «Гауда», «Пошехон», «Голланд» сырларының эре партияләре Мәскәүгә, Санкт-Петербургка, Екатеринбургка, Новосибирскига озатыла. Казанда комбинатның әлеге сырларын югарыда искә алынган ярминкәләрдә һәм Агропромпаркта сатып алырга мөмкин.

Комбинатның продукциясе даими рәвештә һәртөрле азык-төлек бәйгеләрендә, күргәзмәләрендә урыннар алып тора. Әмма ирешкән уңышларына да карамастан, предприятие ассортиментын киңәйтү юнәлешендә өзлексез эшли, тармак белгечләре белән бергә оеткылар белән компонентларның яңа төрләрен туктаусыз сынау белән шөгыльләнә. Моннан тыш, рентабельлелекне күтәрү максатыннан, технологик һәм инженерлык карарларын да һәрдаим камилләштерә. Аерым алганда, бернично ел элек комбинат энергия тулысынча үз чыганакларыннан алуга күчте – модернизацияләү программасы кысаларында биш казан төзелде һәм эшләтеп җибәрелде.

Предприятиенең барлык казанышлары нигезендә югары профессиональлек, гаять зур тәҗрибә һәм бердәм коллективның үз эшенә тугрылыгы тора. Биредә кайбер хезмәткәрләрнең эш стажы 25 елдан артып китә, бүген производствода инде династияләр белән эшләүчеләр дә бар. Кадрлар белән индивидуаль эш алып бару, хезмәткәрләргә һәрчак ярдәмгә килү, аларның белемнәрен арттыру, профессиональлеген үстерү – «Бөгелмә сөт комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры Илһам Минһаҗевның идарә итү принциплары әнә шундый. Предприятие эшчәнлеген популярлаштыру, профессиональ алмаш тәрбияләү һәм хезмәткәрләрнең һөнәрилеген үстерү процессын киңәйтү максатыннан ул Бөгелмә мәктәпләрендә укучыларга даими рәвештә комбинатка экскурсияләр оештыра. Һәр чара файдалы да, тәмле дә бонус белән тәмамлана – йогыртларга дегустация ясыйлар. Комбинат шулай ук иганәчелек белән актив шөгыльләнә. Аның вәкилләре даими рәвештә бәйрәм чаралары оештыра һәм яшәү минимумы түбән булган катламнарга үз продуктлары рәвешендә бүләкләр ясый.

Комбинат – Бөгелмәнең бюджетны оештыручы предприятиеләренең берсе. Биредә 200 гә якын кеше хезмәт куя. Әмма аның район тормышындагы роле икътисадка керткән өлеше һәм югары дәрәҗәдәге социаль җаваплылыгы белән генә тәгәлләнми. Предприятиенең миссиясе – күләмнәрне арттыру һәм үзе җитештергән сөт продукциясенең сыйфатын камилләштерү, шул рәвешле Татарстанда яшәүчеләрне файдалы һәм сәламәт сөт ризыклары белән тәэмин итү һәм, әлбәттә инде, туган республикабызның үсешенә һәм чәчәк атуына да үзеннән өлеш кертү.





БӨГЕЛМӘ СӨТ КОМБИНАТЫ – САННАРДА:

Татарстан һәм республиканың көньяк-көнчыгышында урнашкан башка төбәкләрнең йөзләгән кибетләре киштәсеннән ел саен сатыла:

	5 мең тоннага якын тулаем сөт продукциясе
	500 тонна майлы булмаган продукция
	370 тонна ак май
	2 мең тоннага якын сыр

«НУР» ҖЧҖ:
«БЕЗ МЕНӘ ДИГӘН ЮЛЛАР ТӨЗИБЕЗ!»

Компаниянең хәзерге тарихы 2008 елда башланып китә. Нәкъ менә шул елда әле 1995 елдан бирле эшләп килгән юл төзү предприятиесе базасында Амазасп Карапетян җитәкчелегендә «НУР» ҖЧҖ оештырыла.

«НУР» ҖЧҖ 2008 елның 4 июнендә оеша. Бүген ул үз клиентларына түбәндәге лицензияле эшләрне тәкъдим итә: территорияләрне төзекләндерү, юл-төзелеш эшләре, йөк йөртү. 16 мең 783 квадрат метрны тәшкил иткән һәм үз эченә складларны да сыйдырган үз җитештерү базасы булу киң спектрлы эшләр җәелдерергә мөмкинлек бирә. Предприятиенең үз асфальт-бетон катнашмасы чыгару заводы да бар, аның җитештерү куәте сәгатенә 60 тоннаны тәшкил итә. Юл салу эшләренең сыйфаты һәм көйле баруы нигездә заводның тотрыклы, ышанычлы эшенә бәйле. Нәкъ менә үзләренең асфальт-бетон заводы «НУР» ҖЧҖнә юлларга асфальт җәю һәм ремонтлау юнәлешендә эшләгәндә бәяләр буенча да өстенлекне сакларга булыша, сыйфатны контрольдә тотарга да. Предприятиенең шулай ук һәр заказчыга индивидуаль якын килеп эшләү мөмкинлеге арта: клиентларның таләпләрен исәптә тотып, бик яхшы сыйфат тәкъдим итәргә дә, бәяләрне кулай итәргә дә.

УҢЫШ СЕРЕ

Җитәкчелекнең беренче көннәрдән үк матди-техник базаны ныгыту, персоналның квалификациясен үстерү, хезмәт һәм җитештерү шартларын яхшыртуга нигезләнгән дөрес сәясәте «НУР» ҖЧҖнә Татарстан Республикасы көньяк-көнчыгышында юл салу һәм төзекләндерү эшләре базарында лидерлар рәтенә чыгарга мөмкинлек бирде.

«НУР» ҖЧҖнең партнерлары арасында – «Транснефть-Прикамье» АҖ, «Главтатдортранс» ДКУ, «Татнефтедор» ҖЧҖ, «ТР Баш инвестицион-төзелеш идарәсе», Яр Чаллыдагы «Автомобиль юллары предприятиесе» МУП, «Башкиравтодор» АҖ һәм башка бик күпләр бар.
Соңгы арада предприятие юл салучылары тарафыннан «Урал» М-5 федераль дәрәҗәдәге гомуми кулланылыштагы автоюлның 100 км дан артыграгында колачлы эшләр алып барылды. «НУР» ҖЧҖ Яр Чаллының Сидоровка паркы төзелешендәге һәм сәнәгать зонасындагы гомуми кулланылыштагы юл инфраструктурасын булдыруда да зур эшләр башкарды.

Реклама   Фотолар «НУР» ҖЧҖнән алынды

Амазасп Карапетян, «НУР» ҖЧҖ җитәкчесе:

– Юлларның авыллар белән шәһәрләр арасындагы бәйләп торучы җепләр генә булмыйча, зуррак мәгънәгә ия икәнлекләрен исәптә тотып эшләү зарур. Юллар – республика икътисадына тотрыклы рәвештә эшләргә мөмкинлек бирүче мөһим буыннар да ул. Безнең заманда сыйфатлы юллар булмый торып сыйфатлы тормыш турында сүз алып бару – көлке. Соңгы елларда юл өслегенең сыйфатына карата да таләпләр күзгә күренеп үсте. Заманча юллар яңа технологияләр һәм материаллар куллануны сорый. Без үз предприятиебездә бу яңалыкларны актив рәвештә үзләштерәбез, кертәбез. Бүгенге эш географиясе менә мондыйрак: республикабызның Лениногорск, Азнакай, Баулы, Тукай, Нурлат районнары, күрше Башкортостанның Октябрьск районы һәм, әлбәттә инде, Бөгелмә. Ел саен бездә 50–60 км автомобиль юлларын асфальт белән каплыйбыз. Әгәр шәһәрлеләр, Бөгелмә районында яшәүчеләр шәһәрдә һәм районда юллар яхшырды, дип әйтә икән, безнең өчен моннан да зуррак шатлык була алмый. Шушы сүзләрне ишетер өчен эшлибез дә бит!

«НУР» ҖЧҖ барлык эш төрләрен дә техник регламент, контракт һәм проект документациясе таләпләрен исәптә тотып башкара, башлангыч, операцион һәм кабул итү контролен гамәлгә ашырып. Без үзебез эшләгән бөтен эшләргә дә гарантия бирәбез. Җитешсезлекләр табыла икән, аларны үз хисабыбызга төзәтеп бетерәбез. Иң югары таләпне, беренче чиратта, үзебезгә үзебез куябыз. Юл салучы һәм төзекләндерүчеләрнең компетенциясендә булган барлык эшләрне дә һөнәри югарылыкта башкарып чыгарга омтылабыз. Мин ышанып әйтә алам: бездә иң җаваплы, эшне тоткарламый, кеше хәленә керә белә торган хезмәткәрләр эшли. Алар төгәл белә: юл салучы һәм төзекләндерүченең эше – күз уңындагы хезмәт ул, аның җитешсезлекләрен яшереп калып булмый. Шуңа да начар эшчеләрне тотмыйбыз.

ЮЛ САЛУЧЫЛАР ӨЧЕН – БИЛЬЯРД

Җитәкченең сүзләрен раслаучы иң анык факт: «НУР» ҖЧҖ хезмәткәрләре арасында күбесе Амазасп Мкритчович белән инде 10–15 еллап бергә эшли. Предприятиедә кадрлар мәсьәләсендә тотрыклылык күзәтелә. Бирелә кадрларны әзерләү, аларны эш белән кызыксындыру һәм профессиональ осталыкларын үстерү буенча максатчан эш алып барыла. Кадрлар сәясәтенең төп юнәлешләренең берсе: хезмәт өчен түләү системасын, эшләнгән эшкә нигезләнеп, индивидуаль якын килеп оештыру. Шулай ук – нәтиҗәле, комфортлы хезмәт һәм ял шартлары тудыру да. Хезмәткәрләр җитештерү базасында барысы белән дә тәэмин ителә: бушлай иртәнге, төшке һәм кичке аш, җайлы бытовкалар, чиста һәм уңайлы бүлмәләр, мунча, телевизор, хәтта бильярд та.

КЕШЕЛӘРНЕҢ РӘХМӘТ СҮЗЕ – ИҢ ЗУР БҮЛӘК

Петр Ненастин исемендәге скверны яңарту, Яшьләр сарае каршындагы мәйданны төзекләндерү, «Дюймовочка» мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесенең балалар йөри торган һәм гомумән бөтен территориясен асфальтлау, Бөгелмә шәһәренең купсанлы ишегалларында асфальт парковкалар булдыру, юл читендәге тротуарларны таш белән түшәү... – «НУР» ҖЧҖ каланы уңайлырак һәм ямьлерәк итү юнәлешендә башкарылган эшләрдән беркайчан да читтә калмый. Хәер, предприятие җитәкчесе үзе бу хакта сөйләргә әллә ни яратмый.

«НУР» ҖЧҖ 20дән артык йорт яны территориясен асфальт белән каплау буенча колачлы эш башкарды, шул исәптән, «Нефтеавтоматика» микрорайонының Воровский урамындагы 50–54 нче йортлары тирәсендә дә.

Амазасп Мкритчович сүзләренә караганда, кече улы Егор, әле бәләкәй булуына карамастан, инде юл салучылар белән төзекләндерүчеләр эшенә карата зур кызыксыну белдерә икән. Производство базасында да ул – еш күренә торган кунак. Кем белә бит, бәлки, әтисе эшен дәвам да итәр? Карапетянның олы улы, әнә, бүген инде «НУР» оешмасында тәэмин итү бүлегендә хезмәт куя...

Моннан ике ел элек кенә бирелә, яңгырлар мул ява калса, сулар биш катлы йортларның каршында җыелып, агып китә алмыйча ята иде. Хәзер алай түгел: яңа асфальт өслеге җәелгән йорт яны территорияләре күзне ямьләндереп тора.

Сентябрь аенда шәһәр мэры Линар Закировның республика программасы кысаларында капремонт ясалган йортларны, иҗтимагый-мәдәни тормыш объектларын карау буенча традицион читкә чыгып уздыра торган җыелышын ябыштырканда «Бөгелмә газетасы» «НУР» башкарган эшләр турында язып та чыкты.

– Кешеләр безгә олы рәхмәтен белдерде, – ди Амазасп Мкритчович, – урамнарга чыгып, юл салучыларны һәм төзекләндерүчеләрне хөрмәтләделәр. Ә бит шушы кешеләргә уңайлы булсын өчен, хезмәткәрләребез эсседә дә, салкында да эшләде. Алны-ялны, кичне, таңны белмәделәр, дигәндәй. Безнекеләрне еш кына үрнәк итеп күрсәтәләр. Үземдә эшләгән 86 кешенең һәркайсына мин 100 процентка ышанам. Моның хакына да армый-талмый эшләргә була...

ЯН, **ҖИҢҮ** ЯЛКЫНЫ!

Быел җәй көннәрендә Татарстанның берьюлы өч көрәшчесе ишетү сәләте чикләнгән спортчылар арасында грек-рим көрәше буенча дөнья чемпионы булды. Монда берниндИ очраклылык та юк, киресенчә – чып-чын закончалык. Чемпионнарның өчесе дә Бөгелмәнең «Факел» спорт мәктәбендә шөгыльләнә.

МӘҢГЕЛЕК КӨРӘШ

Өлкәннәр арасында 67 килограммга кадәрге авырлыкта җиңүче – халыкара класслы спорт мастеры Исмаил Насрулаев, үсмерләр арасында 55 килограммга кадәр авырлыкта – Ленур Абдуллин, 67 килограммга кадәрге авырлыкта – Евгений Семенин. Аларның остазы – Россиянең атказанган тренеры Рәис Садыйков озак еллар инде гади малайларны да, ишетү сәләте чикләнгәннәрне дә көрәшергә өйрәтә.

– Бездә максатчан, үҗәт, чын мәгънәсендәге көрәшчеләр шөгыльләнә, алар җиңәм, дип кенә йөрми, ә осталыкларын да камилләштерү юнәлешендә эшли. Бездә Сурдлимпия уеннары җиңүчесе Эдуард Ширазданов, дөнья чемпионы Исмаил Насрулаев һәм башкалар тәрбияләнә. Утыздан артык укучыбыз спорт мастеры булды. Ирешелгәннәрдә генә туктап калырга җыенмыйбыз, – дип сөйли Рәис Садыйков.

Барысы да моннан күп еллар элек Бөгелмәнең ишетмәүчеләр өчен интернат-мәктәбендә тәрбияләнүчеләрнең көрәш белән кызыксынып китүеннән башлана. Озак еллар секциянең даими базасы да булмый. 2011 елда Бөгелмәдә балалар һәм үсмерләрнең «Факел» спорт мәктәбе ачыла, һәм көрәшчеләр шунда күчә. Әмма көрәш белән шөгыльләнергә теләүчеләр саны арта, уңышлар да үзләрен көттерми. Һәм Бөгелмә муниципаль районы башлыгы, Бөгелмә шәһәре мэры Ленар Закиров башлангычы, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән 2017 елда Бөгелмәдә чын Көрәш сарае ачылды, анда аз хәрәкәтләнүче төркемнәргә дә спорт белән шөгыльләнү өчен уңайлыклар тудырылган. Бүген Рәис Садыйковта һәм тренер-укытучы Алексей Антоновта грек-рим көрәше һәм ишетмәүчеләр спорты белән 177 яшь һәм өлкән спортчы шөгыльләнә, шул исәптән сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгәннәр дә – 39 кеше. Ә инде җиңү баскычларын яулаганнар «Факел»да һәм Россия төбәкләренең спорт мәктәпләрендә көрәшергә өйрәтә.

БАЛАЛАРГА ҺӘМ СПОРТКА – ИҢ ЯХШЫСЫ

– Зур ярышларда Бөгелмәдән килгән теләктәшлек иң җылысы һәм көтеп алынганы, – ди 23 яшьлек йөзүче Александр Красных. Ул 2016 елда Рио-де-Жанейрода узган җәйге Олимпиадада бишенче урын алган иде, ә 2017 һәм 2018 елларда йөзү буенча иң эре чемпионатларда алтын медаль яулады. Александр Россиянең атказанган тренеры Сергей Кузнецовта тәрбияләнгән.

«Факел» ачылгач, аларның 25 метрлы заманча бассейнда тренировкалар үткәрү мөмкинлеге барлыкка килгән. 2010 елда «Газпром – балаларга» Федераль программасы буенча төзелгән «Факел» буйлап экскурсия ясарга була. Волейбол, баскетбол, мини-футбол белән шөгыльләнү өчен җиһазландырылган универсаль спорт залы. Алты юллы бассейн, суын ультрашәмәхә нурлар ярдәмендә чистарту системасы. Аэробика залы, өстәл теннисы залы, коры йөзү залы һәм киокусинкай белән дзюдо бүлекләре өчен төзекләндерелгән өч зал – кирәкле барлык җиһазлары да бар, барысы да өр-яңа кебек күренә, югыйсә барысы да туп-тулы: биредә тәрбияләнүчеләрнең гомуми саны сигез йөздән артыграк.

ПЕДАГОГИК АЛЫМ

– Комплекс ачылуга безнең нәтиҗәләрне яхшырту мөмкинлекләре дә артты, һәм алар үзләрен көттермәде. Һәрбер уку елы яңа җиңүләр белән билгеләнә. Узган сезонда озак еллар буена беренче тапкыр безнең волейболчы кызларыбыз Татарстан Республикасының җыелма командасы составына керде һәм волейбол буенча Россия беренчелегенең ярымфиналында дүртенче урынга чыкты, ә юниор Тимур Миңнетдинов Идел буе федераль округы беренчелегендә алтын яулады, – дип сөйли мәктәпнең директоры Петр Никитин. Ул Бөгелмәдә әлеге искиткеч спорт комплексы, аның янәшәсендә чын футбол кыры, волейбол һәм баскетбол мәйданчыклары, тренажер зонасы барлыкка килсен өчен күп тырышлыклар куйган кеше. – Эш, билгеле, инфраструктурада гына түгел. Безнең педагоглар гаҗәеп яхшы. Тренер-укытучыларның барысы да югары белемле, дүртесенең югары квалификация категориясе бар, уникесе – беренче квалификация категорияле. Сергей Кузнецов һәм Рәис Садыйков – Россиянең атказанган тренерлары, дзюдо укытучысы Индус Фәттахов – Татарстан Республикасының атказанган тренеры. Тагын 12 тренер-педагогыбыз «Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт отличнигы» билгесе белән бүләкләнгән. Без ел саен Бөтенроссия һәм республика бәйгеләрендә җиңүләр яулыйбыз. Ә 2017 елда балалар һәм үсмерләр өчен спорт мәктәпләренең республика рейтингында икенче булдык.

Чемпионнарның тәрбиясе тренировкалар белән генә чикләнми. Үсмер вакытта хәтта иң сәләтле балалар да башка нәрсә белән мавыгып китәргә, үзендә шикләнә башларга яки, киресенчә, җиңүләрдән башларын югалтырга мөмкин.

– Баланың үзе сайлаган спорт төрен ташларга ниятләвен сизеп алуга, әгәр аның менә дигән нәтиҗәләргә ирешерлеге бар икән, без аны кызыксындыру һәм калдыру өчен кулдан килгәннең барысын да эшлибез, – дип сөйли директорның укыту-тәрбия эшләре буенча урынбасары Ольга Гафиятуллина. – Бу мәктәп җитәкчелегенең, тренерның, ата-аналарның, спортчының сыйныф җитәкчеләренең уртак тырышлыгы, һәм ул җиңел генә бирелми. Ләкин уңышлар барысын да аклый.

Фото: Александр Ефремов, «Факел» спорт мәктәбеннән алынды

Реклама

Что делать зимой в Дубае?
Там просто жара!
Ни вьюг, ни метелей,
Ни снега, ни льда…

Такие погоды – не наше,
Не твоё, не моё!
Хочется ёлок, снегурок,
Оливье – ё-моё!

Хочется, чтобы в печке
Пылал огонёк.
Хочется прям из баньки
Нырнуть в сугроб!

Чтоб Дед Мороз подарки
Нам приносил,
Чтоб оливье мандаринкою
Он закусил…

Хочется тёплого снега,
Душевного льда…
Это вас ждёт в татарстанских
Дубаях всегда!



Элитный ресторан • Банкетный зал • Конференц-зал • Тренажёрный зал
4 корта для большого тенниса • Бассейн • Сауна • Баня-люкс • Массаж
Пейнтбол • Аренда лошадей • Арбалет и лук • Гостевые дома

Дубай
гостевой комплекс

422700 Россия, РТ, Высокая Гора,
8 (927) 419-29-66, 8 (960) 048-54-66
e-mail: dubai-k-m@mail.ru

www.gk-dubai.ru

Реклама.
Фото: Александр Ефремов

ИБРАҺИМ ХАН ҺӘМ АНЫҢ УЛЛАРЫ

Казанның беренче ханы Мәхмүт үлгәннән соң, бераз вакыт (якынча 1465–1467 елларда дип уйланыла) ханлык белән аның олы улы Хәлил идарә итеп ала. Бу хан турында тарихи язмаларда бернинди мәгълүмат сакланмаган. Шунысы гына билгеле: аны Мангыт ыруыннан булган Нугай бәге Тимернең Нурсолтан исемле кызына өйләндерәләр. Шул ук елны Хәлил үлеп китә. Тәхеткә Мәхмүтнең икенче улы Ибраһим утыра. Шул заманнардагы йола буенча Нурсолтан Ибраһим хан белән никахлаша. Ибраһим ханның Фатыйма исемле хатыныннан туган өч (Илһам, Ходайкол, Мәлик-Таһир), Нурсолтаннан ике улы була (Мөхәммәдәмин, Габделлатыйф). Шуларның өчесе – Илһам, Мөхәммәдәмин һәм Габделлатыйф – төрлесе төрле вакытта Казан тәхетен биләп торалар.

Автор:
Фаяз Хуҗин

ИБРАҺИМ ХАН
(1467–1478 ЕЛЛАР)

Хәлил хан вафатыннан соң, Казан аксөякләре арасында килеп туган каршылыклардан файдаланып, Мәскәү хөкүмәте бушап калган хан тәхетенә Касыйм ханлыгының беренче идарәчесен – Касыйм ханны кую өчен көрәшә. Ләкин аның Казанга 1467 елда Мәскәү ярдәме белән оештырылган явы уңышсыз тәгәлләнә. Казанлылар Иван III нең мәкерле планын тиз аңлап алалар, тәхеткә Хәлилнең бертуган энесе Ибраһимны утыртып куялар.

Ибраһим ханлык белән уңышлы гына идарә иткәндер дип уйларга нигез бар. Һәрхәлдә бу чорда илнең икътисадый куәте шактый үсә, чит дәүләтләр белән сәүдә мөнәсәбәтләре ныгый. Әмма халыкара хәл катлаулана бара.

Ибраһим хан идарә иткән чорда Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III Казан ханлыгына каршы агрессив планнарын тормышка ашыра башлый. Шушы чорда башланып киткән Мәскәү – Казан сугышлары Иван III нең улы Василий III вакытында дәвам итә һәм оныгы Иван IV вакытында Казан ханлыгының җимерелүе белән тәмамлана.

1469 елның язында Мәскәү дәүләте Казанга беренче тапкыр зур яу оештыра. Устюг шәһәрендә тупланган отряд Казанны Вятка, Кама һәм Идел аша көньяктан, Түбән Новгород отряды төньяктан килеп камап алырга тиеш була. План уңышлы чыкмый: отрядлар Казанга төрле вакытта килеп җитәләр. Шулай да шәһәр бистәләре яндырыла, талана. Нәтиҗәдә Иван III сугышчылары үзләренең төп максатларына ирешә алмыйлар. Әмма Казан белән Мәскәү арасында төзелгән солых килешүе соңгылары файдасына була: Ибраһим хан Мәскәүгә башкалада тупланган барлык рус әсирләрен кире кайтарып бирергә ризалаша. Искәртеп үтик: әсирләрне чынлыкта коллар дип атарга мөмкин, аларның күбесен Казанның коллар базарында Кырым, Әстерхан, Урта Азия һәм Якын Көнчыгыш дәүләтләреннән килгән сәүдәгәрләргә сатып җибәргәннәр. Бу сәүдә бик табышлы саналган һәм ханлык икътисадында сизелерлек роль уйнаган. Әсирләрнең бер өлешен хуҗалыкта, бигрәк тә һөнәрчелектә файдаланганнар.

Казан.
Рәссам Ф. Халиков.

Мәскәү белән Казан арасында сигез ел буена сугышлар булмый (вак бәрелешләрне исәпкә алмаганда). 1478 елның кышында казанлылар Хлынов шәһәренә яу чабалар, ә бу җирләрне Иван III үз дәүләтенә кушарга ниятләп йөри. Аңа Казанга яу җибәрер өчен шул гына кирәк тә: Ибраһим хан солых килешүен бозды дигән сылтау табып, Мәскәү хөкүмәте Казанга каршы сугыш башлый. Ахыр чиктә бу юлы да рус гаскәрләре җиңелә.

Шул ук елны (кайбер мәгълүматлар буенча, 1479 елда) Ибраһим гүр иясе була. Аның Нурсолтан исемле хатыны яшь улы Габделлатыйф белән Кырымга – Бакчасарайга китә һәм анда Миңлегәрәй ханга кияүгә чыга.

ИЛҺАМ ХАН
(1478–1487 ЕЛЛАР)

Ибраһим хан үлгәннән соң хан тәхете өчен кискен көрәш башлана. Илһам – аның Фатыйма-солтаннан туган өлкән улы, Казан аксөякләренең Нугай морзалары, Урта Азия белән бәйләнгән төркеме тарафдары. Мөхәммәдәмин кандидатурасы исә казанлыларның Мәскәүгә караган төркеме тарафыннан яклана. Ногай татарларының көчле (шул исәптән – хәрби) басымы нәтиҗәсендә тәхеткә Илһам утыртыла. Ун яшьлек Мөхәммәдәминне әнисе хозурына Бакчасарайга түгел, ә Мәскәүгә, Иван III карамагына озаталар. «Туенып тору» өчен аңа Кашира шәһәрен бирәләр.

1482 елда Мәскәү хөкүмәте Казанга каршы олы яу әзерли. Рус гаскәрләре Түбән Новгородка килеп җитәләр, әмма шул вакытта Илһам Мәскәүдән солых килешүе төзүне үтенә. Иван III әлеге үтенечне кабул итә (солых шартлары турында мәгълүматыбыз юк), сугыш булмыйча кала.

1485 елда Мәскәү гаскәре Илһам ханны тәхетеннән куып җибәрә. Хан итеп Мөхәммәдәминне игълан итәләр. Яңа хан хөкүмәте файдалы эшкә яраксыз булып чыга, гади халык та, Мәскәү яклы аксөякләр төркеме дә аннан үзенең канәгатьсезлеген белдерә. Күп тә үтми, хан тәхетен Нугай гаскәрләре ярдәмендә яңадан Илһам яулап ала. Мәскәү моңа каршы килми.

1487 елның язында Казанга тагын бер олы яу оештырала. Илһам хан сугышчылары Мәскәү гаскәренә нык каршылык күрсәтә алмый. 18 майда Иван III сугышчылары Казанны камауга керешәләр. Шәһәр халкы аяусыз көрәшә, әмма, тарихи документларда әйтелгәнчә, Илһамның булдыксызлыгы аркасында, югалтулар күп була. Ачуы чыккан казанлылар аны тәхетеннән бәреп төшерәләр һәм урыслар кулына тапшыралар. 9 июльдә шәһәр капкалары ачыла, Иван III гаскәре Казанны яулап ала. Илһам хан, аның хатыннары, Мәлик-Таһир һәм Ходайкол исемле туганнары, сеңелләре, әнисе Фатыйма-солтан кулга алыналар һәм Мәскәүгә озатылалар. Аларның берсе дә бүтән Казанга әйләнеп кайта алмый (дөрес, Илһамның бер хатыны, ире үлгәннән соң, Мөхәммәдәмингә кияүгә чыга). Илһам үзе берничә елдан соң Вологда шәһәрендә дөнья куя. Аңа 40 яшьләр тирәсе була.

Илһамның туганнары Белоозерога һәм шул тирәдәге кечкенә шәһәрләргә сөреләләр. Фатыйма-солтан һәм Мәлик-Таһир Каргаломда үләләр. Мәлик-Таһирның ике улы да чукындырала. Аларның берсе, Федор Мелик-Тагирович исемлесе, 1530 нчы елларда Новгород наместнигы булып тора.

Касыйм шәһәре. XVII гасыр.

Ходайколны исә Мәскәүгә чакыртып алалар һәм әсирлектән азат итәләр. Петр/Ходайкол Ибрагимович бөек кенәз Василий III нең сеңлесенә өйләнә. Ул 1552 елда вафат, Мәскәүнең Архангел соборында күмелгән. (Сүз уңаеннан: Петр/Ходайколның бер кызы Василий Шуйскийга кияүгә чыга; икенче кызының улы, ягъни Петр/Ходайколның оныгы – Иван Федорович Мстиславский, аның кызы – элеккеге Касыйм ханы Саин-Булатның хатыны. Саин-Булат – Иван IV патшалык иткәндә вакытлыча «царь всея Руси» булып торган атаклы Симеон Бекбулатович ул).

МӨХӘММӘДӘМИН ХАН
(1487–1496)
ҺӘМ МӘСКӘҮ ПРОТЕКТОРАТЫ

Югарыда әйтелгәнчә, Мөхәммәдәмин яшьтән үк Мәскәү тәрбиясе алган шәхес. Аны, син Казан ханы булырга тиешсең, дип гел үсендереп торалар. Һәм чыннан да ул үзен булачак хан итеп тоя. 1485 елда аңа бу хыялын тормышка ашырырга мөмкинлек бирәләр, тик бу омтылыш уңышсызлыкка очрый.

1487 елгы сугыш Казан ханлыгының мөстәкыйльлегенә чик куя. Мәскәүнең бөек кенәзе Иван III тәхеткә Мөхәммәдәминне утырта, әмма үзенең күпсанлы титулларына «князь Болгарский» дигәнен дә өстәргә онытмый. Казанда рус протектораты урнаша һәм ул 1521 елга кадәр, тәхетне Кырымнан килгән Сәхибгәрәй хан яулап алганчы дәвам итә.

Казан белән Мәскәү арасында төзелгән солых килешүе нигезендә Казан ханнары Мәскәүгә каршы сугышлар алып бармаска, рус әсирләрен тулысынча азат итәргә, рус сәүдәгәрләренә иркенләп сәүдә итү өчен уңай шартлар тудырырга тиеш булалар. Солых килешүендә казанлыларны һич тә тыныч калдыра алмый, аларның ачуын чыгара торган тагын бер шарт була: алар Мәскәү рөхсәтеннән башка тәхеткә яңа хан сайлап кую хокукыннан да мәхрүм ителәләр. Мәскәүгә бәйлелек беренче карашка бик вак булып күренгән нәрсәләрдә дә сизелә. Мәсәлән, Мөхәммәдәмин, нугай морзасы Муса кызына өйләнергә теләвен әйтеп, Мәскәүгә хат юллый. Кәләш сайлауга Иван III каршы килми һәм рәсми никахка рөхсәтен бирә. Хан гаскәрләре Мәскәү кенәзләренең кайбер сугышларында да катнашалар.

Мөхәммәдәмин солых килешүе шартларын төгәл үтәп барырга тырыша. Мәскәүгә бәйлелек Казан аксөякләре арасында кискен ризасызлык тудыра. 1490 нчы еллар башында хөкүмәткә каршы оппозиция оеша. Оппозиция башында торган Коләхмәт, Урак, Садыйр һәм Агиш карачыбәкләр, күршеләре Себер ханына мөрәҗәгать итеп, Казан тәхетенә Мамук ханзадәне чакыралар. 1496 елда Себердән Мамук гаскәрләре, алар артыннан Мөхәммәдәмин яклы рус гаскәрләре Казанга юнәләләр. Мамук җиңүгә ирешә һәм хан тәхетен яулап ала. Әмма озакка түгел. Күчмә тормыш шартларында тәрбияләнеп үскән Себер ханы көчле икътисады, мәдәнияте һәм халыкара абруе булган Казан ханлыгы белән идарә итәргә бөтенләй сәләтсез булып чыга. Нинди сәбәптәндер Арча каласына яу чабып кайткач, Мамук ханны башкалага кертмиләр. Казанны болай да өнәп бетермәгән хан кире үз ватанына кайтып китәргә мәҗбүр була.

ГАБДЕЛЛАТЫЙФ ХАН
(1496–1502 ЕЛЛАР)

Хәтерләсәгез, әнисе Нурсолтан, Ибраһим хан үлгәннән соң, аны үзе белән Кырымга алып киткән иде. Балигъ булганчыга кадәр ул Бакчасарайда тәрбияләнә. Үги әтисе кырыс булгангамы, балигъ булгач, аны Миңлегәрәй хан Мәскәүгә озата. Бөек кенәз Иван III аны хезмәткә ала һәм уделга, «туенып тору өчен» Звенигород шәһәрен бирә. Ул вакытта Мәскәүгә җибәрелгән абыйсы Мөхәммәдәминнең уделы Кашира була.

Мамуктан соң бушап калган хан тәхетенә Иван III Габделлатыйфны билгели. Мөхәммәдәмин, әлбәттә, бик хурлана, ризасызлыгын белдерә. Иван III аның күңелен күтәреп җибәрү өчен, Каширага өстәп, тагын Серпухов һәм Хотунь шәһәрләрен уделга бирә.

20 яшьлек Габделлатыйф башлыча Бакчасарайда тәрбияләнгән ханзадә, Мәскәүдә ул озак яшәми, русларның гореф-гадәтләре аның өчен ят була, аларны һич тә үзенеке итеп кабул итә алмый. Аңлашыла ки, Габделлатыйф әле Мәскәү тарафдары булып өлгермәгән була. Әйе, ул тәхеткә күтәрелүгә Мәскәү белән Казан арасында төзелгән 1487 елгы солых килешүе яңартыла. Яңа хан ул шартларның һичшиксез үтәлергә тиешлеге турында да кисәтелә. Баштарак ул чыннан да тышкы сәясәттә Мәскәүгә кара эш йөртә. Әмма ханлык белән идарә итү дәверендә аның алдында беренче чиратта Мәскәү түгел, ә Казан мәнфәгатьләре тора. Һәм бу табигый рәвештә Габделлатыйф-

ның Мәскәү белән мөнәсәбәтләрен катлауландыра. Элеккеге оппозиция җитәкчесе Коләхмәт тә, Габделлатыйфка каршы чыгып, Мәскәү ягына авыша.

1502 ел башында Казанга Мәскәүдән рус илчелеге килеп төшә. Габделлатыйф хан тәхеттән куыла. Аны әсир итеп Мәскәүгә, аннан соң Белоозерога сөргенгә озаталар. 1510 елның җәендә әнисе Нурсолтанның Мәскәүгә уңышлы сәфәре нәтиҗәсендә Иван III нең Кырым һәм Казан ханнары белән мөнәсәбәтләре бераз яхшыргач, Габделлатыйфны сөргеннән Мәскәүгә кайтаралар, ул Кашира шәһәрендә яши башлый. 1515 елда Миңлегәрәй вафат булгач, Мәскәү белән Бакчасарай арасындагы мөнәсәбәтләр бозыла. Өстәвенә, ул вакытта Казан тәхетендә утырган Мөхәммәдәминнең сәламәтлеге дә куркыныч астында була. Ул үлгән очракта тәхеткә яңадан Габделлатыйфны чакырырга теләүчеләр дә табыла. 1518 елны ноябрендә (кайбер мәгълүматлар буенча, бераз элегрәк) Габделлатыйф кәтмәгәндә үлеп китә.

ТӘХЕТТӘ ЯҢАДАН МӨХӘММӘДӘМИН
(1502–1518 ЕЛЛАР)

1496 елда хан тәхетеннән бәреп төшерелгәч, Мөхәммәдәмин Мәскәүгә озатыла һәм биредә Иван III гә хезмәт итә башлый. Рус елъязмаларында аның Ливон сугышында катнашуы турында мәгълүматлар сакланган. 1500 елда ул хәтта, номиналь төстә булса да, рус армиясенең башкомандующие итеп билгеләнә. 1502 елда Мәскәү гаскәрләре ярдәме белән Мөхәммәдәмин яңадан Казан тәхетенә күтәрелә. Ул, һичшиксез, иң әүвәл Мәскәү мәнфәгатьләрен күз алдында тотып эш итә торган идарәче була. Әмма ханлык башкаласында туган яңа шартлар, сәяси көчләр чагыштырмасы аны бу юлы башкачарак сәясәт алып барырга мәҗбүр итә. Ул халыкның ризасызлыгыннан, баш күтәрүеннән, сәяси төркемнәрнең фетнәләреннән курка һәм, теләсә-теләмәсә дә, Мәскәү мәнфәгатьләрен икенче планга калдырып торырга карар бирә. Алай гына да түгел, яңа сәясәт Мөхәммәдәминне Мәскәүнең дошманына әверелдерә.

Тәхеткә килүгә, Мөхәммәдәмин Мәскәү яклы төркемнең башында торган хөкүмәт җитәкчесе Коләхмәтне үзеннән читләштерә. Аны кулга алалар, хөкемгә тарталар һәм үтерәләр. Мөхәммәдәмин Мәскәү кенәзе Иван III нең сәламәтлеге турында да белешеп тора. Ул инде картайган, көчсезләнгән, аның үлемен генә көтеп торалар. Бу хәлләр Мөхәммәдәмингә Мәскәү сәясәтенә кыю рәвештә каршы чыгарга нигез бирә.

Сугыш 1505 елның җәендә, Мәскәү өчен һич көтелмәгән вакытта башланып китә. 24 июньдә, ел саен үткәрелә торган Казан ярминкәсенең беренче көнендә, бик күп, исәпсез-сансыз рус сәүдәгәрләре үтерелә, әсирлеккә алына, товарлары талана. Гомумән, Казан җирендәге русларның барысын да кол хәленә төшерәләр. Аларны тиз арада көньяк базарларына сатып җибәрәләр.

Көзен исә Мөхәммәдәмин хан Мәскәү дәүләтенә чын сугыш игълан итә. 40 мең казанлылардан һәм 20 мең Нугай татарларыннан торган гаскәр Түбән Новгородны камап ала, бистәләрен яндыра, әмма Кремльне ала алмыйча, кире чигенәләр. Рус хөкүмәте Мөхәммәдәмингә каршы 100 меңлек гаскәр туплый, әмма оешмаган, начар коралланган отрядлар Муромга җиткәч бөтенләй таркалып бетәләр. Казанлылар Ока елгасы буйлап урнашкан авыл-шәһәрләрне талап китәләр.

Сугыш хәрәкәтләре 1506 елда да дәвам итә. Рус гаскәрләре 22 майда Казанга килеп җитәләр, әмма аларның һөҗүмнәре уңышсыз тәмамлана. 22 июньдә казанлылар русларның атлы гаскәрен дә җиңелүгә дучар итәләр. Руслар Мөхәммәдәминне Мәскәүгә дә яу чабар дип көтәләр, әмма Казан ханы һөҗүмне туктата. 1507 елның мартында Казан белән Мәскәү арасында сөйләшүләр башлана. Ике дәүләт арасында солых килешүе төзелә, нәтиҗәдә Мөхәммәдәмин элеккеге, 1487 елгы килешү шартларын үтәргә ризалыгын бирә. Мондый сәер сәясәтне тарихчылар болай аңлата: Иван III тарафыннан хан тәхетенә утыртылган Мөхәммәдәмин шундый хәлгә куелган ки, ул Мәскәүгә дә ярарга тиеш, Казан халкы да аннан йөз чөермәсен. Үзенең «милләтпәрвәрлеген» ул Казан ярминкәсендә үтереш-талаш оештырып, Мәскәүгә тугрылыган исә элеккеге солых килешүе шартларын икърар итеп раслады.

Мөхәммәдәмин 1518 елда озак авырудан соң вафат була. Җәсәде Казан ханнары төрбәсендә җирләнгән.

Казанны алу.
Рәссам К. Бениг.

Казан бүреге.
XVI гасыр уртасы.

КЕШЕ КИТӘ, ҖЫРЫ КАЛА...

Тормышта безнең ихтыярга бәйле булмаган нәрсәләр бар. Әйтик, туу белән үлем. Аның беренчесе бик күңелле булса да, икенчесе – хәтәр. Якыннарын, тирәдәгеләрен сагышка салып, кеше дөньялыктан китеп бара...

Без быел да арабыздан киткән кадерле милләттәшләрбезне барлыйбыз. Алар барысы да күңелләрдә якты эз калдырып киттеләр.

НАИЛ АЛАНЛЫ
(11 ИЮНЬ)

Башкаларга охшамаган, үзенчәлекле фикерле, кыю кешеләр була. Шундыйларның берсе – Наил Аланлы (Наил Вазыйх улы Хисамиев). Күпләр аны «Азатлык» радиосы корреспонденты буларак белә. Үлеме дә көтелмәгәнчә һәм аяныч булды: Көнбатыш Африканың Кабо-Верде Республикасына ялга баргач, йөрәге туктаган.

Наил Аланлы тумышы белән Татарстаннан булса да, гомеренең күп өлешен читтә үткәрә. 17 ел Төмәндә яши. Университетның татар теле бүлеген тәмамлагач, Себер якларына – балаларга татар теле укытырга дип чыгып китә. Укытучы булып эшләп йөргән җиреннән бу яшь, фикерле егетне Татарстан дәүләт радиосына эшкә чакыралар. Татар теленең чит төбәкләрдә дә чәчәк аткан чоры – «Дусларга сукмак» исемле тапшыру алып бара башлый ул. Шуннан инде «Азатлык»ка чакыралар. Прагага күченә. Анда журналистлык эшен алып бару белән бергә, яшьләргә татар теле дә өйрәтә, махсус курслар ача.

Бер әңгәмәсендә Наил абый үзе турында болай ди:

– Мин үземне кыю журналист дип санамыйм. Сүриягә барып, андагы вазгыятьне ничек бар, шулай сурәтли алсам, вәт булыр иде. Туган проблема турында министрга, йә булмаса хакимият кешесенә шалтырату өчен кыюлык кирәк димени?!

Чынлыкта исә һәр фикерендә кыюлык, милләтен ярату ярылып ята иде аның.

Татарстан Фәннәр академиясенең вице-президенты, әдәбият галиме Дания Заһидуллина Наил Аланлы турында болай диде:

– Наилнең һәр язмасы милләткә, халыкка багышланган. Ул халык яхшырак яшәсен өчен, тел һәм мәдәният сакланып калсын өчен тырышты. Үзенең сүзе белән халкыбызны уятырга тырышты. Алан авылында мәктәпнең сакланып калуында, Татарстандагы күп кенә авылларда мәктәпләрнең ябылмавында Наилнең өлеше бик зур. Аның җәсәден туган ягына алып кайтканда Татарстан Хөкүмәте, хезмәттәшләре, дуслары ярдәм итте. Бу Наилне зурлауның, кем икәнлеген аңлауның бер чагылышы иде... »

Наил Аланлы туган ягында – Теләче районы Алан авылында җирләнде.

ФӘҺИМӘ ХИСАМОВА
(17 СЕНТЯБРЬ)

Филология фәннәре докторы, профессор, Халыкара төрки академия әгъзасы, Татарстанның атказанган укытучысы, ТРның атказанган фән эшлеклесе... Кыскасы, гомерен фәнгә багышлаган галимә иде ул.

Татар филологиясе факультетында белем биргән мөгаллимнәр, анда укыган студентлар Фәһимә апаны бик яхшы белә һәм чиксез хөрмәт белән искә ала. Белемле, итагатьле һәм зыялы иде, диләр. Гаиләсе өчен – кайгыртучан ана да. Тормыш иптәше, шулай ук күренекле галим Нурмөхәммәт Хисамов белән өч ул тәрбияләп үстерәләр алар. Өчесе дә милли җанлы, югары белемле зыялы кешеләр. Игезәк уллары Айдар белән Нияз – рәссам, алары Татарстанда, Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә беләләр. Олы уллары Айваз – белеме буенча тарихчы, соңгы елларда эшмәкәрлек белән шөгыльләнә.

Оныкларым Ләйлә белән Зөһрә Нурмөхәммәт белән минем юлдан киттеләр. Татар теле бүлеген тәмамладылар. Филология фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә ирештеләр, – дип горурланып сөйләгән иде бер Фәһимә апа.

Галимәне җирләргә бик күп халык – татар милләтенең күренекле вәкилләре җыелган иде. Бу мизгелләрдә тормыш иптәше – Нурмөхәммәт абыйга бигрәк тә кыен булгандыр. Картайган көндә дә җитәкләшеп кенә йөргән пар иделәр бу икәү. Нурмөхәммәт абый, кадерле тормыш иптәше белән хушлашканда:

– Фәһимә шәкертләренә балаларына караган кебек карый иде. «Мин беркемгә дә начарлык эшләмәдем, шәкертләремә беркайчан тупас сүз әйтмәдем», – дип сөенә иде... Мин аңа, үз итеп, «бәбчегем» дип эндәшә идем. Аннан башка ничек яшәрмен, күз алдыма да китерә алмыйм?! Фәһимә, хаҗда булып, пәйгамбәр каберен күргән кеше. Ахирәттә дә шундый затлардан ерак булма, җанкисәгем...» – диде.

Фәһимә Хисамованы Казанның мөселман зиратына җирләделәр.

ШӘФӘГАТЬ САЛИХОВ
(27 ОКТЯБРЬ)

Үкенечле, фаҗигале үлемнәр була. Алар турында ишеткәч: «Аһ, ничек шулай килеп чыккан?» – дип сыкрап куясың. Татарның тагын бер талантлы улы – танылган баянчы, әле алтмыш яшен күптән түгел генә билгеләп үткән Шәфәгать Салиховның үлеме дә шундыйрак. Казан-Чаллы трассасында юл һәлакәтенә очрап вафат булды ул.

Шәфәгать Салиховны күпләр Салават Фәтхетдиновның беренче баянчысы буларак белә. Нәкъ шул елларда халык күңеленә кереп, популярлык казана да ул. Гаиләдә дүрт бала үсәләр. Әтисе дә – авылның атаклы гармунчысы. Якыннары нәни Шәфәгать турында сөйләгәндә «кечкенәдән гармунга тартылды», ди. Хәтта йомычкалар җыеп, шуны гармун итеп тотып йөргәннәрен дә искә алып сөйлиләр. Моны күреп, әтисе нәни улына гармун алып бирә.

8 нче сыйныфны тәмамлагач, яшь гармунчы Лениногорск шәһәренең музыка училищесына укырга керә. Аны тәмамлагач, туган авылына – Азнакай районы Татар Шуганы авылына сәнгать җитәкчесе булып кайта. Ансамбль оештырып, аны республика дәрәҗәсендә таныта. 1983 елда Чаллы шәһәренең Төзүчеләр мәдәният сараена эшкә урнаша. Шунда Салават Фәтхетдинов белән танышып, җырчының иҗат төркеменә кушыла. 11 сезон Салават төркемендә эшли. Соңгы елларда җырчы Руслан Кираметдинов белән хезмәттәшлек итә. Концертларда, банкетларда чыгыш ясый.

Гармунчының гаилә хәле гади генә түгел: яшьли кавышып, ике бала үстергән тормыш иптәше Мөршидә кинәт кенә вафат була. Шуннан Шәфәгать абый хатынының бертуган апасының кызы Ларисага өйләнә. Бер кыз, бер уллары туа. Яңа гаиләсенә куанып, тормышка зур планнар корып яшәгән мәлдә гомере әнә шулай кинәт кенә өзелде дә куйды.

Шәфәгать Салиховны туган ягында – Азнакай районының Татар Шуганы авылында җирләделәр.

РАУЗА ХӘЙРЕТДИНОВА
(15 НОЯБРЬ)

90 яшендә Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Рауза Хәйретдинова вафат булды. Сәхнәдә иҗат итә башлаган чорында лирик пландагы яшь кызлар, бигрәк тә музыкаль рольләрне башкарган актриса соңрак үткен, чая характерлы образлар да тудыра. Мисал өчен, «Зәңгәр шәл»дәге – Мәйсәрә, «Галиябану»дагы – Галиябану, «Гүзәлем Әсәл»дәге – Хәдичә, «Таң атканда»дагы – Гөлбикә, «Татар хатыныниләр күрми»дәге – Гөлбану, «Әниләр һәм бәбиләр»дәге – Вазифа, «Рәхәт яшибез»дәге – Волчанская һәм башка күп кенә образлар.

Рауза апа үзен бәхетле тоеп яши. Тормыш иптәше Нуретдин абый белән соңгы көненә кадәр тигезлектә гомер итә. Бер-берсен аңлап, хөрмәтләп яшәүче парлар булалар.

Ә иҗаттагы бәхете турында сөйләп бетергесез... Алтмыш елга якын татар сәхнәсендә иҗат итү чорында ул легендар сәхнә йолдызлары – Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская, Галия Булатова, Галия Нигъмәтуллина һ.б. белән бер сәхнәдә уйный. «Мине алар үз әртилләренә керттеләр. Бу легендар театр артистларыннан күп нәрсәләргә өйрәндем. Мин аларга бик рәхмәтле», – дип әйткән иде бер әңгәмәсендә Рауза апа.

Рауза Хәйретдинованың моңлы, матур тавышы турында да искәртеп үтәргә кирәк. Шуңа да аңа еш кына җырлы рольләр биргәннәр. Әле күп вакыт сәхнә артыннан кеше өчен дә җырлап торган. Төрле концертларда чыгыш ясаган. Зифа Басыйрова белән дә бер сәхнәдә җырлаган.

– Бәхетем – тырышлыкта, тормышны яратуда, – дия торган була Рауза Хәйретдинова. – Бер урында утырып, сыктап яшәмәдем. Йөзләгән рольләр башкардым. Алар тамашачы күңеленә барып җитте. Олыгая барган саен кеше үзенең үткән тормышын сагына, аңа бәя бирә. «Дөрес яшәгәнмен», – дим. Кеше теленә кермәдем. Коллегаларым белән яхшы мөнәсәбәттә булдым. Мин бәхетле. Тамашачыма теләгем шул – тормыш авырлыкларын көлеп үткәрергә тырышыгыз!»

Рауза апа Хәйретдинованы Казанның Яңа татар бистәсе зиратында җирләделәр.

СӘКИНӘ ШӘЙМИЕВА
(16 НОЯБРЬ)

Татарстанның беренче Президенты, хәзерге Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең хатыны Сәкинә Шәймиева каты авырудан соң арабыздан китеп барды. Яшьли кавышып, 57 ел бергә гомер иткән үрнәк пар иде Шәймиевләр. Сәкинә ханымны якыннан белгән кешеләр: «Бик ярдәмчел, кече күңелле, сабыр хатын һәм уңган хуҗабикә», – диләр. Ярдәмчел дигәннән, Сәкинә ханым базарда сатучы әбиләрдән башлап (яшелчә, җиләк-җимеш сатып утыра торган өлкәннәрнең бар әйберен сатып ала торган була), туганнары, танышларына кадәр гел ярдәм кулы сузып яшәде. Уңган хуҗабикә булуына бер генә дәлил: алар гаиләсендә йорт эшләре башкаручы махсус кеше булмый. Сәкинә ханым барысын да фәкать үзе эшли.

Журналыбызның март санында Минтимер Шәрипович белән әңгәмә биргән идек. Анда Татарстанның беренче Президенты үзенең яраткан хатын-кызлары турында сөйләде. Тормыш иптәше турында ул: «Президент хатынына «әйләнүгә» килгәндә... дөресен әйтим, аның бер дә үзгәрәсе килмәде. Башта, Минзәләдә «Сельхозтехника» районара берләшмәсендә идарәче булып эшләгән җиремнән Казанга күчергәндә, ул катгый каршы төште. Чөнки безнең үз хуҗалыгыбыз, йортыбыз бар иде. Аңа анда бик ошый, оҗмахтагы кебек яшим, дия иде. Ә инде мин президент булгач, бу югары вазыйфаның кайчан тәмамланачагын көтеп яшәде. Гомумән алганда, «өйдәге оппозиция» булды, мин аны, шаяртып, шулай атыйм.

Ул минем күбрәк өйдә торуым турында хыялланды һәм, мин республика президенты вазыйфасыннан киткәч, җиңел сулап куйды. Әмма иртәрәк өметләнде шул! Без Болгар белән Зөяне яңартырга тотындык, һәм мин тагын көнетөне эштә югала башладым. Ул бу хыялына һаман ирешмәде кебек...»

Сәкинә ханым белән хушлашу Казанның Мәрҗани мәчетендә узды. Анда дәүләт эшлеклеләре, танылган шәхесләр, хезмәттәшләре, гомумән, Шәймиевләрнең тирән кайгысын уртаклашкан якыннары җыелган иде. ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Әхмәтов мәрхүмә турында бик җылы сүзләр әйтте:

– Минтимер Шәриповичның күңел халәтен бик тирән аңлыйбыз, чөнки алар Сәкинә апа белән бер җан булып гомер иттеләр. Искиткеч матур яшәделәр. Аларның бер-берсенә булган мөнәсәбәтен читтән күзәттек һәм үзебезгә чын гаилә үрнәге буларак кабул иттек. Сәкинә апа искиткеч матур, мәхәббәтле, гүзәл апабыз иде. Ул кешеләрдә бары матурлык күрә иде. Күңеле белән һәр көн игелек таратып яшәде. Аның күңел сафлыгына, эчке чисталыгына гел соклана идек...

Сәкинә Шәймиеваны Казанның Яңа татар бистәсе зиратында, әтисе-әнисе, зур абыйсы Мөбәрәкҗан һәм энесе Галимҗан белән янәшә җирләделәр.

РӨСТӘМ ЗӘКУАН
(2 ДЕКАБРЬ)

Шагыйрь, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Рөстәм Зәкуан да каты авырудан соң арабыздан китеп барды.

Рөстәм абый журналистика факультетын тәмамлап, иҗат белән яшьтән кызыксынса да, әдәбиятка шактый соң, илле яшьләрендә генә килә. Гомеренең күп өлешен авыл хуҗалыгы тармагында үткәрә.

– Минем шигырьләргә язылган җырлар шулай тиз арада хитка әйләнер дип һич уйламый идем, – дигән иде Рөстәм абый бер әңгәмәсендә. Чынлап та, аның бик күп җырлары – хит, популяр артистлар тарафыннан яратып башкарыла.

Туган ягы – Азнакай районы Үчәлле авылында егерме еллап эшләгәннән соң (хуҗалык рәисе урынбасары, совхоз директоры) Казанга килә. 2007 елда аны ТР Язучылар берлегенә кабул итәләр. 2009 елдан «Таттелеком» компаниясенең матбугат хезмәте җитәкчесе вазыйфасын башкара. Оешманың директоры Лотфулла Шәфигуллин белән берлектә мәдәни мирасны саклау юнәлешендә күп эшләр башкара. Мисал өчен 20дән артык чишмәне төзекләндерү, музейларны, батырларча һәлак булганнарга куелган һәйкәлләрне, зиратларны торгызу һ.б.

– Якташлар буларак, без аның белән еш аралаштык, – дип искә алды Татарстан һәм Россиянең халык артисты Әзһәр Шакиров. – Ул бик моңлы, шигъри җанлы кеше иде. Мин аның беренче мәртәбә җырлаганын ишеткәч шаккаттым. Ходай бирсә дә бирә икән талантны кешегә. Оештыру эшләре, дисеңме, шигырь иҗат итүме... Гаиләсе өчен җан атып яшәүче ир дә, ата да... Эчке дөньясы бай, әдәбиятны тирәнтен тоемлаган кешеләрнең берсе иде ул...

Рөстәм Зәкуанны хәләл җефете Фәния Зәкуанның туган авылында – Биектау районының Мулмә авылында җирләделәр.

БЕЗГӘ УҢАЙЛЫ БУЛМАГАН КИНО, ЯКИ МИНЕМ ТАМАШАЧЫМ ӘЛЕ ТЕРЕМЕ?

Венеция, Канны, Берлин фестивальләрендә игътибарны җәлеп итеп, ниһаять, 2019 елгы Оскарга тәкъдим ителгән (яки ителми калган) премьераларны «парадлар парады» дип тамгаладылар быел. Хәер, «иң яхшы фильм»нарга төгәл генә шорт-бит юк әле... Чыннан да, агымдагы фестивальләр исемлеге төрлелеге һәм теләсә кайсы зәвыкны канәгатьләндерерлек премьералары белән күзне камаштыра. Аннан да бигрәк – жанрлар синтезы белән.

МЭТРДАН – СӘЛАМ, ЯКИ «МИН ТАМАШАЧЫ ӨЧЕН ТӨШЕРМИМ»

Хоррор тышчасына төрелгән картиналар – 2018 елның иң шау-шулы һәм прокат рейтингы үзәгендә торган премьералар. Быелгы сезонның иң кискен провакациясе дип, мөгаен, «Дом, который построил Джек» очрагын атарга кирәктер. Моңарчы төшергән һәр лентасы белән безнең нервларны кытыкларга, оялтырга, чиркандырырга яраткан, хәтта ки җирәнергә мәҗбүр итүдән тәм тапкан Ларс фон Триер бу юлы үзенең апогеена җитте, дисәк, әллә ни ялгышмабыз... Хәер, Триер очрагында монысын да тәгаен генә әйтеп булмый.

Фильмны быел Канны фестивалендә конкурс программасыннан тыш күрсәттеләр. Хәтерлибез, 7 ел элек Каннда Гитлерга симпатиясе көчле булуы турында белдергән Триер яшен тизлегендә фаворитлардан фестивальнең нон грата персонасына әверелгән иде. Инде ситуация үзгәрде шикелле... Әмма режиссёрның фестивальгә дә, бүгенге кино сәнгатенең йөзен билгеләүчеләргә дә үпкәсе барыбер калган булып чыкты. «Дом» фильмын күпмедер дәрәҗәдә Канн публикасына пародия, мэтрның үче дип таптылар. Кайбер тәнкыйтьчеләр аны гомумән «Канныга урта бармак күрсәтү» дип бәяләде. Әмма шәхси мотивлар белән бәйләп, артык тар кысаларга гына кертеп кую Триерның феноменын тарайту, үзен кимсетү булыр иде. Ничек кенә булмасын һәм нинди генә булмасын, аның фикер колачы киңрәк, карашы үткенрәк...

Автор:
Луиза Янсуар

Деструктив вектор буенча курс алган яңа Триер постмодерн кысаларындагы ысулларны эшкә җигә. Әмма бу деструктивлыкның яңача чишелеше булырга тиеш, дигән өмет уяна. Фильмда юкка гына яңа Данте калкып чыкмый лабаса. Һәм ул кызыл халат киеп алган Вердж (Вергилийга сылтама булуы аермачык) исемле юлдашы белән юкка гына көймәдә дә йөзми. Әйе, бу үз эчендәге хәлләрне, тирәлегендәге һәм гомумән заман, дөнья масштабындагы тәмугка әверелеп барган вазгыятьне ваемларга тырышу. Әмма безгә кайчан да булса һәм кем дә булса тәмуган чыгу юлын күрсәтергә тиештер бит инде?

> *«Нинди дә булса бер кеше эшләгән, хәтта уйлаган гына нәрсәләрнең дә экранда яшәргә хокукы бар, дип исәплим. Минем омтылышларымны уен-көлке, кәмит дип атап буламы икән? Белмим. Кайчак сәнгатьне чәйнәп йоту – авыр галәмәт. Үземне тамашачы өчен эшлим, дип тә әйтә алмыйм. Үзең өчен эшләп, бары тик үзеңне генә аудитория дип исәпләргә дә була. Публикага ошый торган түгел, үзеңә ошый торган кино төшерү мөмкинлеге – казаныш ул. «Дом, который построил Джек» картинасы, минемчә, халыкны тиешле дәрәҗәдә җенләндерми, җирәндерми әле. Әгәр ул популяр булып китсә, миңа ул чакта зур проблема туачак».*
>
> *Ларс фон Триерның әңгәмәләреннән.*

Әйе, асылда фильм – конкурс программасына керми калып, призларга дәгъва кылудан азат булып утлап йөрүче тәртәгә ияләнмәгән «җанвар» гына түгел, ул гомумән – яхшылык белән яманлык чикләренең аргы ягында торучы «хәшәрәт». Бу лентада берниндиүлчәүләр, кысалар, мораль нормалар юк. Кадр артындагы тавыш кына бар – ул безнең чыганагы билгесез компасыбыз.

Музыка һәм тавышлар биредә һәр нюансы, һәр детале белән кызыклы, үзенчәлекле. Интертекстуаль яктан Бах та, Гленн Гульд та, Вагнер да билгеле бер кодларга алып чыга, шул ук вакытта алар Триерга үз героеның гадәти маньяк, үтерүче генә түгел икәнлеген дәлилләү юнәлешендәге бер алым да.

Кайчандыр безне «Американский психопат» сәер халәттә калдырган иде, исегездәме? Хәзер инде без аны ни өчен һәм нәрсә хакына икәнлеген тәгаенрәк беләбез. Экранда тудырылган Джек – Триер шәрехе буенча, иҗатчы, сәнгатькә хезмәт итүче. Юкка гына Данте белән турыдан-туры параллель уздырмый бит инде ул. Укучының, ә аннан тамашачының да кайчандыр Зюскиндның һәм Тыкверның Жан-Батист Гренуйына мөкиббән булганын, «Парфюмер» белән сәташканын хәтерлибез бит? Менә монда да, абстракция аръягына чыгып, салкын канлы күзәтүчегә әверелергә, дидактикадан азат булган парадигманы анализларга чакыра безне режиссёр.

Ярый, каһарман белән якыннанрак танышыйк. Гадәти бер урта яшьләрдәге Америка гражданины, инженер. Хыялында – архитектор, рәссам, сынчы. Чынлыкта – психологик почеркы анык кына тәгаен булмаган маньяк. Үтерүләр аның өчен – «инцидент» һәм «иҗади акт». Хатын-кызлармы, ир-атлармы – әллә ни мөһим түгел. Иҗат стихияле булырга тиеш бит инде, аны кысаларга кертеп утыртсаң, үзегез аңлыйсыз, илһам китә... Хәер, артык илһам алуын да тоеп булмый Джекның: сөмсере гел коелган, йөзен болыт баскан. Бу картина бик күңелсез һәм озакка сузылган депрессив клаустрофобиягә әверелер иде, әмма Триерның үзенчәлекле кара юморы белән ул гына оештыра алган трэш аны хәтта урыны-урыны белән ягымлы, рәхәт тә итә. Пародия тоемына китереп, эстетик ләззәт бирә. Мәсәлән, бер кадрда Джек, үз шәрехләрен тыңлый-тыңлый, психиатрия клиникасы пациенты кебек, безгә – тамашачысына – туптуры карап, картоннарга язылган диагнозларын күрсәтә. Бу да – массачыл акт. Бу да – бүгенге инфантиль игътибарны җәлеп итү ысулы.

Без аның турында бернинди артык фактлар белмибез, режиссёр боларны тәгаенләп торуны кирәк тапмый. Чөнки ул асылда инферналь объект белән эш итә. Хәер, Триер өчен каһарманын социаль ансамбльдә күрсәтү беркайчан да өстенлек булмады. Мэтт Диллон үз персонажын искиткеч нечкәлек, виртуозлык белән уйный. Мэтр теләгәнчә, нәкъ менә шушындагы аерым бер конкрет зат та, җир йөзендәге барлык маньякларны үзендә туплаган типаж да ул. Башта моны ваемламыйбыз әле, әмма ваемлап өлгергәч, аның гамәлләрендәге диссонанс шунда ук бер гармоник эзлеклелеккә җыела. Бу – бик тәэсирле алым, шунда ук искә тагын бер картина килеп төшә: моннан ике ел элек экраннарга чыккан М. Найт Шьямаланның «Сплит»ы. Ул Дэниел Кизның «Множественные умы Билли Миллигана» әсәренә нигезләнеп төшерелгән иде...

«Чәрдәкләнгән аң» һәм бер кешедә күп «мин»нәрнең яшәү теориясе (ахыр чиктә, безнең барыбызның да чиксез бер «мин»гә барып тоташуын алга сөргән гипотезалар) соңгы дистә ел эчендә инде шактый чәйнәлеп тә, ялыктырып та өлгерде. Кайбер фаразлар буенча, безнең бүгенге «мин»ебез социаль челтәрләрдәге аккаунтларга чәчелеп, бүлгәләнеп, таралган да, үзебездән аерым диярлек яши һәм киләчәктә кеше үзаңы инде янә җыелмаячак, фрагментар булып калачак. Без үзебезнең чын асылыбызны югалтачакбыз...

Джек – әкиятләргә кереп, шомлы-куркыныч төсмер алган Синяя Борода (реаль тормышта – Жиль де Рэ) да, XIX гасыр азагында Лондонны шок халәтендә калдырган һәм куркуда тоткан Джек-Потрошитель да, Советлар Союзында нонсенс булган Чикатило да... Шулай ук персонаж эчендәге персонаж да: Роберт Блохның повестендагы канунга әверелгән Норман Бейтска, «Американский психопат»тагы нарцисс Патрик Бэйтманга сылтама, аерым алганда. Ягъни, дискурс эчендәге дискурс. Триер безне янә постмодерн лабиринтлары буйлап йөртә, әмма аның буяулары эре итеп ягылган, символикасы аермачык диярлек укыла, шуңа урыны-урыны белән ачыктан-ачык көлке дә. Бигрәк тә каһарманның Үлем трансформациясе булуын ваемлагач, тәгәрәп көләсе килә: Триер аны Елисей басуларындагы чалгычы рәвешендә гротеск белән сурәтли.

Триер каһарманына корбаннардан инсталляцияләр ясатып, ә ахыр чиктә, алардан йортын төзергә кирәк икәнлегенә дә инандырып, безнең бүгенге җәмгыятьнең үлеп баруына ишарә итә түгелме? Автор-иҗатчы гына түгел, ә аның публикасы, аудиториясе дә үз агониясендә, диюеме? Үле манекеннар, үле сәнгать, үле тамашачы... Бәлки, апогейга җиткереп, сискәндереп, тетрәндереп, олыгаеп баручы Триер сынап карарга телидер: минем тамашачым әле тереме?

Триерның Каннда әйтелгән саксыз фразасын янә искә төшерик әле. Контексттан тартып чыгарып, чиксез күпертеп, хайп ясамадылармы соң режиссёрның үзеннән дә? Бәлки, шуңа да ул бик озак үпкә саклагандыр? Хәер, ул чакта «хайп» төшенчәсе әле юк иде... Үзенә кадәрге кыю режиссёрларның берсе – Пазолини төсмерләре аермачык чагыла «Дом»да. Шулай ук Бергман да. Триер, нәкъ менә алар шикелле, тоталитар практика, көч куллану, кешенең табигатендәге явызлыкның тамырларын өйрәнүдән аермачык тәм тама. Һәм – сәнгатьчә буларак, ул моңа хокуклы. Ләкин икенче ягы да бар: Триер безгә бит бүгенге турында сөйли, еш кына, ул бүгенгене гомумән мифологик-глобаль тышчаларга төреп бирә. Каннга урта бармак күрсәтүдә гаепләүчеләр аның бу жестында, бәлки, система эчендәге үзләре белгән системага мөнәсәбәт барын абайлагандыр?

«Мин катарсиска, сәнгать аша дәвалауга, хэппи эндка беркайчан да ышанмадым һәм ышанмыйм да». Әйе, бу Триер. Һәм без аның Триерлыгына бу картинадан соң инде ышанмас дәрәҗәдә инандык.

ФАШИЗМ ТУРЫНДА ЯҢАДАН, ЯКИ ҮТКӘНГӘ РЕВЕРАНС

29 ноябрьдә Россия прокатына Лука Гуаданьинонның көтелгән «Суспирия»се чыкты. Аны әле продакшн вакытында ук «интерьерлардагы биюләр» дип тә, «фильм-ассамбляж» дип тә, «гедонистлар өчен хоррор» дип тә, «йолдызлы галерея» дип тә атадылар. Бу ярлыкларның барысы да кәнфит кәгазенә тиң. Әмма ул сыйфатлы, хәтта ки крафт кәгазенә төрелгән кәнфитне без ба-

рыбыз да тешләп йота алмаска мөмкинбез. Без ияләшмәгән тәмгә ия чөнки. Аннан да бигрәк, ул тәм тел төбеннән тиз генә китми, озак бимазалый…

Әйе, бу – бик уңайсыз продукт. Гап-гади тамашачы өчен дә, «кино чытырманы»нда нәрсәдер ваемлаучы, әзерлекле, күпмедер дәрәҗәдә циник фикер калыбы булган караучылар өчен дә, азау ярган тәнкыйтьчеләр өчен дә. Җитмәсә, бу тарихның үзенә кадәрге тарихы да бар – легендасы. Сүз атаклы хоррор остасы, джалло жанрын үстерүче Италия режиссёры Дарио Арджентоның 1977 елда экраннарга чыккан «Суспирия»се турында бара. Хәер, дөресен генә әйткәндә, быелгы премьераның баштан ук ремейк булачагына шик бар иде. Гуаданьино, беренче «Суспирия» хакында сүз алып барганда, әңгәмәләрендә үк инде Ардженто белән озакка сузылган дискуссиядә булуын күрсәтте. «Мин Ардженто картинасын беренче тапкыр 10 яшемдә карадым. Җете ачык төсләре белән күзне камаштырган постерына юлыгуга ук әсир итте. Минем инде ул чакта үскәч режиссёр булам, дигән ниятем тәгаенләнгән иде. Ардженто фильмын карагач, кайчан да булса аңа ремейк төшерергә хыяллана башладым», – ди Гуаданьино бер әңгәмәсендә.

Гуаданьинога хәзер, аз да түгел, күп тә түгел, 47 яшь, ә ул хәлләрдән соң инде 3 дистә ел узган. Бу – тулы бер гомергә сузылган мәхәббәт һәм бәхетле очракны (ягъни, тиешле актёрлар составын, композиторны, локацияне… һәм йолдызларның билгеле ноктага җыелуын) көткән язмыш бүләге, дисәк тә, ялгышмабыз. Яңа «Суспирия»не юкка гына «йолдызлы галерея» дип атамыйлар: Дакота Джонсон, режиссёрның аерылгысыз музасы Тильда Суинтон, Хлоя Грейс Мориц, Миа Гот, Малгоша Бела, Ангела Винклер, Сильви Тестю, Алек Вик… Алар арасында беренче «Суспирия»дә төшкән актриса, үз чорының арт хаус иконасы Джессика Харпер да бар. Тагын бер йолдыз – чыгышы белән Россиядән булган хореограф, хәзерге көндә атаклы Бельгия хореографы һәм режиссёры Вим Вандекбейкусның Ultima Vez труппасы биючесе Елена Фокина. Биюгә килгәндә, барлык актрисалар да фильмны төшергәнче (һәм төшерү барышында) профессиональ дәресләр алып, хореография белән шөгыльләнә…

«Минем персонажым биюнең җимергеч көчен дә, башка персонажлар арасындагы драматик коллизияләрне күрсәтүче дә төен булып тора. Лука бу фильмда хәрәкәт аша һәр героеның характерын ачып күрсәтүне максат итеп куйды, аның эмоциональ спектрын, градацияләрен… Барлык персонажлар да хәрәкәт текстурасын исәпкә алып уйланды һәм эшләнде. Кемдер фильмда җимергеч энергетика, агрессия күп, дияр. Ә кемнәрдер, аның азагында чын мәгънәсендә позитив кичереп, вертикаль буенча Югарыга тоташыр. Мин табигать көчләренә дә, кешеләрдәге һәм җимерү, һәм яңарту сәләтенә дә ышанам. Фильмдагы хәлләр, вакыйгаларның, аерым бер чор кисемтәсен алып күрсәтсә дә, һәр заман өчен актуаль булуына да…»

Елена Фокина белән әңгәмәдән.

Гуаданьиноны конъюнктурага йөз тотуда гаепләделәр. Һәм, әйтергә кирәк, ул моны үзе алдан ук белеп тора иде. Кайчандыр беренче «Суспирия»гә Туллио Кечич исемле мәртәбәле Италия кино тәнкыйтьчесе язган рецензиядә Арджентоны феминизм идеяләрен алга сөрүче дип тәгаенләгәннәр иде. Узган гасырның 70 нче елларында Италияне, бөтен Европаны чолгап алган ул феминизм дулкынына, Арджентоның үзеннән бигрәк, Гуаданьино якынрак тора, дисәк, дөресрәк булыр. 2018 елгы «Суспирия» нәкъ менә беренчесе экраннарга чыккан елдан башланып та китә. Бу – Гуаданьиноның мэтрга реверансы. Әмма нәкъ шушы этәрелү ноктасын алуы юктан гына түгел. Режиссёрны берничә дистә ел элек булган хәлләрнең бүгенгегә биргән чагылышы кызыксындыра. Җитмәсә, яшьлеген, җитлегү елларын бүгенге күзлектән торып ваемлый. Кайчандыр Райнер Фассбиндер фильмнарында да тәрбияләнгән Гуаданьино бию һәм мифологияне нәкъ менә тарихи полотнога «тегеп куюын» яшерми дә.

Асылда, чорның катаклизмнары аша ул борынгырак катламнарга төшә. «Мине Явызлыкның тамырлары кызыксындыра, ә ул фашизмга кадәр бик күптән булган, битлекләре бик күп төрле», – ди режиссёр. Һәм «алман көзе» ситуациясен камераның бер чите белән эләктереп алып, хроникаларны кадрга «тегеп куеп», бездәге аң катламының да төпкелләренә мөрәҗәгать итә. Экранда кунакханә бүлмәсендәге тәрәзәләрне ачкан Миа Гот героинясы Америкадан яңа гына килгән Дакота Джонсон героинясына террорчылык акты турында сөйли: промышленник Ханнс Мартин Шлейерны үтерделәр, ди. Бию мәктәбендәге юкка чыккан студентканы Мадам Бланк «Кызыл армия фракциясе» белән бәйләнгән дип исәпли, сәяси карашлары өчен харап булды, дип кызгана да, позициясе барлыгы өчен соклана да. Кадрлар булып Lufthansa самолетын Палестинаның Халык фронты вәкилләреннән азат итү турындагы хроникалар уза…

«Миңа өч сихерче ханымның тарихы нәкъ менә Явызлык тарихының бер кисемтәсен ваемлау өчен кирәк иде», – ди Гуаданьино. Һәм нәкъ менә Европаны алуы да, бик яхшы аңлыйбыз, юкка түгел. Шулай ук Европа үзәгендәге икегә бүленгән, дивар белән аерып алынган, ике ягы ике дөньяны тәшкил иткән Берлинны төп локация булырак тәкъдим ителүе дә – символик код. Ә менә монда Американың Огайо шәһәреннән меннонитлар арасында үскән Сюзины китерүе һәм аның аша системаны үзгәртеп коруы, Европа белән Америка арасындагы мөнәсәбәтләргә глобаль киная ясавы.. – монысы, әйтергә кирәк, шактый кыю адым. Сюзи, ахыр чиктә, бөтен конструктларны алыштыручыга әверелә.

Виктор Клемперер исемле филологның «Язык Третьего рейха» дип аталган һәм безнең көннәргәчә сакланып калган көндәлекләрен еш искә ала Гуаданьино. Алар тоталитаризмның кеше аңына ни рәвешле сеңдерелүе турында бәян итә, ди: сөйләшү манерасы, үзеңне тоту кагыйдәләре, тел һәм лексиканың трансформацияләре. Клемперер образы фильмга шул ук фамилиядә кереп тә китә. Әйтергә кирәк, яңа «Суспирия» ул – оммажлар калейдоскобы. Фильмдагы психиатр Йозеф Клемперер да – шуларның берсе.

Яраткан ысулы буенча, барлык иҗади төркемне – команданы алдан ук бергә туплый Гуаданьино. «Гаилә әгъзалары» съёмкага кадәр һәм аның барышында, мөмкин булганча, бер пространствода яши: кафеларга йөриләр, кичләрен бергә уздыралар, уеннар уйныйлар, шаяралар, көләләр… «Мин командамның олы бер дус гаилә булуын яратам, һәм фильмнан

соң да, без барыбер гаилә булып калабыз», – дип еш кабатлый режиссёр. Фильмда исә бу инде куркыныч төсмер алган рефрен булып яңгырый: «Монда, Бию академиясендә, без – бер гаилә», – ди сихерче ханымнарның җимергеч гамәлләренә ышанырга теләмәгән бер студентка.

Гуаданьино локацияне һәрвакыт җентекләп сайлый: съёмкаларның иң әһәмиятле өлешләре Германиянең үзендә түгел, ә Италиядәге, биек тау башындагы иске кунакханәдә уза. Варезе белән янәшә урнашкан Гранд Отель 1968 елдан бирле бикләп куелган булса да, режиссёр аны хакимияттән соратып ала. Шомлы, хәтта ки дәһшәтле, үз легендалары булган урын, дип искә алалар замокны. Актерлар аның кыштырдаулар, сәер тавышлар белән тулы булуын хәтерли һаман. Актриса Миа Гот бер көнне замоктан кафега төшүләре турында искә ала. Алар утырган һәм ашаган кафеда, баксаң, үз заманында, әле фашизмның яралып кына килгән чагында, Гитлер нотык белән чыгыш ясаган булган. Менә бу да – Гуаданьинонның детальләре, кодлары...

Ардженто картинасының төп умырткасы – Өч Бөек Ана турындагы миф. Гуаданьино үзенә кадәрге режиссёр нигез итеп алган бу теманы десакрализациягә дучар итеп, бөтенләй башка чишелеш тәкъдим итә. Өч Ана турындагы миф идеясенә нигез салучы – Томас де Куинси исемле инглиз язучысы. «Suspiria de Profundis» дип исемләнгән хезмәтендә ул Мойралар (Язмыш алиһәләре), Хариталар (Тормыш һәм Шатлык алиһәләре) булган кебек үк, Сагышның да өч алиһәсе бар, ди. Алиһә дию бик үк дөрес булмас, алар Беренчел Хаостан башланган барлык караңгылыкны үзләрендә чагылдыручы Бөек Сихерчеләр, дип ассызыклый. Өч Ана исеме белән тарихка кергән алар. Имештер, нәкъ менә шул өчәү дөньядагы глобаль яманлык белән идарә итә: сугышлар, үтерешләр, күз яшьләре... Матриархат чорына барып тоташкан инануларны чагылдырган миф буенча, Өч Ана тарихы XI гасырда башлана. Кара диңгез ярындагы бер авылда дөньяга киләләр дә Җир йөзендәге караңгы көчләр белән идарә итүне үз кулларына алалар. XIX гасыр азагына кадәр төрле империяләрдә хакимнәр кулы белән дә, палачлар кулы белән дә идарә итәләр. XIX гасыр азагында күренекле итальян архитекторы Варелли аларга өч йорт – замок төзеп бирә.

«Җәмгыятьнең нигезен система, шул система белән идарә итүче кечкенә оешмалар, берләшмәләр, кешеләр төркеме хасил итә. Әмма һәр кеше үзе өчен үзе җаваплы. Олы Явызлык ул гадәти бер кечкенә кешедән, төркемнән, оешмадан башлана да, кабарып, глобаль колач ала...» – дип фикер йөртә Гуаданьино. Гадәти көндәлек шартларда тасвирлап, ул Аналарны аерым бер тарихи җирлеккә бәйләп куя, персонификацияли. Mater Suspiriorum, ягъни Сулышлар Анасы, Германиядә, Шварцвальдта яши. Mater Lacrimarum, ягъни Күз яшьләре Анасы, Италиядә, Римда яши. Mater Tenebrarum, ягъни Караңгылык Анасы, Америкада, Нью-Йоркта яши. Суспириорум Ананың, кайбер оккультизм тарафдарлары ышануы буенча, исеме Елена Маркос була. Ул реаль шәхескә барып тоташа. Фильмда без Елена Маркос оештырган Бию академиясенә килеп эләгәбез. Имештер, бу ханым оккультизм буенча күпсанлы китаплар язган, ритуаллар уздыра торган булган, Европадагы һәм дөньядагы иң көчле масон ложаларының мөһим әгъзасы исәпләнгән. Әнә шундый фаразлар яши аның хакында. Кайбер эзотерик чыганаклар буенча, 1905 елда, эзәрлекләүләрдән котылыр өчен, үзенең атаклы Варелли салган йортында – замогында үлемен фальсификацияли. Йортка ут төртеп, шунда янып үлгән, дип уйласыннар өчен.

Фильмның финалында Суспириорум Ана, моңа кадәр Явызлыкка өстенлек итәргә мөмкинлек биргән, аны туендырып торган Мадам Бланк гәүдәсен – тышчасын ташлап калдырып, кан яңарта. Ул инде каршыбызга кыюсыз гына күренгән Сюзи образында килеп баса. Кискен һәм көтелмәгән

финал тәкъдим итә Гуаданьино: без фашизм турындагы фильмнарда гына күргән кадрларны торгызып, Рейх чорында хатын-кызлар концлагерьларында барган коточкыч хәлләрне гәүдәләндерә. Әлеге дәһшәтле ритуал фонында җәза акты уздырыла:

– Нәрсә телисез сез? – дип сорый моңарчы ерткычлык өчен җавап биргән Ана корбаннарыннан.

– Үлем телибез, без шундый арыдык... – ди корбаннар. – Азат итегез безне бу газаплардан...

– Мин сезне азат итәм, биегез рәхәтләнеп! – ди борынгы кара көч. Камера безгә бу сценаны дөрләп торган ялкын камаган крематорий тәрәзәсе аша күрсәтә диярсең. Ә эчендәгеләр ачыргаланып кычкыра, елый, өзгәләнә...

– Биегез, – дип пышылдый Сюзи-Суспириорум. – Бу бию искиткеч...

Әнә шул мизгелдә бу явыз көчнең үз куллары белән ертып ачкан күкрәк читлегендә – йөрәгендә – миллионнарның тавышсыз кычкырганын күрәсең дә... имәнеп китәсең. Мин – сезнең авыртуларыгызны сыйдырып тибеп торган яра, диме ул безгә? Режиссер шул рәвешле яңа яшәү парадигмасы тәкъдим итәме? Дөнья рәхимлерәккә әвереләчәк, дип раслыймы? «Барысы да кулына хакимлек эләккән кешенең үзеннән тора», – диган иде бит бер әңгәмәсендә...

P.S. Фильмнарны, һичшиксез, кинотеатрларда, һәм бары тик яхшы, бик яхшы сыйфатта гына карарга киңәш итәм!

«Суспирия»гә саундтрекны Radiohead фронтмены Том Йорк яздыра. Нәтиҗәдә, тулы бер альбом пәйда була. Фильмның космологиясендә Йорк музыкасының роле искиткеч зур роль уйный. «Минем өчен Том Йорк кандидатурасы идеаль вариант иде. Тулы бер дәверне чагылдыручы музыкага ставка ясадым. Томнан башка, йә, кем?» – ди Лука Гуаданьино.

ЯЗЫЛ ҺӘМ ТЕЛЕВИЗОР ОТ!

БҮЛӘКЛӘР 2019 елның 15 февралендә УЙНАТЫЛАЧАК

телевизор

призлар!

1 ЯЗЫЛ **30.12.2018** кадәр «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең кимендә өч басмасына языл *(акциядә катнаша торган басмалар белән tatmedia.ru сайтында таныша аласың)*

2 ҖИБӘР язылу квитанцияләренең күчермәсен «Акция» билгесе белән түбәндәге адреска җибәр *(телефон номерыңны күрсәтергә онытма)*: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

3 ОТ Телевизор, фотоаппарат һәм башка бүләкләр!

Заявкалар 2019 елның 25 гыйнварына кадәр кабул ителә.

Акцияне үткәрү вакыты: 20.10.2018–20.03.2019
Акция турында тулырак – tatmedia.ru сайтында.
Оештыручысы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Белешмәләр өчен телефон:
(843) 222-09-84 өстәмә номер – 1261

16+
Реклама

МАХСУС ПРОЕКТ

— 37нче чыгарылыш —

Татарстан юбилярлары

Илшат Ганиев,
«Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ нең генераль директоры, гыйнварда үзенең 65 яшьлеген билгеләп үтә.

«МАЙСКИЙ» УҢЫШЫ

Моннан 30 еллап элек ул «Майский» совхозына җитәкчелек итә башлый һәм беренче булып бу совхоздан Россиядәге бердәнбер теплица предприятиесен ясый. Аның мәйданнары ел әйләнәсендә 42 мең тоннадан артыграк күләмдә яшелчә җитештерүгә көчерелә. Илшат Ганиев бүген дә барысы да диярлек үз куллары белән булдырылган «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнә җитәкчелек итә.

ГОЛЛАНДЛАРГА КӨНДӘШ БУЛЫП

Казаннан «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнә барып җитәр өчен ярты сәгатьләп вакыт кирәк. Шәһәр, республика кешеләренең һәм Россиянең байтак төбәкләре халкының табыннарына яңа өлгергән яшелчәләр һәм яшел тәмләткечләр нәкъ менә биредән китерелә.

Ярты гасырга якын элегрәк нигезләнгән «Майский», үзе оешканнан бирле экологик чиста продукция җитештереп, аерым танылу алды. Бүген ул бөтен Россия кешеләренә билгеле бренд. Агымдагы елда комбинат үз тарихында беренче тапкыр яшелчә җитештерүдә 40 мең чиген узып китте. Бүгенге көндә ул – теплица яшелчәчелегенең иң камил технологиясе булган «яктылык культурасы» белән яшелчә үстерүче иң эре Европа комбинатларының берсе. «Майский» продукциясенең сыйфаты, аның экологиясе һәм уңышлылыгы, үсемлекләрне корткычлардан саклау, хуҗалык белгечләре куллана торган технологияләр шул дәрәҗәдә югары – аңа дөнья яшелчәчелеге флагманнары булган голландлар гына көндәш була ала. Ә хуҗалык хезмәткәрләре һәм белгечләре үзләре инанганча, боларның күбесенә җитәкчеләре – Илшат Ганиев тырышлыгы белән ирешелгән.

1976 елда Илшат Ганиев, КСХИны тәмамлап, үсемлекләрне саклаучы агроном буларак, «Майский» совхозына килгән. Кыска гына 13 ел дәвамында Илшат Газыймович агрономнан совхоз директорына кадәр карьера һәм профессиональ үсешнең төп этапларын узган. Бу вакыт эчендә аның тарафыннан фундаменталь агрономлык технологияләре салына: аз күләмле технология, биоысул, суны тамчылап сибү; шулардан башка хәзер сакланган грунтта заманча яшелчәчелекне күз алдына да китереп булмый. «Майский» ТКның генераль директоры буларак та, Илшат Ганиев яшелчә җитештерүнең заманча технологияләрен кертүне дәвам итә һәм хаклы рәвештә Россиядә «яктылык культурасы» технологиясенә нигез салучы булып санала, Россиянең бер генә нәтиҗәле теплица предприятиесе дә хәзер бу ысулны читләтеп үтми. Илшат Ганиев заманча агротехнологияләр кертеп кенә калмый, ул Россия теплица предприятиеләре арасында беренче булып комплекслы энергетика ситемасын да кертә, ә монысы үз җитештерүеңне арзанрак энергоресурслар белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

УҢЫШ ФАКТОРЫ

Илшат Ганиевның үзе җитәкчелек иткән предприятиегә керткән өлешен бәяләп бетергесез. Соңгы елларда Россиядә бер-бер артлы теплица базарының күп кенә әйдәп баручы катнашучылары ябылды. «Майский» исә бүген дә җитештерү егәрлеге буенча Россиядә әйдәп баручы булып тора.

Җитәкченең уңыш сере шунда – ул, җитештерүдә яңа процессларга керешкәндә, «старт»ны үз хезмәткәрләренең социаль-көнкүреш шартларын яхшыртудан башлый. Кешеләр һәрвакыт уңышның төп факторы булып тора. Предприятиедә даими тотрыклы югары квалификацияле персонал эшли. Комбинат хезмәткәрләре биредән лаеклы ялга гына китә.

Җитештерүдә хезмәтне саклау конкурсында катнашып, «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры EuropeAid 119764|C|SV|RU Европа комиссиясенең Россиядәге «Хезмәтне һәм куркынычсызлыкны саклау буенча норматив хокук базасын якынайту» проектында җиңүче дипломын алды.

Илшат ГАНИЕВ

«Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ генераль директоры, РТ Дәүләт Советының бишенче чакырылыш депутаты.

1976–1986 елларда – «Майский» совхозының үсемлекләрне саклау буенча агрономы, үсемлекләрне саклау буенча өлкән агрономы, цех башлыгы, баш агроном урынбасары, баш агрономы.

1986 елдан 1989 елга кадәр – КПСС-ның Татарстан өлкә комитетында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек сәнәгате бүлеге инструкторы. 1989 елдан – «Майский» совхозы (хәзер «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖ) җитәкчесе.

Хезмәт шартларын Европа дәрәҗәсенә җиткереп, комбинат үз хезмәткәрләренең яшәү шартларын яхшырту программасын тормышка ашыра: күпфатирлы йортлар төзелеше алып барыла, соңгы елларда күпфатирлы дүрт торак йорт, 44 һәм 55 фатирлы, янәшәдә 40 балага каралган балалар бакчалы ике тулай торак төзелгән. Волейбол, баскетбол мәйданнары һәм тренажёр залы булган ябык спорт комплексы эшли. Хезмәткәрләр карамагында шулай ук ачык спорт комплексы – футбол кыры, балалар мәйданчыгы, шугалак бар. Яшь гаиләләргә һәм пенсионерларга ярдәм күрсәтелә.

Узган еллар дәвамында «Майский» Осиново инфраструктурасын үстерү юнәлешендә дә күп эш башкарган. Комбинат 840 урынлы яңа мәктәп төзүдә катнашкан, ул бүгенге көндә республиканың

Реклама

иң яхшы 100 мәктәбе исемлегенә керә. Бердәнбер җирле медицина учреждениесе – амбулатория көндезге стационар итеп үзгәртелгән.

ЧИРАТКА БАС!

Әлбәттә, боларның барысына да предприятиенең тотрыклылыгы, технологияләренең камиллеге, продукциясенең ихтыяҗга ия булуы һәм аның тотрыклы рәвештә сатылуы нәтиҗәсендә ирешелгән. Ә бит 1992 елда комбинат белгечләре, дөньяда әйдәп баручы селекция агрофирмаларының берсе чакыруы буенча Голландиягә баргач, күргәннәренә шаккатып кайткан булганнар. Җирне диңгездән талап диярлек алырга мәҗбүр булган голландлар югары уңыш үстерә ала, аларның кибет киштәләрендә ел әйләнәсе яшелчә, ә без кай ягыбыз белән ким? Шундый азарт барлыкка килә! Яңа нәрсәләр уйлап чыгарасы, нәрсәнедер үзгәртәсе килә башлый... Мең кешелек коллективның күпьеллык эш нәтиҗәсе бүген күз алдында – бу «Майский» продукциясе сатылган кибетләрдәге сатып алучылар чираты.

ЯКТЫЛЫК СҮРЕЛМӘСЕН!

Теләсә кайсы авыл хуҗалыгы бизнесы, шул исәптән теплица бизнесының да тулыканлы үсеше өчен заманча җиһазлар һәм системалардан файдалану, өр-яңа технологияләр һәм гибридлар куллану гына түгел, үзең эшләгән тармакның үсеш тенденцияләре курсында булу һәм шулай ук әйдәп баручы белгечләр һәм экспертлар белән тәҗрибә уртаклашып тору да мөһим. Боларны бик яхшы аңлаган хәлдә, Илшат Газимович уникаль сәләтләргә ия. Ул җитәкче генә түгел, инженер да, галим дә, төзүче дә... Соңгысына Ганиевнең коллегалары комбинатта үз энергетика инфраструктурасы булдырылгач, тагын бер кат инанганнар. Ул максатчан программа ярдәмендә тормышка ашырылган. Бу эш «Майский»га технологияләргә сизелерлек модернизация һәм оптимизация ясарга, яшелчәләрне сезоннан тыш чорда да үстерергә мөмкинлек биргән. Россия аграрийлары өчен энергетика үзәге уникаль проект булып чыккан. Бүгенге көндә комбинат кирәкле энергия, җылылык һәм электрны тулысынча диярлек үз энергия чыганакларыннан ала.

«МАЙСКИЙ»ГА ТУГРЫЛЫК

Илшат Ганиев – көчле ихтыярлы холыкка ия, ул менә дигән карьера төзи алган. Ул хәзергәчә эш кешесе өчен иң куркынычы – эчке ялкаулык һәм кызыксынучанлык булмау дип саный. Төрле вакытларда аңа бик кызыклы тәкъдимнәр ясаганнар, ләкин югары вазифалардан ул, һичшиксез, яраткан «Майский» комбинатын өстен куйган.

«МАЙСКИЙ» БҮГЕН:

Иң эре яшелчә җитештерүче – елына **42 мең тонна** яшелчә;
Яшелчәләрнең уңышлылыгы буенча РФндә әйдәп баручы: кыяр уңышы – **кв. метрдан 203 кг**;
Кв. метрдан 113 кг – помидор уңышы;
126 МВт – казаннарның җылылык егәрлеге;
47 МВт – энергия үзәкләренең электр егәрлеге;
Корткычлар белән көрәшү өчен **1 млрд** энтомофаг күләмендә биоысул җитештерү буенча РФндә әйдәп баручы;
Үз торак комплексы, **20000 кв. метрдан** артыграк мәйданда фатирлары булган РФндәге бердәнбер теплица комбинаты;
35,8 га – теплицаларның мәйданы.

«Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнең зур һәм тату коллективы үзенең генераль директорын юбилее белән котлый! Илшат Газыймович, сезгә ихлас күңелдән иң изге теләкләребезне җиткерәбез! Сезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек, иминлек, энергия-дәрт телибез!

Фотолар «Майский» теплица комбинаты» ҖЧҖнән алынды.

Хәйриячелек традицияләрен саклап...

Надежда Кисиль,
«Раифа ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе директоры

– Хөрмәтле Илшат Газыйм улы! Сезгә юбилеегыз уңаеннан чын күңелдән ирештерелгән котлауларны кабул итеп алыгыз!

Аграр сектор – икътисадның гади бер тармагы гына түгел, ә республикабыз халкы өчен муллык нигезе ул. Сез Татарстан авыл хуҗалыгы предприятиеләре флагманнарының берсе булган «Майский» теплица комбинаты»н инде 30 елдан артык җитәклисез. Бүген ул – ябык грунтта яшелчә җитештерү буенча Россиянең иң эре предприятиесе. Бу бик зур җаваплылык! Һәм шунысы тирән хөрмәткә лаек: җитештерү эшенең җитди һәм мөһим бурычларын үтәгән хәлдә, Сез хәйриячелек һәм меценатлык традицияләрен тугры саклыйсыз.

Сез балаларның четерекле язмышларын күрә-аңлый беләсез, аларның үтенечләрен һәм проблемаларын, беркайчан игътибарсыз калдырмыйсыз. Безнең училищеда тәрбияләнүчеләргә һәрвакыт ихлас ярдәм күрсәткән өчен, Сезгә рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Тормышта балалар һәм оныкларыгыз өчен горурлык, шатлык хисләре кичерер өчен сәбәпләр мөмкин кадәр күбрәк булсын! Сезгә бәхет, нык сәламәтлек, яхшы кәеф телибез! Иң изге теләкләребез!

Фото «Раифа ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениесе» федераль дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесеннән алынды

Азат Бикмурзин,
«Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ
генераль директоры,
гыйнварда 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

Дмитрий Солуянов,
«Татэлектромонтаж»
АҖ генераль директоры

Алдынгы фикерле шәхес

Хөрмәтле Азат Шәүкәтович!

«Татэлектромонтаж» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм!

Безнең предприятие нигездә сәнәгать төзелеше тармагында эшли. Аның эшчәнлек өлкәсе – күләмле төзелешләр һәм сәнәгать объектлары. «Татэлектромонтаж» АҖ һәм «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖнең уртак проектлары кысаларында Сезнең белән хезмәттәшлек итү безнең өчен зур дәрәҗә булды.

Сез – бер урында таптанырга күнекмәгән кешеләр исәбендә. Белгеч һәм җитәкче булырак, Сез алдынгы фикергә йөз тоту, эшкә югары сәләтлелек, куәтле оештыру таланты белән һәрвакыт аерылып торасыз. «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖдә соңгы елларда республиканың һәм Россиянең нефть химиясе тармагы лидерларының берсе булып калырга мөмкинлек бирә торган үзгәрешләр булды һәм алар дәвам итә. Шуңа күрә «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ тарафыннан Сезнең җитәкчелектә гамәлгә ашырылган иң яхшы эшләрнең үсешкә баруын, дәвам итүен, ә яңа проектлар һәм башлангычларга һәрвакыт уңыш юлдаш булуын телибез. Туганнарыгыз һәм якыннарыгыз һәрвакыт янәшәдә булып, аларның ярдәме яңа җиңүләрнең нигезен тәшкил итсен!

Реклама   Фото «Татэлектромонтаж» акционерлык җәмгыятеннән алынды.

Павел Кочнев,
«Союзхимпромпроект»
ПИ «КМТТУ» ЮББ ФДББУ
директоры

Яңа проектлар, казанышлар…

Хөрмәтле Азат Шәүкәтович!

«Союзхимпромпроект» проект институты җитәкчелеге һәм коллективы 50 яшьлек юбилеегызга чын күңелдән, зур хөрмәт белән котлаулар юллый!

Сез – Татарстан Республикасы икътисадының флагманы һәм Россия нефть химиясе сәнәгатендәге иң мөһим предприятиеләрнең берсе булган «Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ штурвалын ил тормышы өчен шактый катлаулы чорда кулыгызга алдыгыз. Бөтендөнья икътисадындагы сәүдә сугышлары, икътисадый санкцияләр һәм финанс өлкәсендәге чикләүләр, салым кануннарының һич фаразланмаслык үзгәрешләре…

Мондый шартларда гигант предприятие белән җитәкчелек итү, җитештерү һәм икътисадый күрсәткечләр үсешен, яңа җитештерү куәтләре кертүне тәэмин итү һәм предприятие коллективы мәнфәгатьләрендә җаваплы социаль сәясәт үткәрү өчен, ныклы ихтыяр көче, ару-талу белмәү, максатчанлык, үз предприятиең һәм аның коллективы, туган калаң һәм илең өчен эшләү теләге кирәк.

Сез бу сыйфатларның барлык арсеналына ия! Институтыбыз проекты буенча хәзерләнгән колачлы инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда катнашканда, һәм Сез җитәкләгән «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятенең, бәлки әле, киләчәктәге стратегик үсеш проектларында да предприятиегезнең ышанычын аклауны үзебез өчен горурлык, дәрәҗә дип саныйбыз.

Сезгә ныклы сәламәтлек, энергия, оптимизм юлдаш булсын! Сезгә ерак киләчәкне күзаллаган планнарыгызның һәм проектларыгызның чынга ашуын, лаеклы, ышанычлы партнерлар телибез!

Фото «Союзхимпромпроект» ПИ «КМТТУ» ЮББ ФДББУнән алынды.

ПОЗИС 120 еллыгын бәйрәм итә!

Инновацияләр юлында

Реклама

Борис Тихомиров,
«Казан Гипронииавиапром» АҖ генераль директоры

Игорь Дюгуров,
«Казан Гипронииавиапром» Инжиниринг компаниясе» ЖЧҖ генераль директоры

Хөрмәтле Радик Шәүкәтович!

«Казан Гипронииавиапром» АҖ коллективы исеменнән сезне һәм «ПОЗИС» АҖ коллективын юбилей белән котлыйбыз!

«ПОЗИС» АҖнең 120 еллык бай үткәне – Россия тарихында игътибарны җәлеп итә торган сәхифә. Илдә йөз елдан артык тарихы булган предприятиеләр күп түгел, ә ПОЗИС – аларның иң эреләреннән берсе. Француз акционерлары нигез салган һәм 1917 елда дәүләт кулына күчкән, Беренче бөтендөнья сугышы вакытында оборона продукциясе җитештерә башлаган кечкенә мануфактура еллар дәвамында күппрофильле, югары технологияле, диверсификацияләнгән предприятиегә әверелә. Бөек Ватан сугышы вакытында артиллерия өчен кече калибрлы һәр өченче снаряд Сезнең предприятиедә җитештерелә. Сугыш тәмамланганнан соң беренче елларда ук гражданлык продукциясе тармагын үстерү башлана. Бүгенге көндә сезнең продукция белән барлык төр һәм юнәлештәге диярлек гаскәрләрнең һәм көч структураларының 120 дән артык коралы, хәрби техника төрләре тәэмин ителә. Бер үк вакытта моңарчы күрелмәгән зур күләмдә көнкүреш суыткычлары, медицина өлкәсе өчен суыткыч җиһазлары җитештерелә, шул исәптән алар экспортка да озатыла – Сезнең продукция Европа берлегендә дә, якын һәм ерак чит илләрдә дә билгеле.

Болар барысы да инновацияле үсешкә, яңа технологияләргә таяну нәтиҗәсендә мөмкин булды; бүген сезгә илнең эре дәүләт корпорацияләре инженерлык заказлары белән мөрәҗәгать итә. Сезгә күп кенә предприятиеләр кызыгып карый, чөнки заводның бар тарихында кайгыртучанлык белән үстерелгән эшче һәм хезмәткәрләрнең һөнәри яктан оста, югары белемле элитасы ПОЗИСта эшли, инженерларның яңа формациясе үсеп җитеп, менә дигән нәтиҗә бирә. Бу – таң калырлык социаль программаларны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе. «Казан Гипронииавиапром» АҖ проектлау һәм инжиниринг тармагының иң алдынгы рәтләрендә эшләү мөмкинлеге бирә торган предприятиегез белән хезмәттәшлекне бик югары бәяли. Киләчәктә дә үзара нәтиҗәле хезмәттәшлеккә өметләнәбез.

«ПОЗИС» акционерлык җәмгыятенә уңышлар, яңа проектлар һәм яңа казанышлар телибез! Завод ветераннарына һәм барлык хезмәткәрләрегезгә тынычлык һәм муллык насыйп булсын, аларның балалары сәламәт һәм бәхетле булып үссен, предприятиегезнең яшь көчләре һәрвакыт тулып торсын.

Фото «Казан Гипронииавиапром» АҖ, «Казан Гипронииавиапром» Инжиниринг компаниясе» ЖЧҖ ширкәтләреннән алынды.

Реклама

Дөньякүләм дәрәҗәдәге мәсьәләләрне чишкәндә...

Николай Семикопенко,
«Авиация редукторлары һәм трансмиссияләре – Пермь моторлары» АҖ («Редуктор-ПМ» АҖ) идарәче директоры

Фото «Авиация редукторлары һәм трансмиссияләре – Пермь моторлары» акционерлык җәмгыятеннән («Редуктор-ПМ» АҖ) алынды.

– Хөрмәтле Радик Шәүкәтович, «Редуктор-ПМ» АҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» федераль дәүләт унитар предприятиесенең барлык хезмәткәрләрен котларга рөхсәт итегез. ПОЗИС 120 еллык тарихында артиллерия гильзаларыннан алып суыткыч җиһазлары җитештерүгә кадәр күп өлкәләрдә үзен лаеклы күрсәтте. ПОЗИС бүген дә Россиянең оборона тармагында әйдәп баручы заводларның берсе һәм Татарстанда суыткыч техникасы җитештерә торган бердәнбер предприятие булып кала. Ул Татарстан һәм Россиянең сәнәгать потенциалына әүвәлгечә зур өлеш кертә.

Компания тарафыннан эшләнгән һәм гамәлгә ашырылган үсеш стратегиясе фән тармагы белән тыгыз бәйләнгән югары технологияле продукция җитештерүгә юнәлгән. ПОЗИС бренды яңа модельләр эшләгәндә һәм камилләштергәндә генә түгел, ә менеджмент һәм маркетинг системасында инновацияләрне гамәлгә кертү, кулланучыга йөз тоту нәтиҗәсендә дә ышаныч уята.

Бу өлкә белән таныш даирәдә ширкәтнең инженерлар командасы да яхшы билгеле. Вертолет редукторлары һәм трансмиссияләр җитештерү буенча Россиянең иң эре предприятиесе булган «Редуктор-ПМ» АҖ вертолет редукторлары өчен сынау стендын төзү проекты кысаларында ПОЗИС белән хезмәттәшлек итә башлады. Бу дөньякүләм дәрәҗәдәге мәсьәлә иде. Һәм аны чишкәндә, ПОЗИС белгечләре ярдәм итте. Безнең белән көчле һәм уңышлы җитәкчеләр командасы кул астындагы тирән белемле конструкторлар һәм технологик персоналның эшләве хезмәттәшлекнең беренче көннәреннән үк билгеле булды.

Сынау стендларының беренче проектын уңышлы тәмамлап, ПОЗИС осталары командасы стандарт булмаган махсус җиһазларны әзерләү һәм эшләп чыгаруда, шулай ук «Редуктор-ПМ» АҖ тарафыннан проектлана торган яңа сынау стендларының аерым детальләрен һәм төеннәрен әзерләүдә ышанычлы партнерыбыз булып калды.

ПОЗИС коллективына ниятләгән барлык планнарын сыйфатлы тормышка ашыруларын, тотрыклылык, оптимизм, иминлек телибез! Без үзара хезмәттәшлегебезне югары бәялибез һәм аның киләчәктә дә дәвам итүенә өметләнәбез! Ныклы сәламәтлек, һөнәри уңышлар һәм алдынгы идеяләр сезгә!

Шамил Агиев, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе, гыйнварда үзенең 70 еллыгын билгеләп үтә.

Шамил Рәхим улының бөтен хезмәт юлы Татарстан Республикасы белән бәйле. Ул ВЛКСМнең Казан шәһәр комитетында беренче секретарь булып эшли, аннары биш ел ВЛКСМның Татарстан өлкә комитетын җитәкли. Соңрак – КАМАЗда икътисад буенча директор урынбасары. 1984 елдан 1993 елга кадәр «Электроприбор» заводында шундый ук вазыйфа башкара.

Икътисад фәннәре докторы Шамил Агиев инде 25 ел Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасын җитәкли. Төп эшчәнлектән тыш, җәмәгать проектлары белән дә шөгыльләнә, Халыкара эшкуарлык һәм һөнәр академиясе әгъзасы, РФ Сәүдә-сәнәгать палатасы Президиумы әгъзасы, «Зур Идел» Сәүдә-сәнәгать палаталары ассоциациясе рәисе, шулай ук Татарстанның Академик ишүү федерациясе президенты булып тора. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, Татарстан Республикасы Президентының Мактау грамотасы, Дуслык ордены, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале белән бүләкләнгән.

Үзара ышанычка нигезләнгән хезмәт

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

Хөрмәтле Шамил Рәхимович! Юбилей көнендә шәхсән үзем һәм «Татэнерго» АҖ коллективы исеменнән ихлас котлауларыбызны һәм изге теләкләребезне кабул итегез.

Без инде берничә дистә ел буе таныш, һәм миңа Сезнең лидерлык сыйфатларыгыз, югары һөнәри осталыгыгыз, республика өчен мөһим бурычларны хәл итүдәге максатчанлыгыгыз яхшы билгеле. Сез җитәкчеләр арасында – зирәк остаз, чын аксакал. Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасы идарәсе рәисе вазыйфасында чирек гасырдан артык вакыт эчендә республиканың чәчәк атуы, анда яшәүчеләрнең иминлеге өчен бик күп эш башкардыгыз. Бу тирән ихтирамга һәм ихлас рәхмәткә лаек хезмәт. Сез югары дәүләт бүләкләрен лаеклы рәвештә алдыгыз.

Республиканың эшлекле җәмәгатьчелегенә чиксез бирелгән булуыгызны яхшы беләбез, үзара ышаныч һәм хөрмәткә нигезләнгән уртак эшебезне бик югары бәялибез. Безне сезнең белән киләчәктә дә нәтиҗәле эш еллары көтә, дип ышанабыз. Сезгә ныклы сәламәтлек, бәхет һәм уңышлар телибез! Тормышыгызның һәр елы бетмәс-төкәнмәс энергия, йортыгыз җылылык, иминлек белән тулы булсын, туганнарыгыз һәм якыннарыгызның мәхәббәтен тоеп яшәгез!

Фото «Татэнерго» АҖнән алынды.

Республиканың бизнес-җәмәгатьчелеген үстереп...

Талия Миңнуллина,
Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе

– Хөрмәтле Шамил Рәхимович! Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котларга рөхсәт итегез!

Без Сезне абруйлы остаз һәм җитәкче буларак беләбез. Холкыгызга кешелеклелек, тормышны ярату һәм үз эшегезгә тугрылык кебек иң матур сыйфатлар хас. Сез иң катлаулы эшләргә дә ачык йөз һәм чиксез җаваплылык белән, уңышсызлыкка очрау мөмкинлеге бер дә калмаслык итеп алынасыз. Без Сездән үрнәк алырга тырышабыз, әмма көчле акылыгыз һәм бигрәк тә гаҗәеп тормыш тәҗрибәгез белән көндәшлек итү мөмкин түгеллеген дә таныйбыз.

Республикабыз икътисадына инвестицияләр җәлеп итү буенча уртак хезмәттәшлек элемтәләрен күздә тотып, үз эшенең чын остасы – Сездә булган хәзинә – бары тик тәҗрибәдән генә алынган белемнәр, җитештерү процессларын төптән аңлау һәм барлык идарә структуралары белән дөрес хезмәттәшлек итү турында әйтмичә кала алмыйм. Болар барысы бергә яраткан Татарстаныбызның потенциалын тотрыклы үстерү мөмкинлеген бирә.

Сезнең лидерлык һәм кешелеклелек сыйфатларыгыз бәрабәренә Татарстан бүген бөтен дөнья буйлап бик күп эшлекле партнерлар белән элемтә тота. Үзегез белән аралашучыларга биргән фундаменталь белемнәрегез, төпле киңәшләрегез – башка беркайда да табып булмый торган кыйммәтле мәгълүмат ул. Без сезнең үгет-киңәшләрегездән илһам алабыз, аларны идеяләребезгә кушып, заманны узып китәр сәләткә ия колачлы проектларны тормышка ашырабыз.

Татарстан Сәүдә-сәнәгать палатасының алыштыргысыз рәисе сыйфатында Сез республиканың бизнес-җәмәгатьчелеге үсешенә бәяләп бетергесез өлеш керттегез. Бүген Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы Идел буе төбәгендә иң эреләрдән санала. Сезнең ярдәм белән ул эшкуарларның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен нәтиҗәле яклый, хакимият белән ике арада элемтәләр кора һәм республиканың тышкы икътисадый багланышларын үстерүгә булыша.

Сезгә һәм якыннарыгызга сәламәтлек, бәхет һәм иминлек телибез. Эшләрегез алга таба да чәчәк атсын, шатлыклы вакыйгалар һәм онытылмаслык тәэсирләр күбрәк булсын!

Фото Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгыннан алынды.

«ӘКИЯТ»НЕҢ ТӨП КАҺАРМАНЫ

Бу соклангыч сарай Татарстан турындагы бер генә роликта да күренмичә калмый. Купшылыгына һәм матурлыгына килгән туристлар шаккката. Һәм бигрәк тә – аның министрлык-фәлән, йә булмаса сәүдә комплексы түгел, ә... балалар өчен Курчак театры икәнлеген белгәч. Казанда һәм Татарстанда шушындый гүзәл архитектура үрнәгенең булуы өчен без аны чирек гасыр дәвамында җитәкләгән директорга чын күңелдән рәхмәтле булырга тиешбез. Әйе, Роза Яппарованы бизи торган иң асыл сыйфатлар – әлеге театрга, һәм гомумән театрга булган күп елларга сузылган мәхәббәт белән тәвәккәллек. Гыйнвар аенда ул 70 яшьлек юбилеен бәйрәм итә.

ТӘВӘККӘЛ АДЫМ

2008 елда була бу хәл. Дәүләт Советының бюджет буенча утырышларының берсендә мәдәният өлкәсендә хезмәт куючылар утырган рәттән бер ханым сүз сорап ала. Зал инде җитәрлек дәрәҗәдә алҗыган була, шуңа аның бу гамәлен уфылдап кына каршылыйлар. Әмма берничә минуттан мөнбәргә күтәрелгән ханым залның игътибарын тулаем үзенә җәлеп итә.

– Без бер ел эчендә 79 мең тамашачыга 520 спектакль күрсәтәбез. Без аяк басмаган авыл юктыр. Үз эшебезне 100%ка җиткереп башкарабыз, әмма безгә – балалар театрына – республикада мөнәсәбәт нинди? Миңа кадәр яңа гына Алевтина Николаевна* чыгыш ясады, театрлардагы эш хаклары турындагы соравыма «бездә андый мәгълүмат юк» дип җавап кайтарды. Ә менә миндә бар! – дип кызып сөйләвен дәвам итә ханым. – Мин уйлыйм, уйлыйм да, янә бер кат уйлыйм: кичәге студент, ә бүген республика театрының яшь актеры ничек итеп 3 меңгә бер ай буена яшәргә тиеш?! Алар бездә алтау! Ничек шул тиен-миенгә киенсеннәр дә алар, транспортта да йөрсеннәр, фатир хакын да түләсеннәр?! Ә бит кайберләренең инде гаиләсе үк бар! Әгәр алга таба да балалар театрына мөнәсәбәтегез мондый булса, сәхнәдә аю да күрмәссез! Тагын бер мәсьәләне ничек йомшаграк итеп күтәрергә икәнен дә белмим хәтта... Бу – безнең бина мәсьәләсе. Өч ел элек Минтимер Шәрипович анык белдерде: яңа курчак театры төзергә керешәбез, диде. Мин, әлбәттә, барыбызга да яхшы таныш булган мәкальне сезнең кебек үк хәтерлим, әмма бит өч ел узды, ә эшнең әле башланганы да юк... Балаларга хезмәт итә торган театрга мондый мөнәсәбәт күрсәтергә ярамый!

Әлеге кайнар чыгышның азагында мөнбәргә күтәрелгән ханымның күзләрендә яшь була. Гарьләнүдән – театр өчен дә, үзе өчен дә... Утырышта катнашучыларның янына килеп, хуплау сүзләре белдерүен күргәч, аптырап кала ул. Аны тынычландыралар: яңа бина, һичшиксез, булачак, диләр. Чынлап та, икенче көнне Минтимер Шәймиев планерка җыя һәм курчак театры бинасын проектлау буенча күрсәтмә бирә.

Бу хәлләрдән соң өч елдан артыграк вакыт узгач, Казанда курчак театры гына түгел, ә чын мәгънәсендә әкияти сарай калкып чыга. «Әкият» театрының ачылыш спектакленә Минтимер Шәймиев та, Рөстәм Миңнеханов та килә.

МӘҢГЕЛЕК ХӘТЕР

«Аһ, кызым, әниең исән булса, бу кадәр туры итеп кистереп сальрга ярамаганлыгын искәртер иде...» – дия торган була кечкенә Розага туганы. Әнисе 32 яшендә инфарктан вафат була, Роза аңардан 7 яшендә кала.

Розаның әнисе авыл мәктәбендә һәм Баулы районында рус теле белән рус әдәбияты укыткан. Өйләрендә аның каллиграфик почерк белән язып тутырган дәфтәрләре бик күп була. Ә ул дәфтәрләрдә – бөек шәхесләрнең цитаталары... һәм әнисенең үзе язган шигырьләре дә. Үлеменнән соң, аның халат кесәсеннән тулы бер поэма табып алалар. Ул аны кызына, иренә һәм әнисенә багышлаган була...

Роза гөле иң матур гөл бит ул,
Кемнәр генә аны яратмый.
Башка гөлләр тәмле хуш исләрен
Аның кебек читкә таратмый.
Шул гөл кебек матур булып,
Тормышыбыз алга китсен, дип,
Үзем куштым, кызым, сиңа ул исемне,
Үскәч, безне хөрмәт итсен, дип.

Бу талантларыннан тыш, Роза ханымның әнисе халык театрында да уйный торган була тагын. Озын кара чәчле искиткеч бер гүзәл булып сакланып калган ул Розасының хәтерендә. Бөтен баш рольләр аның әнисенеке була. Шулай итеп, кечкенә тамашачы рәвешендә, әнисенең барлык спектакльләрен карап үскән Розаның йөрәгенә дә театр мәңгегә кереп урнаша.

КАЙТЫР ӨЧЕН КИТҮ

Кеше үз язмышын үзе яза, әмма барыбер дә иң мөһим борылышларны аның көченнән генә килми торган очрак хәл итә, дип исәпли Роза Яппарова. Бөгелмәдә мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетының татар мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыту бүлегенә (РТО) укырга керә. «Социалистик Татарстан» газетасында эшли торган була инде үзе. Газетаның ул чактагы баш мөхәррире Шәмси Хамматов: «Безгә рус һәм татар телләрен бертигез дәрәҗәдә белә торган белгечләр кирәк. Без сезне 3 елга Мәскәүгә укырга җибәрергә телибез», – дип канатландыра. Һәм болай дип тә өсти: «Кияүгә генә чыга күрмәгез берүк, Роза, артыгыздан бер егет йөри, дип ишеттерделәр...» Ул бу сүзләрне әйткәндә, яшьләрнең язылышу датасына нибары бер атна гына калган була инде. Роза, киңәш сорап, апасына бара һәм мондый җавап ишетә: «Хатын-кыз, теләсә, әллә ниләргә ирешә ала, әмма гаилә – беренче урында». Роза кияүгә чыга, гаиләләре белән Бөгелмәгә күченәләр. Игезәк кызлары туа, фатир алалар. Вакыйгалар гөрләп торган Казан белән аралар өзелде, дип уйлаган чаклары да була. Әмма җиде елдан соң бәхетле бер очрак Яппаровлар

Фото «Әкият» Курчак театрыннан алынды.

0+

*Алевтина Кудрявцева *(Ред.иск.)* – ул чакта Татарстан икътисад министрының беренче урынбасары.

Роза Яппарова,
«Әкият» Татар дәүләт курчак театры директоры, гыйнварда 70 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

гаиләсен Татарстанның башкаласына кире алып килә. КПССның Татарстан өлкә комитетында газета-журналлар, радио һәм телевидение секторы мөдире Илгиз Кәлимулла улы Хәйруллин Роза ханымнан сорый: «Кайсы редакцияне сайлыйсың?» Ә ул арада Роза Яппарова инде мәктәптә балалар укытырга да, Бөгелмә район газетасы «Ленин байрагы»нда дубляж буенча баш мөхәррир урынбасары булып эшләргә дә өлгергән була. «Юк, редакциягә бармыйм, театрга барам!» – дип кистереп сала безнең кыю каһарманыбыз. Казанның «Әкият» курчак театрында педагог-оештыручы урыны бушаган була. Эш хакы тиен-миен генә булса да, Розаны бу туктатып калмый. Ул бит хыялында йөрткән урынга – театрга урнаша!

РЕКОРД КУЙГАН «ЧЫРШЫ»ЛАР

«Әкият» курчак театрында барысы да – балалар өчен. Яңа ел бәйрәмнәре вакытындагы тамашалар саны «рекорд»лы: көнгә 8 әр Чыршы бәйрәме. «Курчак театры – педагогика белән сәнгатьне берләштерүче ул», – бу сүзләрне Ленинград шәһәренең Яшь тамашачылар театрына нигез салучы Александр Брянцев әйткән.

– Репертуарны формалаштырганда, һичшиксез, балалар фикеренә таянабыз. Югары дәрәҗәдәге спектакльләр чыгарырга омтылабыз, – ди Роза Сәетнуровна. – Хәлдән тайганчы эшлибез. Планны арттырып. Миңа бит, җитәкче буларак, театрны финанслау турында да кайгыртырга кирәк. Башка шәһәрләрдән заманча эшли торган режиссерларны чакыру, фестивальләргә, гастрольләргә чыгу өчен... Яшь талантлы актерларны, ут куючыларны, тавыш операторларын, рәссам-бутафорларны яхшы хак түләп чакырмасаң, булмый. Актер репертуарда ныклап җәлеп ителгән икән, 150% өстәп түлибез. Шуны да истә тотарга кирәк: эшләп алган акчаның нибары 50%ын гына әнә шул өстәмә түләүләр өчен файдаланырга мөмкин. Минем, җитәкче буларак, төп бурычым: театр хезмәткәрләрен яхшы эш хакы белән тәэмин итү. Аларның күбесе ипотека түли.

КУРЧАКЛАР НӘКЪ КЕШЕ КЕБЕК!

Роза Сәетнуровна кабинетында Шамахан патшабикәсе яши. Әлбәттә, чын патшабикә түгел, ә курчак. Аны язмабыз каһарманына, юбилее белән котлап, РФнең атказанган рәссамы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Валентина Губская бүләк итә. Валентина Губская әлеге театрда 30 елдан артык баш рәссам булып эшли. Хәзер ул – лаеклы ялда. Роза Яппарова әйтүенчә, Курчак театрын еш кына бәяләп җиткермиләр. Имеш, курчаклар – нәрсә инде ул, аларның чынбарлыкка нинди катнашы бар? Әмма чын курчак һәм аның белән идарә итүче чын актер тамашачыны шулай ук елата да, көлдерә дә ала. Куркуга төшерә дә.

90 нчы еллар азагында, Казанга, элеккеге курчак театры сәхнәсенә гастрольгә Чиләбе труппасы килеп төшә. Ул чакта аны атаклы режиссер, Россиянең халык артисты, К.С. Станиславский исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Валерий Вольховский җитәкли. Чиләбе артистлары Бертольд Брехт пьесасы буенча «Карьера Артуро Уи» дигән легендар спектакль күрсәтәләр. Вак карак Артуроның җинаятьчел банда башлыгына әверелү тарихы чын осталарча эшләнгән була. Персонаж Гитлердан күчереп алынгандай кабул ителә – залда чиркану, курку тойгысы уята. Спектакль турында әллә каян гына Казандагы панклар төркеме белеп ала. Агрессив яшьләр, театрга килеп, пикет оештыра, спектакльне куймауларын таләп итә. ФСБ хезмәткәрләрен чакырырга мәҗбүр булалар.

ХАКЫЙКАТЬ – ШИГЫРЬЛӘРДӘ

«Әкият»тә пьеса сайлауга җитди якын киләләр. Мәсәлән, Чыңгыз Айтматов әсәре буенча «Бер көн – бер гомер» әсәрен сәхнәләштергәндә, спектакльгә шигырьләрне Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты шагыйрь Зөлфәт иҗат итә. Алар шулкадәр күрәзәи эчтәлеккә ия булалар ки, хәзер дә кисәтү шикелле яңгырыйлар:

Иртәгәсе көнне кемнәр атлап узар
Без дөньяны атлап узган юлдан?
Ком басмасмы безнең сукмакларны,
Уйлан, кеше, уйлан, уйлан, уйлан!

Бер ай элек «Әкият» театрының труппасы гастрольләр белән Барнаул шәһәренә бара (Алтай төбәге). Театр коллективын җирле татар җәмәгатьчелеге белән очрашуга чакыралар. Роза Сәетнуровна аларга бер сәгатьтән артык Казан, Татарстандагы театрлар турында сөйли. Театр коллективы гастрольләр белән фестивальләр кысаларында татар диаспорасы вәкилләре белән очрашуларны актив оештыра. Мондый очрашулар Улан-Удэ (Бурятия), Көньяк Сахалин, Омск, Магнитогорск һ.б. татарлар яши торган шәһәрләрдә дә узды. Һәрберсендә татар диаспорасы вәкилләре Казаннан килгән Курчак театрының спектакльләрен карады, актерларны чәчәкләргә һәм алкышларга күмде.

– Без, театр вәкилләре, үзебезгә йөкләнгән тәрбия бирү бурычын да, белем бирү бурычын да вөҗданыбыз кушканча башкарабыз. Безнең репертуарда Татарстан әдипләре иҗат иткән бик күп кызыклы, гыйбрәтле, тәрбияви эчтәлекле әкиятләр бар. Спектакльләр балаларга аңлашылсын, тәэсир итсен, дип тырышабыз. Нәкъ менә курчаклар аша яхшыны – яманнан, акны карадан аерырга өйрәтәбез нәниләргә. Тамаша барышында алар Убырлы карчык кылган явызлыкны да күрә, Батырның гаделлеген, тырышлыгын да...

Әмма ничек кенә теләсәк тә, театрның гаилә белән мәктәп бирә торган тәрбияне алыштырыр көче юк. Безнең спектакльләр татар телендә бара – синхрон тәрҗемә юк. Шуңа карамастан, алар үз тамашачысын таба. Әмма шуны да әйтәсем килә: әгәр Яңа ел тамашаларына билетларны рус мәктәпләре әле сентябрь аенда ук сатып алып бетерсә, татарча тамашага билетлар декабрь азагына кадәр сатыла...

ӨЛКӘННӘР – БАРЫБЕР ШУЛ БАЛА

Роза Яппарованың хыялы бар – татар фольклорының атаклы каһарманы Шомбай катнашында спектакль чыгару. Әмма олы Шомбайны түгел, кечкенә һәм мут, кыю, ут малай Шомбайны күздә тота ул. Аның аша өлкәннәрнең дә балачактан булуларын тагын бер мәртәбә исләренә төшерергә иде, ди. «Шомбай»ны татар һәм рус телләрендә куяр өчен илебезнең затлы театраль премиясе – «Алтын битлек» не алган режиссер Светлана Дорожко чакырылган. Режиссер спектакльне үзенең төркеме белән әзерли икән: куючы рәссам – Александр Алексеев (Санкт-Петербург), композитор – Татьяна Алешина (Санкт-Петербург). 2019 елның февралендә режиссерның һәм аның командасының куелышы буенча карар кабул итәргә худсовет җыелачак. Ә премьера үзе июньгә планлаштырылган.

Әйтергә кирәк, Светлана Дорожко спектакльләре театраль фестивальләрдә беренче тапкыр гына җиңү яуламый инде. 2017 елда Светлана Дорожко Казанга Людмила Савчук пьесасы буенча «Хаврошечка» спектаклен куярга килгән иде. Әлеге тамашаны Курчак театры тамашачысы бүген дә яратып карый.



ШӘҺӘРДӘН РӘХӘТРӘК ЯШӘҮ

Балтач районының Бөрбаш авылына баргач, күңелне мең төрле халәт биләп алды: гаҗәпләнү, соклану, хәтта үпкә. Кемгә, ни өчен – боларын язманы укыганнан соң белерсез...

Автор:
Руфия Фазылова

АКСАКАЛЛАР АВЫЛЫ

Бөрбашны авыл да димәссең, ул шәһәр янындагы бер бистәне хәтерләтә. Яңа салынган төзек йортлар (араларында ике катлылары да шактый), кибетләр, һәртөрле социаль объектлар... Чагыштырмача зур да: бирелдә 860 кеше яши, 260 хуҗалык бар.

Салаларга баргач, иң беренче эш итеп балалар бакчасы, мәктәп белән кызыксынам: ничә бала йөри, укый? Нәкъ менә шушы саннар ярдәмендә авылга гомуми нәтиҗә дә ясап була. Бөрбаш балалар бакчасына бүген 40 сабый йөри икән. Урта мәктәптә 138 укучы белем ала, шуларның 80е –Бөрбаш авылыннан. (Белем бирү йортына тагын ике авылдан йөреп укыйлар). Шәхси эшмәкәр булып теркәлеп эшләүче уннан артык хуҗалык бар. Кайсы казылык ясый, кайсы теплица тота, кайсы агач яру эше һ.б. белән шөгыльләнә. Ә иң гаҗәбе: һәр өч йортның берсендә яшь гаилә яши.

Бөрбашның үз аксакалы бар: бөтен республикага билгеле шәхес – Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев.

Урам тулы бала-чага. Кичләрен, шәһәр урамындагы кебек, халык гөрләп тора икән: чана, чаңгы шуалар, чаңгы таякларына таянып, Скандинавия йөреше белән шөгыльләнүчеләр дә бар.

Бөрбаш Чувашиянең Урмай, Шыгырдан авылларын да хәтерләтте күпмедер дәрәҗәдә.Ул якларда авыл белән элеккеге заманнардагыча аксакаллар «идарә итә» бүген дә. Юк, рәсми рәвештә кәгазьләрдә күренми, чагылмый ул, ә халык белән эшләгәндә сизелә. «Фәлән абзый белән килешеп эшләнде», – дип сөйлиләр авылныкылар. Бөрбашның да үз аксакалы бар: бөтен республикага билгеле шәхес – Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтының икътисад факультетын тәмамлап кайткач, гомер буе туган районына, авылына хезмәт иткән патриот ул. Монда кем белән сөйләшсәң дә: «Безнең Җәлил хәзрәт», – диләр.

Татарстанның баш казые туган авылы мәчетендә имам булып тора. Хәзрәт белән Бөрбаш мәчетендә очраштык:

– Җәлил хәзрәт, авылда яшьләр күпләп калуда сезнең өлешегез зур, диделәр. Моның сере белән уртаклашсагыз иде. Сез аларны ничек үгетлисез?

– Берәүне дә көчләп авылда калдырмыйм, – диде хәзрәт. – Фәкать аңлату эшләре генә алып барам. Сезгә дә бер мисал китерим әле. Бөрбаш мәктәбен без 65 укучы тәмамладык. Шулардан алты егет авылда калды. Бүген тормышлары «ялт» иткән. Болын кадәр йортта яшиләр, хуҗалыклары нык. Рәхәтләнеп туган як һавасын су-

Фото: Александр Ефремов

лап, кендек каны тамган туфракка басып йөриләр. Ә читкә киткән яшьтәшләребез нәрсә? Шул кысан бер-ике бүлмәле фатирларында гомер иттеләр. Шәһәр – шәһәр инде ул: урам тулы чит кеше, анда егылып ятсаң да, яныңнан битараф кына узып китәргә мөмкиннәр. Ә авылда, бәла-каза килсә, секунды белән йөгереп киләләр. Менә хәзер нәтиҗә ясап карагыз инде: авылда яшәү отышлымы, шәһәрдәме? Авылда начар яшиләр дигән сүз чып-чын ялган! Әнә, карагыз: йорт саен – ничә машина, көнкүрешләре – менә дигән. Әйе, элек авылларда тормыш итү авыр иде. Хәзер мичкә ягасы, су ташыйсы да юк хәтта.

– Авылда эш юк, дип зарлана бит халык, – дим.

– Аны сез, журналистлар, шулай дип язасыз. Ә чынлыкта теләге булган кешегә эш бар. Шәһәрдән аермалы буларак, авылда селкенеп йөргән өчен генә акча түләмиләр. Монда чынлап торып эшләргә кирәк...

Менә шундыйрак сөйләшү булды. Дөресен генә әйткәндә, хәзрәтнең бу сүзләренә үпкәләп тә куйдым. Журналистлар уйлап чыгарып язмый: бик күп авыллар эшсезлек аркасында бетеп бара. Тик Бөрбашта – икенче ситуация. Беренчедән, авылда колхоз системасы сакланып калган. Фермалар, трактор парклары – барысы да гөрләп эшләп тора. Урта мәктәп, зур балалар бакчасы (анда ике төркем эшли), өч кибет – барысы да авыл кешесенә эш урыннары дигән сүз дә. Һәм, әйткәнемчә, эшмәкәрләр дә халыкны эшле иткән. Хәер, бу хакта соңрак...

«РЕСПУБЛИКАДА МОНДЫЙ ҮЗӘКЛӘР ЮК»

Эш урыннарын санауны дәвам итсәк, Бөрбаш балалар пансионатын да исәпкә алырга кирәк. Унлап бөрбашлы хезмәт куя анда. Пансионат 2018 елның сентябрендә генә ачылган. Бүген биредә 13 үсмер малай яши. Әлеге учреждениенең максаты – дини юнәлештә тәрбия бирү. Әле уку-укыту планы да расланмаган, шунлыктан чынлап торып дин гыйлеме бирә алмыйлар. Шуңа да бүген ул күбрәк – яшәү урыны.

– Безнең максат – татар телен камил белгән шәкертләр, ә киләчәктә дин әһелләрен тәрбияләү, – диде пансионатның директоры Альберт Базагутдинов. – Үзегез аңлыйсыз: һәр эшне башлаганда аерым кыенлыклар белән очрашасың. Әлегә балаларны укытырга лицензиябез, башка документларыбыз да юк. Ләкин тиздән барысы да хәл ителер дип уйлыйм. Шул юнәлештә эшлибез.

Бөрбаш пансионатына малайлар Казан, Түбән Кама шәһәрләре, Кукмара, Яшел Үзән, Буа районнарыннан килгән. Алар иртән Бөрбаш урта мәктәбенә китә. Көндезге өчләрдә кайтып, тамак ялгап алып, азрак ял иткәч, күршедәге мәчеткә дин сабаклары укырга керәләр.

– Бу элек мәктәп бинасы иде, – дип таныштырып йөрде пансионатның укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Динә Базагутдинова. – 2015 елда «Ярдәм» Милли ислам хәйрия фонды бинаны рәсмиләштереп, үз өстенә алды. Һәм ремонт эшләре башлап җибәрде. Агымдагы җәйдә бөтен эшләр дә тәмамланып, яшүсмер малайларны кабул иттек.

Бөрбаш пансионаты 40 урынга исәпләнгән. Тик әлегә аның кадәр бала җыймаганнар. Ни өчен дигәндә, тәҗрибә булмау сәбәпле, эшне аздан башлаганнар. Киләсе елга тагын унлап үсмерне алырга ниятлиләр.

– Дөресен генә әйткәндә, күңелдә шик тә бар иде: төрле районнардан килгән балалар бер гаилә булып яши алырлармы? Безгә 5–8 нче сыйныф укучылары килде. Аларның берсе дә гаиләсеннән аерылып яшәгән малайлар түгел. Аерылуны авыр кабул итмәсләрме? Бөрбаш урта мәктәбенә ияләнерләрме? Бер-берсе белән уртак тел табарлармы? Кыскасы, сораулар бик күп иде. Менә инде дүрт ай вакыт узып бара, Аллага шөкер, бер конфликт та чыкканы юк. Авыл балалары белән дә уртак телне тиз таптылар.

– Шәһәр балаларына Бөрбаш мәктәбенә ияләнү авыр булмадымы? Сездә бит уку татар телендә, ә шәһәрдә русча укыйлар, – дим.

– Үзебез дә шуңа борчылган идек, бактың исә, тел проблемасы үсмерләр өчен әллә ни катлаулы түгел икән. Әлбәттә, алгебра, химия кебек фәннәр башта авыррак бирелде, әмма тиз өйрәнделәр. Бөрбаш мәктәбендә укытучылар да көчле, аларның өлеше зур булды.

Пансионатта ашау, яшәү бушка. Моның барысын да «Ярдәм» Милли ислам хәйрия фонды күтәрә. Авылга «Ярдәм» мәчетеннән махсус укытучы – Солтан хәзрәт Сөләйманов кайткан. Ул Бөрбашта гаиләсе – хатыны, өч кечкенә кызы белән яши. (Хәзрәт белән күрешеп булмады, авылда түгел иде).

– Безнең максат – татар телен камил белгән шәкертләр, ә киләчәктә дин әһелләрен тәрбияләү, – ди Альберт һәм Динә Базагутдиновлар.

...Пансионат турында язуны тәгәлләдем дә, тагын бер кызыклы хәл искә төште. Шәһәр балалары Бөрбашны аеруча яраткан. Урамдагы сыер-сарыкларга, тавык-чебешләргә мөкиббән киткәннәр. Ә Түбән Камадан килгән үсмер очрагы тагын да кызыклырак.

– Пансионатка Түбән Кама малае бер кочак дару белән килде, көчле аллергия иде аның, – дип сөйләде Альберт Базагутдинов. – Әти-әнисе бу чир белән ничек монда яшәр дип борчылды. Өч ай дигәндә, ышанасызмы-юкмы, малай бер дарусыз яши башлады. Һава килештеме, сумы, әйтә алмыйм. Элек кишер, чөгендер ише төсле яшелчәләрне авызына да капмый иде, хәзер яшьтәшләре белән бөтен нәрсәне ашый. Малай күптән түгел әти-әнисе янына Түбән Камага кайтып килде. Шәһәрдә яңадан аллергиясе башланган. «Бөрбашка гына күченеп кайтырбыз, ахры», – дип әйтә әнисе, уены-чынын бергә кушып.

«ИТ КОРОЛЕ»

Бөрбашның эшкуарлары турында югарыда әйтеп узган идем. Шуларның иң эресе, районга гына түгел, республикага билгелесе – Илшат Гыйльмуллин. Рәсми рәвештә КФХ «Гыйльмуллин» дип атала. Документ нигезендә 2015 елда эшли башлаганнар. Ә бу өлкәдә эш тәҗрибәләре 8 еллап инде.

Бөрбашта күпләр казылык ясый белә булып чыкты. Берничә ел элек ул модага кереп киткән булган. Бүген дә кайберәүләр үзләре өчен казылык ясый. Гыйльмуллиннар шулай зурлап колбаса ясый торган цех ачарбыз дип планлаштыру түгел, уйлап та карамаган. Хуҗалар әйтүенчә, барысы да үзеннән үзе килеп чыккан.

– Илшат, син казылыкны әйбәт ясыйсың, безгә дә эшлә әле, дип, танышлар ит китерә башлады, – дип сөйләде фермер. – Эш өчен акча да бирделәр. Шулвакыт көнделән генә, кара, казылык ясауга сорау зур икән, ныклап шөгыльләнсәк, дип уйлап куйдым. Хатыным Рамилә дә минем фикерне куәтләде. Менә шулай итеп казылык, колбаса ясый башладык. Аннан өйдә җәелеп ятканчы, дип, ишек алдындагы бер корылмага күчендек. Санитар таләпләрне үтәп, җайлап кына эшләп куйдык. Сорау күп булу сәбәпле, ул урын да җитми башлады. Шуннан соң, тәвәккәлләп, менә хәзерге урында цех ясадым. Ит чыгартырга, колбаса ысларга кирәкле бөтен җиһазларны сатып алдым.

Бүген Гыйльмуллиннар цехында колбаса, казылык, ветчина, сосиска ясыйлар. Каз-үрдәк, сыер, сарык, ат кабыргасы ыслауга шулай ук сорау зур икән. Кышын эш бермә-бер арта, ди.

– Хатыным Рамилә дә минем фикерне куәтләде. Шулай итеп казылык, колбаса ясый башладык, – ди Илшат Гыйльмуллин.

– Даими рәвештә дүрт хатын-кыз эшли, – диде Илшат Гыйльмуллин. – Тагын ярдәмгә берничә кешене чакырабыз. Яңа суелган итне тиз арада эшкәртергә кирәк бит.

Өстебезгә халатлар киеп, цехка кереп, эш барышы белән танышып чыктык. Гаҗәп монда! Бер апа зур иттарткычтан ит чыгара, икенчесе кабыргаларны чистарта, өченчесе зур казанда кайный торган итне карый… Колбаса ясау процессы шундый икән. Илшат абый безгә суыткычны ачып күрсәтте. Дистәләгән зур савытларда яңа суелган ит тора. Хуҗалыклардан килгән ул. Һәр савытка кешенең исем-фамилиясе, телефоны язылган.

– Һәр кешегә үзе алып килгән иттән ясап бирәсезме әллә колбасаны? – дим.

– Әлбәттә! Хуҗалар үзләре шулай тели. Без исә, берәүне дә алдамыйча, нәкъ сез әйткәнчә эшлибез.

Колбасага бөтен ит тә бармый икән. Мисал өчен, 80 килограмм итнең яртысы гына эшкә китә, ди. Калганы – сөяге, сеңерле итләре – аерып алына. (Хатын-кызлар нигездә шуларны эшли.)

– Ышандырып әйтә алам, ризыкларны бер химиясез ясыйбыз, – диде Илшат Гыйльмуллин. – Сыйфатсыз эшләсәң, клиентларны югалтасың. Ә алар елдан-ел күбәя: Балтач кешеләре генә түгел, Киров өлкәсе, үзебезнең Арча, Балык Бистәсе, Лаеш якларыннан, ягъ-

Колбасага бөтен ит тә бармый икән. Мисал өчен, 80 килограмм итнең яртысы гына эшкә китә. Калганы – сөяге, сеңерле итләре – аерып алына. Хатын-кызлар нигездә шуларны эшли.

ни төрле районнардан ит алып килäләр.

Фермерның хыяллары зурдан – колбаса цехы белән янәшә ат фермасы төзеп ята ул. Үзе үстергән ат итеннән колбаса ясап сатасы килә. Ә бүген аның төп эше – әнә шулай кешегә хәләл ит ризыклары ясап бирү. Бөрбаш колбасалары шулай ук сатуга да китә. Атна саен Казанда узган ярминкәләргә киләләр икән. Татарстан белән генә чикләнмичә, Россиягә дә чыгасы килә аларның.

ӨЧ БУЫН – БЕРГӘ!

Бөрбашта киң таралган бер күренеш – ул өч буынның, ягъни дәү әти-дәү әни, әти-әни, балаларның бергә яшәве. Өч йортның берсе шулай көн итәдер, мөгаен. Бу да – Җәлил хәзрәтнең үгет-нәсихәте, аның шәхси үрнәге йогынтысында. Күпләр беләдер, баш казый кая гына барса да, берничә буын бергә яшәүне хуплап сөйли. Үзе дә дәү әти, дәү әни тәрбиясендә үскән, төпчек улы да әлеге традицияне дәвам иткән.

– Татарда гомер-гомергә төпчек ул төп нигездә калган, – дип сөйләде Җәлил хәзрәт безгә дә. – Кече улым шуны аңлап, белеп үсте. Өйләнгәч, безне ташлап чыгып китү уенда да булмады. Ә менә олы улыбыз район үзәгенә – Балтачка йорт салырга ниятләгән иде. «Бик саласың килсә, сал, тик бел: мин сиңа әнә күзе кадәр дә ярдәм итмәячәкмен. Туган авылыңа сыешмыйсыңмы?!» – дидем. Шуннан, син күр дә, мин күр: олы улыбыз Бөрбаштан йорт салырга урын эзләп йөри башлады. Күтәрергә без дә булыштык. Ул елны өч йөз банка гөмбә генә эшкәртеп саттым... (Җәлил хәзрәт атаклы гөмбәче, бакчачы. – Авт.)

Шулай итеп, Җәлил хәзрәтнең ике улы да туган авылында калган, өчәр балалары бар. Хәер, Бөрбашта өч бала – гадәти күренеш.

– Без дә әти-әни белән яшибез, – дип сөйләде Бөрбаш авыл җирлеге башлыгы Равил Галимуллин. – Бик рәхәт бит: хатыным белән көне буе эштә, балалар бакчасына дип ашыгасы түгел. Кайткан җиргә кайнар ризык әзер, балалар караулы.

Равил әле берничә ай элек кенә җирлек башлыгы булган. Аңа кадәр тормыш иптәше белән казылык ясап сату белән шөгыльләнгән, теплица тоткан. Хәзер бу эшләрен ташларга туры килгән.

– Авыл җирлеге башлыгы булырга тәкъдим иткәч, каршы килмәдем инде, – диде. – Бөтен кеше үз эше белән генә шөгыльләнсә, авыл өчен кем йөрер? Әле менә иганәче ярдәме белән мәчет манарасына яктылык уздырдык, караңгыда әллә кайдан балкып тора хәзер. Тагын багана башларына 295 мең сумлык яктырткычлар алып куйдык. Хәзер менә яңа эш артыннан йөрибез – авыл башына 1 чакрым 800 метрлы чаңгы юлы ясыйсы иде. Утлар белән яктыртыла торган булачак ул... Рәхмәт яусын, Бөрбаштан чыккан кешеләр дә авылны онытмый. Акчалата ярдәм итәләр. Бу юлы да аларга өметләнәбез.

Бөрбашка көндез барганлыктан, өч буын бергә яши торган гаиләләрдәге балалар белән күрешү насыйп булмады, ул-кызлар йә бакчада, йә мәктәптә иде. Шулай да, ике бәләкәчләре булган Миңнуллиннар белән танышып чыктык. Ир белән хатынга әле утыз да юк. Гаилә башлыгы Айгиз – Бөрбаш мәктәбендә директор урынбасары, Зөлфия балалар бакчасында тәрбияче булып эшли. Олы уллары Юныска 2 яшь тулган, кечесе Мусага алты ай гына. Миңнуллиннар яңа йорт җиткергән.

– Без яңа урамда яшибез, – дип каршы алды гаилә башлыгы. – Авыл зурая, Аллага шөкер. – Яшьләрнең күп булуы аеруча сөендерә. Бергә аралашасың, бәйрәмнәрдә җыелып утырасың. Балаларга да күңелле. Бик рәхәт яшибез.

...Кайбер авылларга баргач, туган төбәгеңне ташлап шәһәргә чыгып киткәнеңә үкенеп куясың. Салада да бер дигән итеп яшәп була! Балтач районының Бөрбаш авылыннан кайткач та күңелдә әнә шундыйрак уйлар бөтерелде.

– Яшьләрнең күп булуы аеруча сөендерә. Бергә аралашасың, бәйрәмнәрдә җыелып утырасың. Балаларга да күңелле. Бик рәхәт яшибез, – ди Зөлфия һәм Айгиз Миңнуллиннар.



Бөрбашны авыл да димәссең, ул шәһәр янындагы бер бистәне хәтерләтә. Яңа салынган йортлар (араларында ике катлылары да шактый) күзне иркәли.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

Җәлил хәзрәт Фазлыев:

– Бөрбаш тарихы белән күптәннән кызыксынам. Архивларда утырып, авылда яшәүче һәр гаиләнең нәсел шәҗәрәсен төзедем.

Авылыбыз XV гасыр урталарына карый. Балтач районының күпчелек авыллары Казан ханлыгы җимерелгәч оеша, ягъни халык бу якларга таба күченеп утыра.

Бөрбаш җирлегендә табылган беренче кабер ташы Туктаргалинеке. Ул 1675 елда күмелгән. Авылга нигез салучы Көчек атлы кешенең улы булырга тиеш, дип фаразлыйлар. Ул таш бүген дә зиратта тора: яңа мәрмәр таш хәстәрләп, рус хәрефләре белән дә язып куйдык. Киләчәк буыннарга тарих өлгесе булып калсын.

Исеменә килгәндә, Көчекнең уллары, оныклары бу җирлектә терлек утарлары тота. Бөр елгасында хайваннар су эчә. Шушы елгага нисбәтле, Бөрбаш исеме бирелгән дигән фикер яши».

Фотолар Элвин Грей архивыннан алынды

МИНЕМ ТЕЛЕМ – ТАБЫН ТЕЛЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ...

Безнең халыкка бүген милли каһарманнарның, әйдәманнарның кирәклеге – көн кебек ачык. Сәхнәдәге йолдызлар – һәрчак күз уңында, шуңа да без еш кына сусаган героебызны җырчылар, артистлар арасыннан эзлибез. Илһам Шакировлар, Фидан Гаффаровларга алмашка яңа буын вәкилләре килде. Үзләре белән яңа формат, яңа кыйммәтләр һәм хакыйкатьләр алып килде. Бу без көткән форматмы? Һәм без кабул итәргә әзер кыйммәтләр белән хакыйкатьләрме?

ФИЗИКА КАНУННАРЫ, ЯКИ РАД БЕЛӘН ГРЕЙНЫҢ РАДИАЦИЯ КӨЧЕ

– Элвин Грей феномены турында Элвин Грей нәрсә әйтә ала?

– Ә бернинди феномен да юк, асылда. Мәскәүдә 5 ел яшәгән арада милли эстраданы өйрәндек. Топ дәрәҗәсендә йөргән артистларның репертуары нәрсәсе белән хикмәтле икәнен. Графиклар төзедек, логистиканы ничек корасын уйладык. Бервакыт продюсерым мәктәптә синең физика белән эшләрең ничегрәк иде, дип кызыксынды. Мин, кызарып, әллә ни түгел, дип җавап кайтардым. Шуннан ул миңа дәреслекне ачтырды да «Радиациянең ионлашучы энергиясен үлчәү берәмлекләре» дигән бүлекне укырга кушты. Укыдым. Сүзне кая таба боруын барыбер аңламадым. «Мин аранжировщик, миңа бу энергия нәрсәгә», – дидем. Ә уң аңлатып күрсәтте: «Син – «РАД», бүгеннән синең никнеймың шундый. Хәзер инде – «Грей». Ә болар барысы да – радиациянең ионлашучы энергиясен үлчәү берәмлекләре. Син 5 ел буе авыл клублары буйлап йөргәнсең, 100 ләп кеше җыйгансың концертларыңа. Әмма шундый вакыт киләчәк: радиация энергиясе шикелле, йөз мәртәбә күбрәк кешене җәлеп итәчәксең. Ә бу инде 10 000 дигән сүз! Физика кануннары үзенекен эшли ул... Синә бары тик нәкъ менә шушының өчен яратылган булуыңа ышанырга гына кирәк. Бик нык ышанырга! Онытма: Фэн-шуй буенча бәхет китерә торган саның – 7, ә талисманың – чиксезлек билгесе...»

Бу 2011 ел иде. Мин китапны яңадан кулыма алдым да күз салдым. Тәннәрем чымырдап китте: 1 Грей = 100 РАД дигән формула ярылып ята иде анда. Әнә шуннан башланды да инде... Җиде ел узганнан соң, 2018 елда, без «Татнефть Арена»да, чынлап та, 10 000 кешене җыйдык, «Уфа Арена» да – 8 000 не. Әле бит символика бар – чиксезлек билгесе...

– Сез тамашачыга тәкъдим иткән продукт нәрсәсе белән уникаль?

– Бернинди уникальлек юк, без нибары тачкада барганда, дискотекада биегәндә, район мәдәният сарайларында күңел ачканда, концертларга килгәндә һәм безне тыңлаганда оят булмаслык продукт кына чыгарабыз. Саунд дәртләндерә, битлар кәефне тиешле дәрәҗәгә күтәрә. Безнең телләрдә бөтен дөнья җырлый башлады. Йә, бу шәп түгелмени? Халыкка да ошый. Миңа безнең музыканы дөньяның барлык почмакларыннан җибәрәләр хәзер. Мәсәлән, «Краски» төркеме продюсеры Алексей Воронов Лос-Анджелестан шалтыратты: «Братишка,



твою «Черноглазую» через раз гоняют во всех русских магазинах и кафешках. И еще какую-то «Утанма», – ди. «Может, «Уфтанма», – дип, кабатлап сорадым. «Да, да, именно так, – дип, эләктереп алды ул. – Никто не понимает, но все слушают и поют».

Төркия, Мисыр, Тунис, Казахстан, Таиланд, Германия белән дә шундый ук хәл. Дөнья татар һәм башкорт телләрендәге шлягерлар белән яңа хитларны тыңлый. Бу әнә теге 2011 елдагы сөйләшүнең чынбарлыктагы чагылышы. Безнең мәдәният, радиация дулкыны сыман, Җир шары буйлап тарала. Мин моңа бик шатланам!

– Сезгә иң дөрес бәяне бирделәрме әле? Бирсә, кем?

– Бер кешене аерып искә аласым килә: ул «Татар җыры» фестивалендә телефонына мине төшереп, «Элвин Грей җырлый» дигән язу белән Инстаграмына урнаштырган иде. Бу кеше – Татарстанның Президенты. Гади генә бер гамәл, югыйсә. Әмма никадәр зур мәгънәгә ия! Әлеге посттан соң, мин өйгә кайттым да, студиягә бикләнеп, алны-ялны белмичә, эшләдем. Иҗат итәргә генә түгел, очарга да әзер идем хәтта...

– Сезнең аудиториягез – ул кемнәр?

– 2 яшьтән алып 90 яшькә кадәрле теләсә кем. Мин үзем башта яшьләр өчен генә эшләрбез, дип уйлаган идем. Ләкин вакыт башкача хәл итте.

– Артист образы – уйлап чыгарылган, коммерция рельсларына куелган образ гынамы, әллә анда ихласлык та булырга тиешме? Элвин Грей образында Радик Юлъякшин ни дәрәҗәдә бар?

– Радик Юлъякшин – беренче мәхәббәт турында җырлый торган гап-гади бер авыл малае ул. Ә Элвин Грей – милли мәдәниятне дөнья буйлап таратучы пропагандист.

– Карьерагызның хәзер кайсы этабында дип саныйсыз? Алга таба безгә нинди проектлар күтәргә?

– Минемчә, бу әле – зур бер процессның башы гына. Алга таба тагын да колачлырак проектлар булачак. Алар турында зурдан кубып сөйлисем килми, әмма инде 2019 елның көзендә үк күрәчәксез...

– Артист булмасагыз, кем булыр идегез?

– Аранжировщик булып Уфада утырыр идем, мөгаен. Үз вакыты җиткәч, саунд продюсер булып китәр идем, бәлки... Йә инде, клавишник сыйфатында, Юра Шатунов белән йөрүемне дәвам иткән булыр идем...

– Сезне тәрбияләгән остазлар – кемнәр? Кумирларыгыз?

– Минем төп укытучым – ул «Черниковка». Шатланыргамы моңа, юкмы – белмим. Әмма ничек бар, шулай. Ә милли эстрадага килсәк, ул хәзер, ниһаять, уянды.

– Бүгенге татар эстрадасын 10 баллы шкала буенча ничек бәяләр идегез? Безнең эстрада дөнья масштабындагы тенденцияләр белән чагыштырганда, калышамы, кемнәргәдер иярәме, әллә үз юлы белән барамы?

– Моннан берничә ел элек кенә аңарга минус билгесе белән «троебас»тан артыкны куеп булмый иде. Хәзер инде ныклы 7 баллга тарта. Ни өчен җидеме? Ә бу – минем яраткан саным. Коллегаларны тыңлыйм да, безнең сазлыкта «яңа дулкын» күтәрелүенә куанам. Сез, әнә, Әнвәр Нургалиевка карагыз, Фирдүс Тямаевка, Бабек Мамедрзаевка... Шәп бит! Тагын ике ел бирегез һәм күрерсез: безнең «патшалыкта» хәлләр ул кадәр үк мөшкел түгел әле. Иң мөһиме – халык безнең белән, ә бергәләп без таулар күчерә алабыз. Ә бит әле берничә ел элек кенә 30 елга диярлек калыша идек... Хәзер без Россия шоу-бизнесында да мескеннәр рәтендә түгелбез. «Барслар» ниндидер «фабрика» оештыралар, дип ишеттем, «ваһаповчылар» рус мәркәзендә тулы заллар җыеп, шәп концертлар бирә. Ә тамашачыны алдап булмый: ул бит тир түгеп тапкан акчасын түләп килә концертка. Әгәр ошамый икән, икенче юлы бу артистны инде сайламаячак...

– «Татнефть Арена»дагы аншлаг йогынтысы нинди булды? Сездә үзегезгә карата бәя, мөнәсәбәт үзгәрдеме?

– Стадионнардан соң атна буе тора алмадым. Берәүне дә күрәсем килмәде, берәү белән дә сөйләшәсем... Хәзер инде акрынлап хәл керә башлады. Димәк, хаталарны төзәтү өстендә эшлибез дә, камилләшүне дәвам итәбез.

“ – Мине халыкның уянуы сөендерә! Концерттан кайтканда, троллейбусларда, автобусларда безнең милли җырларны татар һәм башкорт телләрендә җырлыйлар. Бу – бик зур бәхет! Димәк, без куйган максатка ирештек, безнең эстрада исән!

ИКЕ МИЛЛӘТНЕҢ ХЕЗМӘТЧЕСЕ, ЯКИ ВАТАН ҺӘМ МИЛЛӘТ БЕЛӘН СӘҮДӘ ИТМИМ

– Сезне Тукай премиясенә тәкъдим итсәләр, реакциягез нинди булачак? Алыр идегезме?

– Тәкъдим итсәләр, шат булачакмын. Димәк, 12 ел дәвамында ике тугандаш халыкны үзара якынайту юнәлешендә юкка гына эшләмәгәнмен. Димәк, минем татар белән башкортның зур бер кодрәтле, көчле рухлы халык икәнлегенә ышануым хак булган. Ул халыкны ясалма рәвештә махсус аерганнар, әмма безнең бер зур, тату гаилә булып яшәү теләгебез һаман да көчле.

– Ә сез үзегезне кайсы да булса милләтнеке дип саныйсызмы? Әллә җырчының, артистның милләте булырга тиеш түгелме?

– Минем әнием дә, әтием дә – башкортлар. Ватан белән милләтне сайлап алып булмый, дип саныйм һәм алар белән сәүдә дә итмим. Әмма мин – кайчандыр тамырлары бер булган ике тугандаш халыкның хезмәтчесе. Көчем җиткәнчә, аларның икесенә дә хезмәт итәчәкмен.

– Сез музыкада фәлсәфә булырга тиеш түгел, ул «качать» итәргә тиеш, дисез. Ә үзегез нинди музыка тыңлыйсыз? Менә хәзер, бүген?

– Европаны, Азияне, яңа юнәлешләрне өйрәнәм. Минем музыкам бит милли эстраданы дөнья күләмендә пропагандалауга хезмәт итә. Шулай ук – телемне дә. Аны бөтен җирдә дә тиешле дәрәҗәдә кабул итәргә тиешләр, ул – бәйрәмнәр, табын теле генә түгел.

– Музыкадан кала, тормышыгызны тагын ни бизи? Мавыгулар, кызыксынулар?

– Минем төп эшем һәм мавыгуым – музыка. Баштанаяк аңа чумып яшим. Башка нәрсәләргә, дөресен генә әйткәндә, вакыт та җитми, теләк тә.

– Сезнең өчен башка артистлар белән бергә иҗади тандемнар тудыру – ят нәрсә түгел. Ә хыялдагы дуэт, тандем – ул кем белән булыр иде?

– Балачактан Айдар Галимовның иҗатын яратам. Аның белән эшләп карарга бик тә теләр идем.

– Сез кешеләрдә нинди сыйфатларны хөрмәт итәсез, ниләрен яратмыйсыз? Үзегездә алар бармы?

– Хыянәтне, икейөзлелекне һәм ялагайлыкны яратмыйм. Көчле, туры фикерле, төгәл һәм сүзендә тора торган кешеләрне ихтирам итәм. Табигатем буенча йомшак һәм беркатлырак кеше булганга, мөгаен, командага көчле, каты, кырыс кешеләрне алырга тырышам. Әмма үземне, якыннарымны бер дә юкка, хаксызга кимсетә башласалар, үзем дә, аларны яклар өчен, рәнҗетүчеләрнең юлына аркылы ятарга әзермен. Халкыма тел тидерсәләр дә – нәкъ шулай. Чөнки минем халкым – ул Габдулла Тукай белән Мостай Кәримне тудырган халык.

Әңгәмәдәш:
Луиза Янсуар



«Татарстан»лы Яңа ел белән!

ТАССРНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

БАГЫШЛАНГАН УНИКАЛЬ ОТКРЫТКАЛАР КОЛЛЕКЦИЯСЕН ҖЫЙ

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

ТАССРның 100 еллыгына

багышланган уникаль открыткалар коллекциясен җый



Яр Чаллы шәһәре төзелеше. 1972 ел

Фото Яр Чаллы шәһәре Тарих һәм туган якны өйрәнү музее экспозициясеннән алынды.

ТАССР 100 лет ел